4˚2019

# ФӘННИ ТАТАРСТАН

ISSN 2499-9741

КАЗАН

*Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә*

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**

МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор,
идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән,
мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология
һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Мэдисон)

► **БАШ РЕДАКТОР**

Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**

ГОМӘРОВ И.Г., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**

ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият),
ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**

ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**

ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., ЛУКЬЯНЧЕНКО Е.Ф.

## БУ САНДА

### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Дыбо А.В.* Төрки һәм славян телләре: контакт күренешләр . . . . . 7
*Миңнуллин К.М., Сәфәров Р.Т.* Татар тел белемендә сүзлекләрнең тоткан урыны һәм тарихи үсеш перспективалары *(ахыры)* . . . . . 23
*Юсупов А.Ф.* 1920–1950 еллар татар шигъриятендә фонетик-стилистик чаралар: төрләре һәм кулланылыш үзенчәлеге . 34
*Сафина Э.И. Күгәрчен* орнитонимының символик мәгънәләре . . . 44

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Гомәров И.Г.* Татар иляһият гыйлеме традицияләренең билгесез чыганаклары: Сөләйман бине Дауд әс-Суваринең «Зөһрәт әр-рийаз...» хезмәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
*Надыршина Л.Р.* Габдулла Тукай шигъриятендә экзистенциаль мотивлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
*Галиева Л.Ш.* Гжегож Червинский хезмәтләрендә поляк һәм казан татарлары әдәбияты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
*Еникеев И.А.* Татарстанның рус телле язучылары һәм әдәби берләшмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Эркинов А.С.* Урта Азия-Идел буе багланышлары тарихыннан бер сәхифә (М. Мөхәммәдҗанов истәлекләре буенча, 1908 – 1910 еллар) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Дәүләтшина Л.Х.* Татар мифологиясенә караган чыганаклар . . . . 84
*Фазлетдинов И.К.* Фольклорчы галим Риф Мөхәммәтҗановның фәнни һәм педагогик эшчәнлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . 94

### МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н.* Әдәбият дәресләрендә шәхескә бәйле универсаль уку гамәлләрен формалаштыру . . . . 100
*Насипов И.С.* Башкортстанда татаристика үзәкләре . . . . . . . . 109

### СӘНГАТЬ

*Герасимова Н.В.* Татарстан районнары музейларының сәнгать тупламаларын булдыруда коллекционерларның роле *(Чистай һәм Тәтеш туган якны өйрәнү музейлары үрнәгендә)* . . 118
*Солтанова Р.Р.* Хакыйкать һәм тормыш шигърияте: рәссам Зөфәр Гимаев портретына штрихлар . . . . . . . . . . . . 123
*Кадыйров И.* Себер татарларының музыка уен кораллары . . . . 131

## ТАБИГАТЬ ФӘННӘРЕ

*Кәрәмова Н.С.* Яңа дару препаратлары булдыру өчен перспектив кандидатлар буларак үсемлек һәм микроорганизмнарның икенчел метаболитлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Куракова Ч.М.* Күренекле татар галиме Габдрахман Сәгъдинең тууына – 130 ел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146

*Баязитова Ф.С.* Туган тел һәм Латыйф Җәләйнең олы мирасы *(Күренекле тел галиме Латыйф Җәләйнең тормыш юлы һәм фәнни эшчәнлегенә карата)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150

*Ахунов А.М.* Шәркыяткә багышланган гомер . . . . . . . . . . . 155

## ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР

*Парсин М.* Татар театры тирәсендә. *Мөхсинов З.* Сезон үткәч . . 158

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Яблоновская Н.В.* Исмәгыйль Гаспринскийның публицистик мирасын популярлаштыруда яңа адым: Исмәгыйль Гаспринскийның сайланма әсәрләренең III томына («Публицистика: 1887 – 1890 гг.» (Казань – Симферополь, 2019) рецензия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

## ФӘННИ АЧЫШЛАР ЭЗЕННӘН

*Ризванов А.А.* Ген препаратларын куллану . . . . . . . . . . . . 171

*Фәхруллин Р.Ф.* Башкалабыз галимнәре АКШ галимнәре белән берлектә чәчләрне дәвалаучы буяу җитештергәннәр . . . . . . . 173

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

## В НОМЕРЕ

### ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Дыбо А.В.* Тюркские и славянские языки: контактные явления . . . 7
*Миннуллин К.М., Сафаров Р.Т.* Основные этапы развития татарской лексикографии *(окончание)* . . . . . . . . . . . . . . 23
*Юсупов А.Ф.* Фонетико-стилистические средства в татарской поэзии 1920–1950 гг.: виды и особенности применения . . . . . . . 34
*Сафина Э.И.* Символическое значение орнитонима *голубь* . . . 44

### ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Гумеров И.Г.* Неизвестные источники татарской богословской традиции: «Зухрат ар-рийаз...» Сулеймана ибн Дауд ас-Сувари . 50
*Надыршина Л.Р.* Экзистенциальные мотивы в поэзии Габдуллы Тукая . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
*Галиева Л.Ш.* Польско-татарская литература в трудах Гжегожа Червинского . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
*Еникеев И.А.* Русскоязычные писатели Татарстана и литературные объединения . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73

### СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Эркинов А.С.* К истории среднеазиатско-поволжских связей (по воспоминаниям М. Мухаммаджанова, 1908–1910 гг.) . . . . . 78

### НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Давлетшина Л.Х.* Источники по татарской мифологии . . . . . . 84
*Фазлутдинов И.К.* Научная и педагогическая деятельность ученого-фольклориста Рифа Мухаметзянова . . . . . . . . . . . 94

### НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Абдуллина Д.М., Мухарлямова Г.Н.* Формирование личностных универсальных учебных действий на уроках родной литературы . . 100
*Насипов И.С.* Центры татаристики в Башкортостане . . . . . . . . 109

### ИСКУССТВО

*Султанова Р.Р.* Истина и поэзия жизни: штрихи к портрету Зуфара Гимаева . . . . . . . . . . . . 118
*Герасимова Н.В.* Роль частного коллекционирования в формировании художественных собраний районных музеев Татарстана *(на примере Чистопольского и Тетюшского краеведческих музеев)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
*Кадыров И.* Музыкальные инструменты сибирских татар . . . . 131

### ЕСТЕСТВЕННЫЕ НАУКИ

*Карамова Н.С.* Вторичные метаболиты растений и микроорганизмов как перспективные кандидаты для создания новых лекарственных препаратов . . . . . . . . 141

## ПЕРСОНАЛИИ

*Куракова Ч.М.* 130 лет со дня рождения Габдрахмана Сагди . . . . 146
*Баязитова Ф.С.* Родной язык и наследие Латифа Заляя *(О жизни и научной деятельности видного языковеда Латифа Заляя)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
*Ахунов А.М.* Жизнь, посвященная арабистике . . . . . . . . . . . . . 155

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Парсин М.* О татарском театре. *Мухсинов З.* После закрытия сезона . 158

## НОВЫЕ КНИГИ

*Яблоновская Н.В.* Новый шаг к популяризации публицистического наследия Исмагила Гаспринского: рецензия на III том избранных произведений Исмаила Гаспринского («Публицистика: 1887–1890 гг.» (Казань – Симферополь, 2019) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

## ПО СЛЕДАМ НАУЧНЫХ ОТКРЫТИЙ

*Ризванов А.А.* Использование генных препаратов . . . . . . . . . . 171
*Фахруллин Р.Ф.* Казанские ученые совместно с учеными из США изготовили лечебную краску для волос . . . . . . . . . . . . . . 173

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811.512.1+811.16

*А.В. Дыбо*

# ТӨРКИ ҺӘМ СЛАВЯН ТЕЛЛӘРЕ: КОНТАКТ КҮРЕНЕШЛӘР

В статье представлен обзор того, что на современный момент известно о языковых явлениях, обусловленных контактами между славянскими и тюркскими языками. Оспаривается гипотеза тюркских контактов праславянского языка; приводятся некоторые новые данные относительно древнейших тюрко-славянских контактов; обрисовываются структурные последствия таких контактов.

**Ключевые слова:** тюркские язык; славянские языки; языковой контакт; лексика; грамматика.

The article provides an overview of what is known about linguistic phenomena due to contacts between Slavic and Turkic languages. The hypothesis of Turkic contacts of the Pre-Slavic language is disputed; some new data are given regarding the oldest Turkic-Slavic contacts as well as an outline of the structural consequences of such contacts.

**Keywords:** Turkic languages; Slavic languages; language contact; loanwords; copying ; lexics; grammar.

**1. Өйрәнелү тарихы.** Славян телләрендә төрки алынмалар XVIII гасыр ахырында – XIX гасыр башында өйрәнелә башлый. 1880 елларда славян телләрендәге көнчыгыш элементлары турында хезмәтләр дөнья күргән була инде, алар арасында арада иң әһәмиятлесе – 1884–1890 елларда төзелгән Miklosich сүзлеге.

Бу тикшеренүләрдә чыганак төрки телне аныклауга, сүзләрнең үзләштерелү вакытына аерым игътибар бирелми, ә төрки алынмалар беренче мәртәбә теркәлә генә. Рус телендә монголларга кадәрге төрки алынмаларның иртә катламын иң борынгы рус истәлекләрендә, беренче чиратта «Игорь полкы турында сүз»дә теркәлгән төрки сүзләргә багышланган хезмәтләрдә аерып чыгара башлыйлар (Мелиоранский һәм Корш бәхәсе, 1902–1909 еллар).

XX гасырның 30–40 нчы елларына кадәр, СССР территориясендә аерым төрки телләрнең сүзлекләре нәшер ителгәнче, славян телләрендәге төрки алынмаларга тюркологик анализ зур уңышларга ирешә алмый. XX гасырның 60 нчы елларына кадәр тюркологларның күбесе нигездә В.В. Радлов сүзлегендәге материаллардан файдаланалар. Әлеге хезмәт күләм ягыннан зур булса да, анда төрле телләр лексикасы тулысынча һәм бертигез дәрәҗәдә теркәлмәгән. 1929 елда Прагада славистларның I съездында Шәрыкны өйрәнүче поляк галиме Т. Ковальский төрки алынмаларның хронологиясен булдыру һәм төгәл чыганакны ачыклауны таләп итеп чыга [Kowalski 1932]. Әлеге хезмәттән соң 1957 елда Дмитриевның мәкаләсе (1941–1942 елларда язылган) басылып чыга. Анда бурычлар билгеләнү белән беррәттән,

рус телендәге төрки алынмаларның шактый өлеше анализлана, хронологиягә салу, алынма сүзнең чыганагын ачыклау һәм аның мәдәни-тарихи верификациясе принциплары арасындагы бәйләнеш күрсәтелә. Әлеге ике хезмәтне славян телләрендәге төрки алынмалар турындагы фәннең яңа дәрәҗәгә күтәрелүен билгеләгән хронологик этап дип атарга да мөмкин.

Славян телләрендә төрки алынмаларны өйрәнүнең башлангыч этаплары буенча әдәбиятны күзәтү өчен түбәндәге хезмәтләрне кара: Кононов, 1972, с. 251–253; Poppe, 1966; Poppe, 1971; Добродомов, 1981; Петровић, 1993. Шулай ук библиографияләр: Kappler, 2002, Krebs-Garić and Kelih, 2016.

И.Г. Добродомов һәм Ст. Стаховский исемнәре алдагы чорда аеруча мөһим. Аерым славян телләрендәге төрки алынмаларга багышланган берничә этимологик сүзлек бар. 2004 елда Соболев Балкан телләре берлеге диалектларында (славян телләрендә генә түгел) төрки алынмаларны системага салу омтылышын ясап карый. Славян телләрендәге төрки алынмалар, шул исәптән аларны өйрәнү методологияләре буенча М. Стаховский мәкаләләре дә игътибарга лаек.

Төрки алынмалар төрле дәрәҗәдә аерым славян телләренең этимологик сүзлекләрендә дә тикшерелә. Аларның бер өлеше А. Рона-Таш һәм А. Бертның фундаменталь хезмәтендә анализлана (2011).

Төрки телләрдәге славян алынмалары азрак өйрәнелгән; Идел буенда яшәүче халыкларның телләрендәге (төрки һәм фин-угор) көнчыгыш славян алынмалары турында К. Адягаши һәм Себер халыклары телләрендәге рус алынмалары турында Аникин (2003) хезмәтләрен атарга була. Төрек, татар һәм чуваш телләренең этимологик сүзлекләрендә дә славян алынмалары ышандырырлык итеп анализлана. Башка тел дәрәҗәләрендәге интерференция күренешләре турында кара: мәсәлән, Anderson, 2005, 2017; Pakendorf 2012, кайбер мәкаләләр: Boeschoten & al., 2006.

**2. Төрки-славян багланышларын чорларга бүлү һәм географик бүленеш.**

*2.0.* Алга таба, турыдан-туры күзәтелә торган чор алдыннан килгән тарихи чорларны тикшергәндә, сүз лексик алынмалар турында барачак. Лексик алынмалар – үткәндә телләр арасында багланышлар булуны күрсәтә торган төп материал. Сүзнең алынма характерын ышандырырлык итеп дәлилләүгә караганда телнең нинди дә булса структур үзенчәлегенең үзара бәйләнеш нәтиҗәсендә барлыкка килүен ышандырырлык итеп исбатлау күпкә катлаулырак. Шуңа күрә структур алынмалар турында ышанычлы итеп телнең хәзерге торышына бәйле рәвештә генә сөйләшеп була.

*2.1. Иртә болгар-славян багланышлары.* Славяннар очрашкан беренче төркиләр – Идел буе болгарлары булса кирәк. Баба төрки тел берлегенең иң беренче бүленеше – болгар һәм гомумтөрки, яисә стандарт төрки төркемнәргә бүленүе. Бер төркем аргументлар (баба төрки телдәге борынгы кытай алынмаларының фараз ителгән фонетик тыш-

часы буенча вакытын билгеләү; глоттохронологик исәпләүләр) әлеге бүленешнең безнең эра чигендәге интервалда барлыкка килүен, безнең эраның III гасырыннан да соңрак түгеллеген дәлиллиләр. Бүгенге көндә болгар төркеменең бердәнбер варисы – хәзерге чуваш теле, әмма протоболгар теле фонетикасы тарихының башлангыч этапларын болгар төркеменә караган теләрдән башка телләргә үтеп кергән иртә алынмалар турындагы мәгълүматлар нигезендә дә торгызырга мөмкин. Венгр телендәге болгар алынмалары (400 гә якын сүз) – бу темага караган иң информатив материал.

V гасыр ахырына Византия чыганакларында «болгарлар» этнонимы пәйда була. Ул һуннардан килеп чыккан һәм Идел белән Дунай бассейннары арасындагы далада яшәгән кабиләләр конфедерациясен аңлата. Алга таба болгар конфедерациясе Идел болгарлары һәм Дунай болгарлары төркемнәренә бүленә; телгә нисбәтән беренчесенең аеруча характерлы реликтын хәзерге чуваш теле тәшкил итә. Болгар төркеме башка төрки төркемнәрдән бик нык аерыла. Аңа хас үзенчәлекләр хәзерге чуваш телендә күзәтелә, әмма «болгар» теленең башлангыч торышын барыннан да элек венгр телендәге болгар алынмалары аша күзалларга мөмкин. Венгрларның борынгы бабалары, күрәсең, Көнбатыш Себернең көньягында болгар конфедерациясенә кушылып, аның белән бергә Дунай бассейнына килгәннәр. Венгр телендәге болгар үзенчәлекләре ачык чагылган төрки алынмаларның зур массивын, аерым алганда, Л. Лигети (1977) тикшерә; Рона-Таш һәм Бертның югарыда телгә алынган китабында (2011); алынмаларны фонетик үзләштерү үзенчәлекләре һәм чыганак идиомның алар артында яткан үзенчәлекләре турында шулай ук кара: [Дыбо, 2010; 2011a; Дыбо, Норманская 2013; Дыбо 2016a]. Венгр телендәге болгар алынмалары ике төркемгә бүленә. Бу факт алынмалар ике хронологик катламны тәшкил иткән дип фаразларга мөмкинлек бирә. Беренче төркемдә төрки прототипларның фаразланган тышчасы баба төрки хәлдән әллә ни аерылмый диярлек. Икенчесендә прототиплар Дунай болгарлары теленнән көньяк славян телләренә кергән алынмаларның прототиплары белән шактый зур охшашлыклар булуын күрсәтә. Димәк, венгр телендәге алынмаларның беренче төркемен «the Pre-Conquest Layer»га [Róna-Tas, 1988] кертергә мөмкин; болар – Идел-Кама, яисә [Róna-Tas, 2005] Дон-Кубань ареаллары территорияләрендә барлыкка килгән алынмалар булса кирәк (б.э.к. V–VII гасырлар). Венгр телендәге болгар алынмаларының икенче төркемен Дунай болгарлары теленнән кергән берәмлекләр тәшкил итә. Алар хәзерге Венгрия тирәсендәге территорияләрдә барлыкка килгән. Аларның венгр телендә фонетик үзләшү кагыйдәләре хронологик яктан венгрлар Урта Дунай буен яулаган чорга якын дәвердә венгр теленә үтеп кергән иртә славян алынмаларының үзләшү кагыйдәләренә туры килә (895–900 ее.) [Хелимский 2000].

*2.1.0. Баба славян телендә төрки алынмалар мәсьәләсе.* Славян телләрендә дә төрки алынмаларның «болгар» фонетик үзенчәлекләре

ачык күзәтелгән шактый зур катламы табыла. Бу алынмалар арасында баба славян хәлендәге, ягъни славян телләре аерым тармакларга бүленә башлаганчыга кадәр, алынмалар булу-булмавы гына бәхәсле булып кала.

Бик борынгы дәверләрдә (якынча б.э. V г.) славяннарның (болгарлар белән ассоциацияләнгән) «һуннар» белән бәйләнешләрында теркәлеп калган кайбер «һун» сүзләре дәлил була алыр иде: *strava* ‘мәрхүмне искә алу мәҗлесе’ (Иордан), *medos* ‘исерткеч эчемлек (Приск: «җирле халык аны шулай атап йөртә»). Әмма бу сүзләрнең авторларга «һун» теленнән түгел, ә славян тәрҗемәче аша да эләгү мөмкинлеге дә танылган [Maenchen-Helfen, 1978, p. 288–289].

Баба славян телендә күз алдында тотылган төрки алынмаларның исемлеген Голуб [Gołąb, 1992, p. 401] алдагы өйрәнү этабы рухында төзегән, ягъни әлеге сүзләрнең чыннан да баба славян төрки бераемлекләре булып санала алу-алмау һәм кайсы телдән алыну мәсьәләсе игътибардан читтә калган. Голуб төзегән исемлекне тәнкыйтьләп тикшерү турында кара: Stachowski, 2005; анда ике генә этимология кире кагылмаган, алары да ышанычлы түгел:

БСл **obъrъ / *obъr=inъ,* чаг. урта гр. Ἄβαρ, Pl. Ἄβαρεις, Ἄβαροι, лат. *avares, avari*; бор. төрки *apar* этнонимы. Славян һәм грек этнонимнарының борынгы төркиләрнекенә бәйле булуы шикле: славян телендә дә, грек телендә дә сүз уртасындагы тартыкның яңгыраулашуы проблема тудыра (беренче тапкыр Прискта, ягъни б.э. V г. урталары). Вакыт ягыннан тарихта аварлар пәйда булган һәм Приск телгә алган чорга туры килгән венгр телендәге иртә төрки алынмаларда мондый яңгыраулашу күзәтелми, яңгыраулашу венгр телендә соңгы чор болгар алынмалары катламына хас (IX–X гг.). Шуңа күрә этнонимның килеп чыгышы томанлы.

БСл **x(ь)rěnъ*: чув. *xĕren* id. сүзеннән дигән этимология тәкъдим ителгән [= гомумтөрки **kïz-gan* ‘кызган, кызу’] < *xĕr-* ‘кызарга, кызарырга (кызган әйбер турында); көергә’ [= гомумтөрки **kïz-* id.]. Әмма, Фасмер билгеләп үткәнчә (4: 275), тарихи яктан ул Теофраст һәм Плинийда (б.э.к. III гасырдан башлап) *κεράϊν, ceraïn* ‘кыргый торма’ сүзләренең телгә алынуына тәңгәл килми (аның фраклар яки иллирияleләр телләреннән чыккан күчмә сүз булуы ихтимал). Тюркологик караштан исә, венгр һәм славян телләрендәге дунай-болгар алынмалары (венгр телендәге иртә болгар алынмалары кебек үк) баба төрки **ï* ны редукцияләштереп түгел, ә *a* кебек чагылдыра; слав. *ѣ* болгар алынмаларында гадәттә сонант алдыннан килмәгәндә баба төрки **i* га барып тоташа. Идел болгарлары язмаларында (XIII гасырдан) югары күтәрелешле **ï* һәм **i* сузыклары алда редукцияләнгән авазларга күчми [Erdal, 1993, p. 149]. Шул рәвешле, болгар теленең бер генә варианты да БСл **x(ь)rěnъ* га чыганак була алмый. Шул ук вакытта чуваш сүзенең үзләштерелгән рус алынмасы булуы бик мөмкин.

*2.1.1. Дунай болгарлары һәм көньяк славяннарның телара бәйләнешләре.* Дунай-болгар телендәге бик күп сүзләр иске славян теленә

нигез булган диалектка эләгә һәм көнчыгыш славян телләренә, шулай ук өлешчә славян дөньясының әдәби теле булган көнбатыш славян телләренә тарала. Тарихи чыганакларга нигезләнгәндә, бу алынмаларның барлыкка килү вакыты VIII–IX гасырлар дип билгеләнергә тиеш. Славян телләрендә бу лексиканың фонетик үзләштерелү кагыйдәләре венгр телендә дунай-болгар алынмаларының үзләштерелү кагыйдәләрен хәтерләтә, сүзләр дә еш кына алар белән тәңгәл килә. Кара: мәсәлән, Дыбо, 2011б.

Дунай-болгар теленнән иске славян һәм көнчыгыш болгар теле белән чиркәү-славян теленә (аның белән көнчыгыш славян телләренә) фигыльдән һәм исемнән сүзьясагыч Nom. ag. **-ъčьјь* суффиксы алынган [Ефимова, 2006, с. 173].

Суффикс алу билгеле бер вакыт аралыгында дунай-болгар – борынгы болгар икетеллелеге булу турындагы табигый фаразның дөреслеген раслый. Дунай-болгар язмалары гомум танылу алмый торып, әлеге бәйләнешләрнең кире йогынтысы, ягъни славян телләреннән дунай-болгар теленә кергән сүзләр турында фикер йөртү мөмкин түгел. Күрәсең, әлеге бәйләнешләрнең төп нәтиҗәсе дунай-болгар телендә сөйләшүчеләрнең акрынлап славян теленә күчә баруы булган.

*2.1.2. Идел болгарлары һәм көнчыгыш славяннарның телара багланышлары.* Идел болгарлары теленнән[1] көнчыгыш славян телләренә кергән сүзләр дә бар (мөгаен, Идел сәүдә юлы ашадыр). Алар өлешчә көнбатыш славян телләрендә, нигездә поляк телендә таралыш алган. Бу алынмаларның вакыты Идел Болгары барлыкка килгәннән соң, X гасырдан соң дип билгеләнергә тиеш.

Рус. *ковёр,* укр. *ко́вер*, бор. рус. *ковьръ* ʿковерʼ. Идел болг. **kävöř* < баба төрки **gebiř* яки **gebüř* ʿкеләм, коверʼ > крх.-уйг. *keviz*, *köwüz*; төр. диал. *köüz*.

Бор. рус. *трунове* ʿИдел болгарларында аксөяк кешеләрʼ, **tъrunъ* < Идел болг. **turun* = бор. төрки *tudun*, хазар. Τουδουνος һ.б.

Көнч. слав. **pirogъ* ʿбәлеш, пирогʼ (бор. чех, словак, бор. поляк, поляк телләренә кергән) < Идел-болг. **bŏrak/g*, чаг. гомумтөрки **bürek* ʿбәлеш, пирогʼ, баба төрки **bür-* ʿкапларга, томаларгаʼ.

Идел-болгар теле аша кергән фарсы алынмасы: рус. *бурса́* ʿфарсы ефәк тукымасыʼ соңгы идел-болгар теленнән > чув. *purśъn* / *porśъm* ʿефәк тукымаʼ, шуннан ук Идел буе фин телләрендә: мар. *порсын*, удм. *буртчин* һ.б.

Nom. ag. **-čI* төрки суффиксын кайвакыт көнчыгыш славян телләрендәге исемьясагыч Nom. ag. **-ьščik* > рус. *-чик/щик* суффиксының чыганагы дип саныйлар [Варбот 1969: 92; XIII гасырдан башлап]. Әгәр шулай икән, аның барлыкка килүен көнчыгыш славян һәм төрки телләр арасында багланышлар башланган чор белән бәйләп карарга кирәк.

---

[1] Идел-болгар теле Идел буе территориясендә XIII–XV гасырларга караган гарәп язулы эпитафияләрдәге глоссаларда чагылыш тапкан; интерпретация мәсьәләләрен кара: Erdal 1993.

Кире якка, идел-болгар теленә, борын сузыгы сакланган гипотетик бор. рус теленнән **kǫželь* (> рус. *кужель*) иң иртә алынмаларның берсе булса кирәк; кара: чув. *кĕнчеле*, диал. *кăнчала* ‘көнҗәлә; каба’. Баба славян борын сузыгын баба славян теленнән алынган **gǫba* (~ рус. диал. *губа*) ‘гөмбә’ сүзе дә чагылдыра. Идел болг. теленә ул **g/kümpä* буларак кергән > чув. *кăмпа* ‘гөмбә’ (сузыкның алгы рәткә күчүе исә идел-болгар телендә арткы рәт сүзләрендә тел арты шартлаулы авазлары спирантларга әйләнүгә бәйле, чаг. бор. рус. *Хопужьское море* Идел-болг. **харъг* сүзеннән < баба төрки **kapïg* ‘капка, капуг’); тат., башк. *gömbɛ* ‘гөмбә’ Идел-болг. теленнән алынган.

Слав. **selo* > *sala* (чув., тат., башк., ктат., караим. *сала*) сүзе славян теленнән («хазарлар дәверендә») кергән иртә алынмаларга нисбәт ителә; төрки сүзнең территориаль яктан Идел буе һәм Кырым белән бәйле булуы ачык күзәтелә; тулырак кара: Добродомов 2008. Бу баба төрки **ä* нең > Дунай.-болг. *a*, Идел-болг. *ä* гә күчүе белән славян теленнән болгар тибындагы телгә алынма була ала, ягъни бор. болгар теленең Идел-болгар һәм Дунай-болгар телләренә таркалып барган чорына якын дәвердә.

*2.2. Иртә гомумтөрки-славян бәйләнешләре.* Якынча б.э. X гасырында Көнчыгыш Европа территориясендә көнчыгыш кыпчак һәм, ихтимал, угыз тибындагы телләрдә сөйләшкән төрки халыклар пәйда була. Угыз телендә сөйләшүчеләре, ихтимал, бәҗәнәкләр булгандыр (этноним буенча фикер йөрткәндә, угызча **bāǯa-nak* ‘бажа, бажа кеше’ сүзенә барып тоташырга мөмкин). Әлеге иртә угыз бәйләнешләренең ышанычлы эзләре әлегә табылганы юк. Якынча венгр телендәге коман-бәҗәнәк алынмаларындагы тарихи-фонетик үзенчәлекләрне күрсәткән кыпчак тибындагы төрки телләрдән кергән сүзләрне иске славян һәм чиркәү-славян телләрендә очратабыз, кара: Дыбо 2016б.

Көнбатыш кыпчак (ихтимал, коман) алынмалары «Игорь полкы турында сүз»дә (XII–XIII гасырлар дип фаразлана) шактый күп кулланыла, анализны кара: Менгес, 1979; Poppe, 2001 һ.б.

Шул ук Идел сәүдә юлы аша кергән берникадәр иртә славян, ихтимал, көнчыгыш славян алынмаларын Урта гасырлар төрки (нигездә кыпчак) истәлекләрендә очратабыз. Иң беренчеләре – Мәхмүд Кашгари сүзлегендә (XI гасыр) теркәлгән.

*rabčat* ‘хак түләнми торган мәҗбүри хезмәт’ ганчак., гапакс МК [Cl. EDT, 780]. Алынманың чыганак сүзе славян телләрендә очрамый, әмма бу – **orb-ьсь* ‘servus’ праславян диминутивыннан [ЭССЯ, 32, с. 134] **-ęt-* диминутив суффиксы ярдәмендә барлыкка килгән продуктив сүзьясалышы [кара: Vondrak 1, p. 493–494].

*samala* ‘дегет; сумала’: XIV гасыр башыннан ук төрки – коман , мәмлүк-кыпчак, чыгтай (XV гасыр) истәлекләрендә теркәлгән; VEWT 399.

*2.3. «Монгол яуларыннан соңгы» төрки-славян бәйләнешләре.*

*2.3.1. Төрки-көнчыгыш славян бәйләнешләре.* XIII гасыр башында Чыңгыз хан империясенең Көнчыгыш Европага экспансиясе белән

бер үк вакытта нугай яки көнчыгыш кыпчак тибындагы телдә сөйләшкән Үзәк Азия кыпчак халыклары күченеп йөри. Көнчыгыш славян телләрендә, шул исәптән аларның Алтын Урда һәм аннан соңгы чордагы язма истәлекләрендә күпсанлы кыпчак алынмалары табабыз. Аерым алганда, бу – дәүләт учреждениеләре, социаль оешмалар, икътисади эшчәнлек атамалары, хәрби терминология; шактый күп көнкүреш лексикасы: рус. *ямщик, казак, тамга* (рус теленең үзендә ясалган *таможня* дериваты белән), *аршин, барыш, деньга, алтын, армяк, утюг*; укр. *козак, аршин, бариш, алтин, арм'як, утюг, ішак* һ.б. Күренгәнчә, рус теле өчен бу нигездә Идел буе төрки (иске татар теле) идиомы (мәсәлән, гомумтөрки **äšäk* 'ишәк' > рус. *ишак,* 1567 елдан башлап, **ä > i* Идел буена хас сузыклар сыну билгеләре белән, чаг. төр. *eşek*, тат. *ишәк* 'шул ук'). Аерым алганда, соңгы Урта гасырлар төрки телләре аша рус һәм башка көнчыгыш славян телләренә шактый гына гарәп, фарсы һәм монгол чыгышлы сүзләр керә (*казна* (фарсы), *алмаз* (гар. < грек.), *караул* (монг.)).

Украин һәм көньяк рус диалектларында, моннан тыш, күп кенә төрки сүзләр кырымтатар теленең угыз һәм нугай диалектларына барып тоташа: укр. *баюра* 'су җыелган чокыр, елгадагы ермак' кырымтатар теленнән, төр. *bayır* «тау бите, кашлак», «кар өеме, көрт», «калкулык» (гомумтөрки **bagïr* 'бавыр'); укр. *капшук* «янчык» нуг. *капшык*тан (гомумтөрки **kāp-čïk* 'кечкенә кап, капчык', **č > š* нугай күчеше белән).

Төрки алынмаларның рус теленә үтеп керүенең катлаулырак юллары турында карагыз: НРЭ.

Төрки телләрнең соңгы Урта гасырлар ядкярләрендә көнчыгыш славян чыгышлы лексика славян дәүләтләре территорияләрендә яшәгән һәм акрынлап ассимиляцияләнгән төрки халыкларның[1] язма истәлекләрендә генә күп очрый, чаг. «әрмән-кыпчак» документларында (Каменец-Подольский, XVI гасыр): *боставлені* 'урнаштыру, билгеләү' (иске укр. *поставленье*), *вірны* 'тугрылыкка ант итүче' (укр. *вірний*), *колода* 'дыба' (укр. *колода*) [Грунин, 1966].

Специфик фонетик тышчалы булу сәбәпле, чуваш теленә үтеп кергән кайбер рус сүзләре иртә (XVI гасырга кадәр; яки диалекталь) алынмалар итеп карала (аннан алар Идел-Урал төбәгенең башка төрки телләренә таралган). Мондый алынмаларның кайберләре тур. карагыз: Адягаши 2005.

*2.3.2. Төрки-көнбатыш славян багланышлары.* Көнбатыш славян телләре бу чорда төрки алынмаларны нигездә көнчыгыш славян телләре аша кыпчак телләреннән ала; поляк теле – шулай ук турыдан-туры Польша-Литва татарларыннан; госманлы алынмаларының төп юлы – госманлы төрек теленнән венгр теле аша борынгы чех һәм иске поляк телләренә.

---

[1] Польша-Литва татарлары XIV гасыр ахырыннан Речь Посполитая территориясендә тупланып яшиләр.

Поляк теле турыдан-туры кыпчак теленнән үзләштерә:

*atłan* ‘атлан!’ (рус. ‘нá конь!’), татарларның яуга кузгалгандагы боерыгы (*at--la-n*-фигыленең Imp.2 ‘атка атланырга’ (‘ат’ + Denom. + Refl.);

*basałyk* ‘кургашын шарчыклы чыбыркы’, иске поляк *baszalyk, bassalyk* ‘кургаш коелмалы камчы’ чама белән 1500 ел (гомумтөрки **basulık* иске төрки *basu* ‘киле сабы’ + *-lık* суфф.). Поляк теленнән укр. *басалык* XVIII гасыр, иске Д. блр. *басалыкъ*, рус. диал. *басалы́к.*

Речь Посполитая территориясендә югарыда телгә алынган әрмән-кыпчак документлары телендәге поляк алынмаларын чагыштыр [Грунин 1966]: *моцны* ‘вәкаләтле’, *моцоват* ‘вәкаләт бирергә’ поляк телендә *mocny, mocować*; *вымувіт* ‘белдерергә, әйтергә’ поляк телендә *wymówić.* Документлар шулай ук Речь Посполитаяның эшлекле славян теле конструкцияләрен калькалаштыруны да күрсәтә (хәер, тере төрки телгә структур славян йогынтысы турында алар буенча гына фикер йөртергә ярамый).

Поляк теленә кыпчак алынмалары көнч. слав. телләре аша кергән: поляк. *baskak* (1786) < укр.*баска́к,* рус. *баскак* < бор. рус. *баскакъ* ‘баскак, даругачы, салым җыючы’, гомумтөрки *bas-kak* (басарга = Nom.ag.); *buhaj* ‘үгез’ (XVII гасырдан) < укр. *бугай* (пол. телендәге украин чыганагын *h* күрсәтә) < гомумтөрки **buka* > кыпч. *buga* ‘буга, нәсел үгезе’.

Төрек теленнән поляк теленә турыдан-туры *tytoń, tytuń; tiutuń, tutuń* (XVII гасырдан) < төр. *tütün* ‘тәмәке’.

Төрек теленнән поляк теленә катлаулы юл белән: *adziamski* ‘фарси’ (XV гасырдан) < иске венгр. *egyem* ‘шул ук’ алынмасыннан дериват < төр. *ecem* < фар. *ädžäm* ‘Фарсы иле; фарси’ < гар. *ʿajam* җый. ‘гаҗәм, фарсылар’ [НРЭ: 33–34, алга таба поляк теленнән рус теленә кергән].

*2.3.3. Төрки-көнчыгыш славян бәйләнышлары.* XIV гасырның икенче яртысыннан көньяк славян – урта дунай-болгар, иске серб, иске македон телләре – Госманлы империясе йогынтысында кала. Госманлы империясенең милли сәясәте ассимиляциягә юнәлтелгән була, халыклар күчереп утыртылган, катнаш төрек-славян авыллары барлыкка килгән, төрек-славян билингвизмы үсеш алган була. Шуңа күрә әлеге славян телләре госманлы төрекчәдән бик күп, шул исәптән көнкүреш лексикасын тәшкил иткән сүзләр алган. Госманлы төрек алынмалары XVI гасыр башыннан яхшы күзәтелә.

Болг.: *ага* ‘бай хуҗа, әфәнде, ага’ (1544 елдан) < госм. *ağa* ‘әфәнде, хуҗа, ага’ < гомумтөрки **āka* ‘ага, абый; *хөрмәт белән эндәшү*’; *алтън* ‘алтын’ (XVII гасыр) < госм. *altın; атлия* ‘атлы, җайдак’ госм. *at-lı* ‘шул ук’ (ат = Com);

Госманлы төрек теле аша күпсанлы гарәп һәм фарсы сүзләре кергән: *алмаз* < госм. *almas* < гар. *almās* (< грек.); *бадем* ‘бадәм’ < госм. *badem* < фарс. *bādam.*

Шул исәптән *ама* ‘әмма, ләкин’ каршы куючы теркәгече дә үзләштерелгән < госм. *ama* < гар. *ammā* ‘шул ук’.

Чагыштырмача продуктив сүзьясагыч суффикслар алынган, ягъни алар лексик төрки берәмлекләрдә генә түгел, башка телдәге нигезләргә ялганып кулланыла: *-джия*: *ловджия* ‘аучы, сунарчы’ < *лов* ‘ау, сунар’ (госм. Nom. ag. *-cı* < гомумтөрки **-čı*, югарыдагы белән чагыштыр).

*-лък*: *войниклък* ‘гаскәри хезмәт’ < *войник* ‘солдат, гаскәри’ (госм. Nom. abstr. *-lık* < гомумтөрки **-lık*).

Кайвакыт болгар теленең, һәм Балкан тел берлегендәге башка телләрнең, кайбер грамматик күренешләрен госманлы йогынтысы белән аңлаталар, мәсәлән, постпозитив билгелелек артиклен (билгелелек семантикасына якын торган конкрет референтлыкны белдерүче төр, һәм гомумән барлык төрки телләрдә дә, 3 зат *-(s)ı* тартым күрсәткече белән бәйләп карыйлар) яки нәтиҗәлелекнең иске күрсәткече (төр. *-mış*) ярдәмендә турыдан-туры булмаган эвиденциальлек категориясен белдерүне. Әмма бу бик шикле. Болгар телендәге *-ът* билгелелек артикле праславян алмашлык энклитикасына кайтып кала; аның рефлексы фокус частицасы сыйфатында кулланыла, мәсәлән, Төньяк рус диалектларында. Шуңа күрә Болгар артиклиниң постпозитивлыгы эчке славян сәбәпләргә бәйле. Шул ук результативгә эвиденциаль мәгънәне үстерү – бер типологик фреквенталия.

XX гасырның икенче яртысы дәвамында Болгариядәге максатчан тел сәясәте госманлы төрек лексик һәм сүзьясагыч алынмаларын куллану ешлыгын шактый киметте.

Македон, серб телләрендәге (һәм хорват теленең штокав диалектындагы) госманлы төрек лексик алынмалары корпусы да болгар телендәге кебек үк хәлдә. Алынма суффикслар серб-хорват нигезләре белән бергә аз дигәндә XVII гасыр ахырыннан очрый башлый: *grabdžija* ‘угры, карак’ (*grabi-* ‘урларга, таларга’), *opaklija* ‘явызлык кылучы’ (*opak* ‘явызлык’; госм. Com *-lı* < гомумтөрки **-lıg*), *zločestluk* ‘усаллык’ (*zločest* ‘усал булу’) [Радиħ, 1990, с. 399–405; Радиħ 2001].

Словен телендә һәм словен диалектларында, серб-хорват теленең чакав һәм кайкав диалектларында (Госманлы империясенә кермәгән территорияләрдә) төрек алынмалары шактый аз һәм аларның күрше славян телләреннән кергәнлеге таныла [Pintarič, 2012].

Госманлы төрек теленә Балкан славян телләреннән кергән сүзләр XVI гасырдан күзәтелә башлый: *kuluçka* ‘йомырка баскан тавык’ (тәүге теркәлүе: 1501) < болг. *клочка* [Eren, 1999, p. 264]; *kabaniça* ‘биек якалы, җиңсез мех кием’ < болг. яки серб. *кабаница* (< итал.) [Eren 1999: 199]; *izbe* ‘аулак урын, чолан’ (тәүге теркәлүе: 1574) < болг. яки серб. *изба* ‘келәт, чолан’ [Eren, 1999, p. 197]; *vişne* ‘чия’ (тәүге теркәлүе: 1683) < болг. *вишна*, диал. *вишня* яки серб. *ви̏шња* [Eren, 1999, p. 436]; төр. *kral* ‘король’ < серб. *краљ* һәм *kraliçe* ‘королева’ серб. *краљица* (әмма госм. *kıral* ‘король’, М. Рясянен фикеренчә, < венг. *király* [VEWT, p. 266]; хәер, өстәлмә сузык ярдәмендә башлангыч кластерны юкка чыгарып, славян теленнән дә булуы бар).

*2.4. Яңа тарихтагы багланышлар.*

*2.4.1. Россия империясе, СССР һәм хәзерге Россия территорияләрендә төрки телләр һәм рус теле арасындагы багланышлар.* Бу чорда рус әдәби теле нигездә төрки телләрдән җирле төрки реалияләрне белдергән сүзләрне (*ирбис, айран, кобыз*) ала.

Рус теленең локаль сөйләшләре бу чорда да территориаль яктан якын идиомнардан шактый күләмдә көнкүреш төрки лексикасын ала. Мондый лексика сайланган исемлекне кара: Аникин 2000.

Тикшерелә торган территорияләрдәге төрки телләргә акрынлап фонетик үзләшүгә дучар булган күпсанлы һәм күптөрле лексик алынмалар үтеп керә. Себер телләре өчен зур исемлекне кара: Аникин 2003; Pomorska 2017. Идел-Урал буендагы төрки телләрдә үзләшкән рус алынмалары да шактый күп: чув. *хитре* ‘матур, чибәр’ (рус. *хитрый*), чув., тат. *монча, мунча* (рус. диал. *мыльня*), башк. диал. *мишук* ‘карыш’ (рус. *вершок*).

Сводешның төрки исемлекләрендә Россия территориясеннән үзләшкән рус алынмалары: ‘all’: туба, билт. *pes’* ‘бөтен’ (рус. *весь*); ‘good’: хакас. кач. *маңат,* саг. *tayat* (рус. *богат*); ‘many’: чув. *čïlaj* ‘бөтен’ (рус. *целый*); ‘seed’: якут. *sieme* (рус. *семя*); ‘worm’: якут. диал. *čierbe* (рус. *червь*) [кара: Дыбо, 2013б].

Әдәби төрки телләрдә әйтелешне һәм чыганакның орфографик формасын саклаган яки өлешчә саклаган үзләшмәгән лексик алынмалар да күп (чагыштыр: *хакас.* артист ‘артист’, *артиз-и* ‘артисты’).

XX гасыр урталарыннан алып бу территорияләрдәге рус теле өстенлек алган тулы дип әйтерлек рус-төрки икетеллеге төрки телләрнең лексик составына гына тәэсир итеп калмый. Бер төркем төрки халыклар, бигрәк тә үзләренең язма теле булмаганнары, әкренләп рус теленә күчә; хәзерге вакытта түбән чулым, урта чулым, туба, тофа телләре юкка чыгу алдында тора; шор һәм телеут телләренә дә юкка чыгу куркынычы яный. Чагыштырмача яхшы сакланган телләрдә дә төрле тел дәрәҗәләрендә интерферент күренешләр күзәтелә.

Кайбер тривиаль булмаган мисаллар китерәбез. Соңгы өч дистә елда тува телендә сөйләшүче шәһәр балаларының һәм яшьләрнең сөйләмендә «аспиратлар – аспират булмаган» фонологик оппозициясенең «саңгырау – яңгырау» оппозициясенә алмаштырылуы күзәтелүен белдерәләр. Шул ук күренеш кайчакта алтай әдәби телендә дә күзәтелә. Сәбәбе шунда ки, шәһәр балалары иң элек туган телләрендә түгел, ә рус телендә укырга өйрәнәләр, һәм соңыннан кирилл графикасында уку күнекмәләрен төрки текстларга карата да куллана башлыйлар.

Синтаксиста интерференция күренешләре:

а) Гадәттә төрки телләрдә сүзләр тәртибе инверсиясен рус теле йогынтысы белән бәйләп аңлаталар. Төрки телләрдә сүзләрнең гадәти тәртибе сулга тармаклана торган – SOV. Әмма еш кына, мәсәлән, объект һәм предикат инверсиясе күзәтелә, чаг. ком.: *Сакъла саманны – гелир заманы* (мәкаль).

Ихтимал, сөйләм телендә сүзләрнең мондый тәртибе еш кулланылу рус теленең тәэсире белән бәйледер; әмма чаг. бор. уйгур телендә дә моңа охшаш ачраклар бар: *Bo bir yumgak taš, nägülük ol biziŋä?* ‘Бу бер йомры таш, нигә ул безгә?’ (предикат – *nägülük* ‘нигә, ни өчен’) [Erdal, 2004, 413].

ә) Теркәгечләр һәм кисәкчәләр алу: төрки телләрдә һинд-европа тибындагы тезүле полипредикатив конструкцияләргә гадәттә ияртүле конструкцияләр туры килә, һәм бу конструкцияләрдә беренче клауза – хәл фигыль формасындагы предикат белән абсолют конструкция, чаг. комык телендә: *О бу языв язып сен оху*. ‘Ул бу язуны язар, син укы’.

Шуңа күрә төрки телләрдә төрки чыгышлы тезүче теркәгечләр сирәк очрый; аерым алганда, Урта гасырлардан мөселман этномәдәни зонасына эләккән төрки телләр тезүче теркәгечләрне фарсы һәм гарәп телләреннән үзләштерә (чагыштыр: үзб., аз., төр. *vә, ve* ‘һәм, вә’, *атта* ‘әмма, ләкин’). Чаг. шор теленә рус теленнән *или* теркәгечен алу (Көньяк Себер): ***Ili*** *aŋ qulayïnya uyul pardï,* ***ili*** *čïnap kiži ünü uyulča* ‘Әллә аның колагына ишетелде, әллә чынлап кеше тавышы ишетте’.

Төрки телләрдә нисби иярчен җөмләләр ролендә гадәттә төшем килешендәге сыйфат фигыльле катнаш абсолют конструкцияләре булган полипредикатив конструкцияләр килә, чаг. ком.: *сен окъ атгъанынгъны гёрдюм* ‘Синең ук атканыңны күрдем’.

Мөселман этномәдәни ареалына кергән төрки телләргә фарсы теленнән *ki* нисби кисәкчәсе алынган; чаг. хәзерге татар сөйләм телендә рус теленнән кергән *что* нисби кисәкчәсе: *Мин шат син-га,* ***что*** *син таза-сау һәм көр күңел-ле.*

б) Рус башкарылышын калькалау:

Балкар. *Магъа керек* «миңа кирәк» (дөрес конструкция – *мени керек*).

в) Кодларны катнаштыру:

Карачай: *Мен в этом году-да отпуск-га не еду* «Мин быел да отпускка бармыйм».

СССР таркалганнан соң барлыкка килгән төрки илләрдә (Азәрбайҗан, Казакъстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Кыргызстан) рус алынмаларын бетерүгә юнәлдерелгән тел сәясәте алып барыла, моның өчен телләрне латин графикасына күчерәләр; әлегә аларның теләгән нәтиҗәгә ирешүләре турында әйтү кыен.

*2.4.2. Славян-төрек багланышлары.* Рус теле, бигрәк тә XX гасырда, госманлы һәм төрек телләре өчен экзотизмнар чыганагы хезмәтен үти.

Чаг. рус теленнән кереп, хәзерге төрек телендә сакланган борынгы экзотизмнар (төрек сәяхәтчесе Әүлия Чәләби әсәрләрендә, 1611–1682): *kapuska* < рус. *капустка* яки *капуста*; *çar* < рус. *царь*.

XX гасырда, мәсәлән: *borç* (1983) < рус. *борщ*; *balalayka* (1994) < рус. *балалайка* кебек сүзләр алынган.

XIX–XX гасырлар дәвамында локаль славян сөйләшләреннән локаль төрек сөйләшләренә сүзләр керү дәвам итә, чаг.:

төр. диал. *vinter, minter* ‘балык тозагы’ (Видин) < болг. *винтер* (Видин), *вентер* (Бохот, Плевенско). Болг. теленә румын *vintîr* аша < рус. *вéнтерь*, ру сүзе исә литва *vénteris* сүзенә кайтып кала [Eren, 1999, p. 435; БЭР 1 (1971): 149].

Анатолия төрекләре сөйләшләрендә локаль славян сөйләшләренең фонетик йогынтысы күзәтелә. Мәсәлән, кайбер румелия сөйләшләрендәге һәм гагауз диалектларындагы *o* > *u* күчешен (*otur* > *utur* ‘утыр’, *kayboldu* > *kaybuldı* ‘югалды’), *h* фонемасының югалуын (*hava* > *ava* ‘һава’), алгы рәт сузыклар алдында *k* һәм *g* тартыкларының көчле палатальләшү тенденциясен (*öküz* > *ük’üs* ‘үгез’, *öfke* > *üfk’e* ‘үпкә’), арткы рәт сүзләрдә тартык алдында *l* > *w* күчешен (*alma* > *owma* ‘алма’, *dolma* > *dowma* ‘тулма’) шуның белән аңлаталар [Hazai, 1960; Kowalski, 1933, 1934; Селищев 1929; к. шулай ук Ужинин, 2008].

Алынма сүзьясагыч кушымчалар: Видинның төрек диалекты [Németh, 1965] *koy-qa* ‘кечкенә авыл, авылчык’ *koy* ‘авыл’ сүзенең кечерәйтелгән формасы. Видин диалектында иялек килешендәге постпозитив исем аергычы булган конструкциянең интерференцияле килеп чыгышы: төр. *qızın babası* урынына *babası qızın* ‘кызның атасы’. Шул ук диалектта төрки чыгышлы *ne* ‘ни, нәрсә’ һәм *kim* ‘кем’ сорау алмашлыкларының релятивизатор сыйфатында кулланылуын болгар конструкцияләрен өлешчә калькалаштыру дип карарга мөмкин. Шул ук күренеш гагауз телендә дә күзәтелә (*не, ким*); гагауз теленә шулай ук *да* ‘һәм’, *не...не* ‘ни...ни’ тезүче теркәгечләре һәм гаҗәпләнүне белдергән *бре* ымлыгы алынган [Покровская 1964].

2.4.3. Көнчыгыш Европаның кыпчак телләренә славян йогынтысы. XIV гасыр ахыры – XV гасыр башында көнбатыш кыпчак литва татарлары һәм караим телләрендә сөйләшүчеләр славян телле территориягә (хәзерге – Украина, Польша, Белоруссия, Литва) килеп утырганнар һәм славян теленең көчле йогынтысын кичергәннәр (югарыда телгә алынган XVI гасырда Каменец-Подольск татарлары хәле белән чагыштыр). Славян-төрки (украин-караим, поляк-караим, рус-караим, поляк-татар) икетеллелеге XX гасыр башыннан билгеләнә. Караим теленең галич һәм луцк диалектлары XX гасыр дәвамында юкка чыкканнар, тракай диалекты юкка чыгу алдында тора. Славян йогынтысына бәйле үзенчәлекләр коллекциясен (югарыда саналганнар кебек үк диярлек) Мусаев 2003: 23–30 хезмәтендә табарга мөмкин. Лексик алынмалардан һәм калькалардан тыш, бу – тартыкларның фонологик системасында катылык-йомшаклык буенча оппозиция барлыкка килү; сүзьясагыч кушымчалар, грамматик алкушымчалар (аерым алганда, сыйфатның артыклык дәрәҗәсен ясау өчен *наи-*: *наи-терен-ряк* ‘иң тирән’ (*-рак* – билге чагылышының тулылыгын белдергән гомумтөрки суффикс); *и, да, ни – ни* тезүче теркәгечләр алу, *не* ‘нәрсә’, *кай* ‘кайсы’ сорау алмашлыкларыннан релятивизаторлар, иялек килешендәге постпозитив аергычлар (*чач-ы башымнын* чәч-3prs баш-1prs-Gen

‘башымның чәче’) ясалу, фигыль башкарылышының аерым үзенчәлекләрен калькалаштыру һ.б.ш.

**3. Йомгак.**

XX гасыр урталарыннан төрки-славян тел бәйләнешләрен өйрәнүдә шактый алгарыш күзәтелүгә карамастан, чишелмәгән һәм бәхәсле проблемалар әле кала бирә. Бу нигездә аерым борынгы лексик алынмаларның үтеп керү вакытына һәм юлларына кагыла. Әлеге мәсьәләләрне яңача чишү күпмедер дәрәҗәдә югарыда тәкъдим ителгән картинаны үзгәртергә дә мөмкин.

**Кыскартылмалар**

аз. – азәрбайҗан
башк. – башкорт
билт. – хакас теленең билтер диалекты
болг. – болгар теле
бор. чех – борынгы чех
БСл. – баба славян теле
венг. – венгр
ганчак – МК да төрки диалектларның берсе, мөгаен, кыпчак
гар. – гарәп
госм. –госманлы
гр. – грек
диал. – диалекталь
Дунай-болг. – Дунай-болгар теле
Идел-болг. – Идел-болгар теле
иске слав. – иске славян
иске укр. – иске украин
кач. – хакас теленең Кача (хаас) диалекты
ком. – комык
крх.-уйг. – карахани-уйгур (МКда диалект)
ктат. – кырым-татар
кыпч. – кыпчак
лат. – латин
мар. – мари
МК – Мәхмүд Кашгари сүзлеге (XI гасыр)
монг. – монгол
нуг. – нугай
саг. – хакас теленең сагай диалекты
слав. – славян
тат. – татар
төр. – төрек
үзб. – үзбәк
удм. – удмурт
укр. – украин
чув. – чуваш

**Әдәбият**


*Адягаши К.* Ранние русские заимствования тюркских языков Волго-Камского ареала. Часть I. Этимологический справочник. Studies in Linguistics of the Volga Region, vol. II. Kossuth Egyetemi Kiadó, Debrecen, 2005.

*Аникин А.Е.* Этимологический словарь русских диалектов Сибири. Заимствования из уральских, алтайских и палеоазиатских языков. М.; Новосибирск, 2000.

*Аникин А.Е.* Этимологический словарь русских заимствований в языках Сибири. М.; Новосибирск, 2003.

*Варбот Ж.Ж.* Древнерусское именное словообразование (Ретроспективная формальная характеристика). М.: Наука, 1969.

*Дмитриев Н.К.* О тюркских элементах русского словаря // Лексикографический сборник, вып. 3. М., 1958, (перепечатано в кн.: Н.К. Дмитриев. 1962: Строй тюркских языков. М., 503–569).

*Добродомов И.Г.* Из истории изучения тюркизмов русского языка. // Тюркологический сборник – 1977. М., 1981. С. 90–108.

*Добродомов И.Г.* Типы поселений ранних тюрок. Историческая эволюция. // Природное окружение и материальная культура пратюркских народов. М.: Вост. лит. 2008. С. 195–218.

*Дыбо А.В.* Вокализм раннетюркских заимствований в венгерском // Gedenk von E.A. Helimsky. Finnisch-Ugrische Mitteilungen. Bd. 32/33. Hamburg, 2010. S. 83–132.

*Дыбо* 2011а – Дыбо А.В. Отражение булгарских палатализаций в булгаризмах венгерского языка // Материалы Международной тюркологической конференции «Чувашский язык и современные проблемы алтаистики» (Чебоксары, 15–18 сентября 2010 г.). Чебоксары, 2011. С. 1–16.

*Дыбо* 2011б – Дыбо А.В. Булгары и славяне: фонетические явления в ранних заимствованиях // Слова. Концепты. Мифы: К 60-летию Анатолия Фёдоровича Журавлёва. М.: «Индрик», 2011. С. 130–144.

*Дыбо* 2013б – Дыбо А.В., Этимологический словарь тюркских языков. Том 9 (дополнительный). Этимологический словарь базисной лексики тюркских языков. Астана: Proper Print, 2013

*Дыбо* 2016а – Dybo, Anna V. Bulgarian borrowings in Hungarian: the problem of reflecting *q // Words and Dictionaries. A Festschrift for Professor Stanisław Stachowski on the Occasion of His 85th Birthday. Krakow 2016, Jagiellonian University Press. pp 113–126.

*Дыбо* 2016б – Дыбо А.В. К кыпчакским заимствованиям в славянских языках // Мир Большого Алтая. Усть-Каменогорск 2016. № 1–2. С. 119–123.

*Дыбо А.В., Норманская Ю.В.* Периодизация тюркских заимствований в финно-угорских языках // Урало-алтайские исследования. 2013. № 4.

*Ефимова В.С.* Старославянская словообразовательная морфемика. М., 2006.

*Грунин Т.И.* Документы на половецком языке XVI в: судебные акты каменец-подольской армянской общины. М., Наука, 1967.

*Кононов А.Н.* История изучения тюркских языков в России. Дооктябрьский период. Л., 1972.

*Менгес К.Г.* 1979: Восточные элементы в «Слове о полку Игореве». Л.

*Мусаев К.М.* 2003. Синтаксис караимского языка. М., Academia, 2003

НРЭ – Новое в русской этимологии. Вып. 1. Институт русского языка им. В.В. Виноградова РАН. Москва, 2003.

*Петровић, Снежана.* 1993. Историјат и стање проучавања турцизама у српскохрватском језику, ЗбМСФЛ XXXVI/2, 71–128.

*Покровская Л.А.* Грамматика гагаузского языка: Фонетика и морфология. М., 1964.

*Радић, Прволав.* Турски суфикси у српском језику : са осврртом на стање у македонском и бугарском. Београд: Институт за српски језик САНУ, 2001.

*Радлов В.В.* Опыт словаря тюркских наречий: В 4-х томах. СПб., 1899–1911.

*Селищев А.* Полог и его болгарское население, София, 1929.

*Соболев А.Н.* Опыт исследования тюркизмов в балканских диалектах // ZfB, 40 (2004) 1: 61-91 ZfB, 40 (2004) 2: 206–229.

*Ужинин Е.Е.* Турецкие заимствования в языках восточно-средиземноморского ареала: языковые контакты на территории Османской империи: дис. ... канд. филол. наук: 10.02.22. Рос. гос. гуманитар. ун-т (РГГУ)]. М., 2008.

*Фасмер М.* Этимологический словарь русского языка. В 4-х томах. М., 1964–1973.

*Хелимский Е.А.* Компаративистика, уралистика. Лекции и статьи. М., 2000.

ЭССЯ – Трубачёв О.Н. (ред.), Журавлёв А.Ф. (ред. с 33 т., 2007) 1974–2013: Этимологический словарь славянских языков: праславянский лексический фонд. Т. 1–39. М. (Изд. продолжается.).

*Anderson, Gregory D.S.* 2005. Language Contact in South Central Siberia. In: Turcologica 54. Wiesbaden: Harrassowitz.

*Anderson, Gregory D.S.* 2017. Consequences of Russian Linguistic Hegemony in (Post-)Soviet Colonial space. In: Endangered languages of rthe Caucasus and Beyond. Brill, 2017. Pp. 1–16.

*Boeschoten & al.* Turkic Languages in Contact / edited by Hendrik Boeschoten, Lars Johanson, Vildan Milani. Harrassowitz, 2006

EDT: Clauson G. An Etymological Dictionary of Pre-Thirteenth-Century Turkish. Oxford, 1972.

*Erdal M.* Die Sprache der wolgabolgarischen Inschriften. Wiesbaden, 1993.

*Erdal M.* A Grammar of Old Turkic. Leiden: Brill, 2004.

*Eren H.* Türk dilinin etimolojik Sözlüğü. Ankara, 1999.

*Gołąb, Zbigniew.* The Origins of the Slavs: A Linguist's View. Columbus, Slavica Publishers, Incorporated, 1992.

*Hazai G.* Rumeli Ağızlarının Tarihi Üzerine, T.D.A. bel. 1960, T. D. K., Ankara, 1960

*Kappler, Matthias* (2002): Turkish language contacts in South-Eastern Europe. Articles in Italian, German, French and English. Istanbul: Isis Press (= Analecta Isisiana, 61).

*Kowalski T.* W sprawie metodologii badań zapożyczeń tureckich w językach słowiańskich. – Sborník prací I. Sjezdu slovanských filologů v Praze 1929, Bd. 2, Praha 1932: 554–556 (mit französischer Zusammenfassung auf S. 999–1001: La méthodologie des recherches sur les mots empruntés du turc dans les langues slaves).

*Kowalski Tadeusz.* Les Turcs et la langue turque de la Bulgarie du nord-est, Kraków: Polska Akademja Umiejetności, 1933.

*Kowalski T.* Osmanisch-tuerkische Dialekte, Enziklopaedie des Islam IV, Leipzig 1934. C. 991–1011.

*Krebs-Garić, Catharina, Kelih, Emmerich.* Loanwords in Bosnian/Croatian/Serbian (working bibliography).https://lissl.univie.ac.at/fileadmin/user_upload/p_lissl/Loanword_BCS_bibliography.pdf

*Ligeti L.* A Magyar nyelv Török kapcsolatai es ami körülöttük van. Budapest, 1977

*Maenchen-Helfen, Otto J.* (1978). Die Welt der Hunnen: Eine Analyse ihrer historischen Dimension. Vienna, Cologne, and Graz: Hermann Böhlaus Nach.

*Miklosich Fr.* 1884–1890: Die türkische Elemente in der südost- und osteuropäischen Sprachen // Denkschrift der Wiener Akademie der Wissenschaften. Philos.-hist. Klasse. Bd. 35, 36, 38.

*Németh J.* Die Türken von Vidin: Sprache, Folklore, Religion. (Bibliotheca Orientalis Hungarica, x.) 420 pp. Budapest: Akadémiai Kiado, 1965.

*Pakendorf, Brigitte.* 2012. Contact and Siberian Languages. In Raymond Hickey (ed), The Handbook of Language Contact , pp. 714–737. Hoboken: Wiley.

*Stachowski M.* Uwagi o zapożyczeniach ałtajskich w języku prasłowiańskim i kwestie pokrewne // Studia Turcologica Cracoviensia. 10 (2005) 437–454.

*Pintarič, Miha* (2012). On turcisms in Slovenian. Vestnik za tuje jezike, letnik 4, številka 1/2, str. 79–81.

*Pomorska M.* 2017. Russian loanworda in the Chulym Turkic dialects. Kraków, Ksıęgarnıa Akademıcka.

*Poppe N.* Jr. A Survey of Studies of Turkic Loan-Words in the Russian Language. // CAJ XI, № 4, 1966. P. 287–310.

*Poppe N.* Jr. Studies of Turkic Loan-Words in Russian. Wiesbaden, Harrassowitz, 1971.

*Róna-Tas A.* Turkic Influence on the Uralic Languages // The Uralic Languages. *Leiden, 1988.*

*Róna-Tas A.* Néhány megjegyzés faneveinkről (Bükk, dió, gyertyán, gyümölcsény, gyürüfa, éger, kőris, mogyoró, tölgy) // Magyar Nyelv. 2005: 419–438. Búdapest.

*András Róna-Tas;* †Árpád Berta with the assistance of László Károly. West Old Turkic. Turkic Loanwords in Hungarian. Part I: Introduction, Lexicon «A–K» (X, 618 S.). Part II: Lexicon «L–Z», Conclusions, Apparatus. (X, S. 620–1494). Turcologica. Herausgegeben von Lars Johanson. Band: 84. Harrassowitz. Wiesbaden 2011.

VEWT: *Räsänen M.* Versuch eines etymologisches Wörterbuchs der Türksprachen. Helsinki, 1969.

***Дыбо Анна Владимировна,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Россия Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы, Россия Фәннәр академиясе*
*Тел белеме институтының урал-алтай телләре бүлеге мөдире*

УДК 811.512.145

***К.М. Миңнуллин,***
***Р.Т. Сәфәров***

# ТАТАР ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ СҮЗЛЕКЛӘРНЕҢ ТОТКАН УРЫНЫ ҺӘМ ТАРИХИ ҮСЕШ ПЕРСПЕКТИВАЛАРЫ

Статья посвящена основным этапам развития татарской лексикографии. В хронологическом порядке рассмотрены и описаны рукописные и печатные словари татарского языка, определены предпосылки их составления. Отдельно рассмотрена типология наиболее значимых словарей татарского языка, проведена их классификация и описание.

**Ключевые слова:** татарский язык, лексикография, типология словарей, история татарской лексикографии

The article is devoted to the main stages of the development of Tatar lexicography. The handwritten and printed dictionaries of the Tatar language are reviewed and described in chronological order, the prerequisites for their compilation are determined. The typology of the most significant dictionaries of the Tatar language is considered separately, their classification and description are carried out.

**Keywords:** Tatar language, lexicography, typology of dictionaries, history of Tatar lexicography.

*Дәвамы. Башы алдагы санда*

**Тел белеме сүзлекләре.** Бер төркем сүзлекләрдә татар теленең сүзлек фондын төрле яклап тасвирлау максат итеп куела. Шундыйлардан этимологик, орфографик, орфоэпик, фразеологик сүзлекләрне, шулай ук синонимнар, антонимнар сүзлекләрен һ. б. күрсәтергә мөмкин.

Татар лексикографиясендә гамәли әһәмияте аеруча зур булганнардан орфографик һәм орфоэпик сүзлекләрне билгеләп китәргә кирәк. Алар – дөрес язылышка, дөрес әйтелешкә ярдәм итә торган белешмәлекләр. Татар теленең орфографик сүзлегенең беренче үрнәге М. Иманаев тарафыннан төзелгән һәм 1901 елда «Русско-татарский (орфографический) словарь к II части учебной книги «Русское слово» дигән исем белән басылып чыккан. 1914 елда «Татарча авыр сүзләр өчен орфографик сүзлек» дөнья күрә. XX гасыр башында матбугат битләрендә татар орфографиясе мәсьәләләре турында шактый көчле фикер алышулар, бәхәсләр бара. Шуннан соң икенче орфографик сүзлек 1927 елда гына нәшер ителә, 1927–1928 елларда ул берничә мәртәбә яңадан басыла. Чөнки бу чорда татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтү һәм ныгыту эшләре активлаша, бу исә аның нормаларын билгеләп халыкка җиткерү бурычын актуальләштерә. Аннан соңгы елларда И. Рәми (1928), И. Рәми һәм И. Кули (1930), Ш. Абай

(1933), И. Рәмиев (1934), М. Гыймадиев һ.б. (1941), Х. Хисмәтуллин һ.б. (1948) сүзлекләре билгеле. Әлеге вакыт аралыгында аларның шулай еш чыгарылуы татар алфавиты алышынып тору белән бәйле була.

Соңга таба да орфографик сүзлекләр, аеруча мәктәпләр өчен, даими чыгарылып килә. Бу эштә А.Х. Нуриева (1968, 1973, 1984, 1996) һәм аның автордашлары Ф.С. Фәсиев һәм М.И. Мәхмүтовларның (1983) актив һәм нәтиҗәле эшчәнлеге игътибарга лаек. Күп кенә редакторлар бүген дә әлеге авторларның 1983 елгы орфографик сүзлеген үрнәк итеп кабул итәләр.

1990 елларда латин графикасына күчү хәрәкәте орфография мәсьәләләренең тагын бер кабат куерып китүенә сәбәпче булды. Икенче яктан, үзгәртеп кору белән бәйле вакыйгалар, татар телен торгызу, үстерү, камилләштерү юнәлешендәге киң эшчәнлек, аның дәүләт теле статусын алуы нәтиҗәсендә телебездә күптөрле үзгәрешләр барлыкка килде, бу – яңа орфографик сүзлекләр төзелүгә китерде (2002, 2003).

Яңа реалияләр барлыкка килгән саен, аларны белдергән сүзләр дә телгә үтеп керә тора. Бу сүзләрнең язылышы беренче чиратта орфоэпик сүзлекләрдә чагылыш таба. Гасырлар чигендә татар теленә алынган яки үз нигезендә ясалган яңа сүзләрне эченә алган тулы типтагы орфографик сүзлек 2010 елда нәшер ителә, 2017 елда ул тулыландырып кабап бастырыла. Башкалардан аермалы буларак, әлеге сүзлеккә кушымта итеп күләмле морфологик-орфографик белешмәлек тә бирелә.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: хәзерге вакытта Ибраһимов исем. ТӘһСИ һәм КФУ галимнәре тарафыннан яңа орфоэпик сүзлек төзелә. Бу белешмәлектә моңарчы хәл ителеп бетмәгән, игътибардан читтәрәк кала биргән орфографик мәсьәләләр чишелешен табар дип көтелә.

Орфоэпик сүзлекләргә килгәндә, татар теле материалында алар күп түгел. Тәүге орфоэпик сүзлек 1995 елда Х. Сәлимов тарафыннан төзелеп дөнья күрә. Әлеге белешмәлеккә булган фикер-тәкъдимнәрне исәпкә алып, берникадәр үзгәрешләр кертеп һәм тулыландырып, шул ук автор 2004 елда яңа хезмәт – «Татар теленең орфографик-орфоэпик сүзлеге»н төзеп нәшер итә.

Ибраһимов исем. ТӘһСИдә соңгы елларда орфоэпия мәсьәләсе кабат игътибар үзәгенә алынды. Моның нәтиҗәсе буларак лексикография бүлегендә орфоэпик сүзлек төзелде. Хәзер бу сүзлек нәшер ителү этабында. Элегрәк чыккак белешмәлекләрдән соңгысы баш сүздән тыш аның әйтелеше, басымы, шулай ук аларның орфоэпик яктан авырлык тудыру ихтималы булган грамматик формаларын тутырып бирү белән аерыла.

**Фразеологик сүзлекләр.** Аларның беренче үрнәкләре, аларны төзүнең башлангыч тәҗрибәләре кульязма сүзлекләрдә үк чагылыш таба. Сүтезмәләр, мәкаль һәм әйтемнәр XVIII–XX гасыр башындагы күпсанлы үзөйрәткечләрдә шактый зур урын алган. Басма

сүзлекләрдә дә алар изречение (1835), выражение (1900, 1906), әйтелмә (1953) һ.б. сүзләр белән аталып эшкәртелә килгәннәр.

«Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре» дип аталган махсус фразеологик сүзлек беренче мәртәбә Л. Җәләй, Н. Борһанова һәм Л. Мәхмүтова тарафыннан төзелеп, 1957 елда бастырыла, ә 1959 елда Л.Г. Мәхмүтова һәм Н.Б. Борһановаларның «Русча-татарча фразеологик сүзлек» исемле хезмәтләре дөнья күрә. 1982 елда Г.Х. Әхәтов сүзлеге басылып чыга.

Татар фразеологиясенең иң тулы белешмәлекләреннән Н. Исәнбәт тарафыннан төзелгән ике томлы сүзлекне билгеләп үтәргә кирәк (I т. 1989, II т. 1990; икенче басмасы I т. 2000, II т. 2001). Анда 14000 фразеологик берәмлек урын алган. Күләме белән Н. Исәнбәтнекеннән берникадәр зуррак «Татарча-русча фразеологик сүзлек»-не 2001 елда Ф.С. Сафиуллина төзи, бу хезмәт 16000 берәмлекне үз эченә ала. Дөрес, бу сүзлекләргә авторлар фразеологизм булмаган кайбер ирекле сүзтезмәләрне кертүне дә кирәк тапканнар, шулай да әлеге ике сүзлек һәм татар теленең аңлатмалы сүзлекләре (1977, 1979 һәм 1981 елгы өчтомлык һәм яңа алтытомлыкның 2015, 2016, 2017, 2018, 2019 елларда нәшер ителгән биш томы) татар фразеологиясен өйрәнүчеләр өчен төп чыганак ролен үти.

Кыскача фразеологик сүзлекчәләр Ф.С. Сафиуллинаның күпсанлы үзөйрәткечләрендә, төрле сүзлекләрендә кушымта итеп бирелгән. Фразеология өлкәсендә күп хезмәт куйган Л.К. Бәйрәмованың да берничә сүзлеге бар: «В.И. Ленин теленең русча-татарча фразеологик сүзлеге» (1980), «Русча-татарча тематик уку-укыту фразеологик сүзлеге» (1991).

Яңа гасырда төзелгән лексикографик чыганаклар – тәрҗемәле сүзлекләр. 2006 елда Ф.Ф. Гаффарова белән Г.Г. Саберованың «Татарча-русча идиомалар сүзлеге» чыга. Бу белешмәлекнең керү теле татар теле булу аерым әһәмияткә ия.

2008 елда Казан университетында Е.Ф. Арсентьева редакциясендә 7,5 меңнән артык рус фразеологизмын берничә телгә тәрҗемә итеп тәкъдим иткән сүзлек әзерләнә. Бу күптелле «Русско-англо-немецко-турецко-татарский фразеологический словарь» төрле структуралы телләрдә идиомаларны чагыштыручылар өчен кыйммәтле чыганак була ала.

Ономастик сүзлекләр – тел байлыгының үзенчәлекле төркемен – ялгызлык исемнәрен чагылдыралар. Халыкның тарихы, мәдәнияте белән турыдан-туры бәйләнгән булганга күрә, кеше исемнәрен, сулыклар, таулар, торак пунклар һ.б.ның исемнәрен барлап җыю, эшкәртү, фәнни анализлау – тел белеменең кирәкле дә, әһәмиятле дә тармакларыннан берсе.

Ономастиканың махсус фән буларак үсеше, нигездә 50 нче елларга туры килә. Татар лексикографиясендә ул Г.Ф. Саттаровның «Татар исемнәре сүзлеге» белән башланып китә (1981). Алга таба да шул ук галим тарафыннан үстерелә, тирәнәйтелә бара, аның күпсанлы

укучылары да бу эшкә өлеш кертә. Соңга таба бу тармак Ф.Г. Гарипованың гидронимнар (1984, 1990), микротопонимнар (1992, 1993), топонимнар (2010) сүзлекләре һәм фәнни хезмәтләре белән баетыла.

Татар теле сүзлек хәзинәсенең аерым тармакларын чагылдыра торган аспектлы сүзлекләр үзләренә бер төркемне тәшкил итә. Алар шулай ук тел белеменең төрле юнәлешләрдә үсүен дә күрсәтәләр. Шундыйлардан сүз тезмәләре (1996, 1998, 2000, 2001, 2002), синонимнар (Ш.С. Ханбикова, 1962; Ш.С. Ханбикова, Ф.С. Сафиуллина, 1999, 2014), омонимнар (1997, 2004, 2015), антонимнар (1997, 2003, 2005, 2015) сүз ясалышы (1984, 2015), этимология (2001, 2015), тел белеме терминнары (1953, 1998, 2016) һ.б. сүзлекләрне атарга мөмкин.

**Диалектологик сүзлекләр**. Телнең байлыгын һәм алгарышын, телне тарихи аспектта өйрәнүне җирле сөйләшләрдәге материаллардан башка күз алдына китерергә мөмкин түгел. Диалект телдә әдәби норма булып китә алмаган үзенчәлекләр, борынгы сүзләр яки күренешләр сакланып килә, җирле шартларда ясалган лексемалар яши. Аларны җыеп лексикографик эшкәртүнең, диалектология генә түгел, тел белеменең башка тармаклары өчен дә, аеруча тел тарихы, халык тарихы, тарихи лексикология мәсьәләләрен хәл итүдә зур әһәмияте бар.

Татар сөйләшләренең төрле төбәкләрдәге лексик системалары сүзлекләрдә күптән чагылып килә. Мәсәлән, Казан гимназиясендә татар теле укыткан С. Хәлфинның 1785 елда төзегән мәшһүр сүзлеге (Казан федераль университетының сирәк китаплар бүлегендә саклана), нигездә, Казан тирәсе татарлары сөйләшен чагылдыра. И. Гиганов сүзлекләре (1801; 1804) татар теленең көнчыгыш диалектлары материалы нигезендә төзелгән. Н.П. Остроумов (1876), А.А. Воскресенский (1894) сүзлекләреннән керәшеннәр сөйләше белән танышырга мөмкин. Шунда ук Г. Биляевнең «Керәшеннәргә татар-гарәп сүзләрен аңлатыр өчен сүзлек»не (1929) дә өстәргә кирәк.

XX гасыр урталарында татар диалектларын фәнни тикшерү аеруча активлаша һәм төрле төбәкләргә уздырылган экспедицияләр барышында тупланган лексик материалны да лексикографик эшкәртү хаҗәте туа. Нәтиҗәдә 1948, 1953, 1958, 1961 елларда диалектологик сүзлекләр дөнья күрә.

Татар халык сөйләшләренең диалектологик атласын төзү өчен, татарлар яшәгән бөтен төбәкләр фронталь өйрәнелә, шул вакытта тупланган бай лексик материал нигезендә, элек чыккан сүзлекләрне дә файдаланып, «Татар теленең диалектологик сүзлеге» төзелә (1969). 1993 елда аның яңа материаллардан торган дәвамы дөнья күрә. Бу ике сүзлекнең принциплары күренекле телче галимә Л.Т. Мәхмүтова тарафыннан эшләнә һәм ул бөтен төрки дөньяда югары бәя ала. Себер диалектларының лексик фонды Д.Г. Тумашева тарафыннан тагын да баетып эшкәртелә һәм басылып чыга (1992). ТӘһСИ диалектологлары Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова һәм Т.Х. Хәйрет-

динова тарафыннан төзелеп, 2009 елда чыккан «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»н исә диалектологларның татар сөйләшләренең лексикасын туплау өлкәсендә башкарган күпьеллык хезмәтләрен чагылдырган, моңарчы дөнья күргән барлык диалекталь сүзлекләрнең материалын да, өр яңа берәмлекләрне дә эченә алган фундаменталь характердагы белешмәлек итеп караргa кирәк.

Болардан тыш, җирле сөйләшләрне чагылдырган һәм, башлыча, шул җирлектә яшәгән тикшеренүчеләрнең сүзлекләре аерым игътибарга лаек. Аларның кайберләре һаман фәнни әйләнешкә кереп китмәгән. Андыйлардан Н.Ш. Зимасовның «Барда сүзлеге (Барда татарлары сөйләшенең диалектологик сүзлеге)» (2005), И.Ә. Гафаровның «Мишәрләр. Тарих һәм тел» (2011, сүзлек өлеше бар) кебекләрне билгеләп үтә алабыз. Чиләбе өлкәсендә яшәгән нагайбәкләрнең лексикасын чагылдырган сүзлекләр дә бар: О.И. Барышникованың «Русско-нагайбакский словарь. Нагайбакща-урысща сузлег»е (2015), П.М. Минеев һәм В.А. Минееваларның «Русско-нагайбакский словарь. Нагайбакско-русский словарь. Русско-нагайбакский тематический словар»е (2017). Татар тел белемендә нагайбәк сөйләше татар теленең урта диалектының бер сөйләше дип карала, шуңа күрә әлеге сүзлекләрдән дә файдаланып була дип саныйбыз.

**Белешмә сүзлекләр.** Халык тормышындагы алга китеш, фән һәм техника, халык хуҗалыгы өлкәләрендәге алгарыш һәртөрле белешмә сүзлекләргә дә ихтыяҗ тудыра. Халыкның тормыш-көнкүреш дәрәҗәсе генә түгел, аның рухи мәдәнияте үсү дә төрле тармаклар, төрле халыклар, төрле илләр белән кызыксыну да тиешле белешмәлекләр булуны таләп итә.

Сүзлекләр дөньясы туып үсеп килгәндә үк төрле сүзлекләрдә, тәрҗемә (тәрҗемә үзе дә белешмә!) белән генә чикләнмичә, кечкенә күләмле белешмәлекләр дә бирелә торган булган.

Чын мәгънәсендәге белешмәлекләр төзү өчен, теге яки бу тармакның фәне тиешле югарылыкта үскән булырга тиеш. Шуңа күрә белешмә сүзлекләр чагыштырмача соңрак барлыкка киләләр. Беренче белешмә сүзлек ислам дине турында төзелгән (С.М. Мәһдиев, 1978). 1981 елда аның төзәтелгән икенче басмасы дөнья күрә.

Үзгәртеп кору чорында төгәл фәннәр буенча белешмә сүзлекләр чыгарылды. Мәсәлән, физика, химия технологиясе буенча (Р.С. Сәйфуллин, Г.Г. Хисамеев, 1995), математикадан (И.Г. Галәветдинов һ.б., 1997) белешмә сүзлекләр төзелгән.

Күп кенә терминологик сүзлекләр аңлатмалар белән төзелгән, ягъни аларны да белешмә сүзлекләр рәтендә караргa мөмкин. Мәсәлән, ветеринария медицинасы терминнарының (ред. Ф.Г. Нәбиев, 2004), агрохимия һәм туфрак белеме (М.Ю. Гыйлаҗев, С.Г. Мортазина, 2003) терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлекләре һ.б.

Шулай ук «Татарский энциклопедический словарь» (1999), «Татар теленең энциклопедик сүзлеге (2003) дә – монументаль характердагы бай белешмәлекләр.

**Мәктәп сүзлекләре.** Сүзлекләр арасында мәктәп сүзлекләрен, уку-укыту эшчәнлегенә юнәлтелгән кайбер башка сүзлекләрне аерып тасвирларга мөмкин. Биредә бер әһәмиятле моментны ассызыклап үтергә кирәк: укучылар өчен сүзлекләр төзүнең дә зур тарихы бар. XIX–XX гасыр башларында уку-укыту максаты белән чыгарылган күпсанлы үзөйрәткечләр, аларда бирелгән сүзлек-сүзлекчәләр – мәктәп сүзлекләренең башлангыч үрнәкләре ул. Мәсәлән, С. Кукляшев сүзлеге (1859) һ.б. Аларда акрынлап эшкәртелә һәм камилләшә килгән принциплар хәзерге мәктәп сүзлекләрен төзү өчен ышанычлы нигез булды. 1901 елда ук М. Иманаев тарафыннан мәктәп һәм мәдрәсәләрдәге, башкорт мәктәпләрендәге рус класслары өчен русча-татарча орфографик сүзлек әзерләнә, ул сүзлек «Русское слово» дигән дәреслеккә кушымта буларак төзелә.

К. Насыйриның русча-татарча, татарча-русча сүзлекләре дә, беренче чиратта, рус яки татар телен өйрәнергә теләүче яшь буынны күздә тоткан. Шундыйлардан тагын Габбас Сәйфи (1917) сүзлеген күрсәтергә мөмкин. Соңрак Ф.А.Дәүләткилдеева төрек-татар мәктәпләре өчен русча-татарча лөгать (1929) төзи.

Мәктәп сүзлекләренең зур өлеше үзләренең төзелү принциплары буенча гадәттәге сүзлекләрдән нигездә аерылмый. Бу бигрәк тә тәрҗемәле сүзлекләрдә шулай, алар бары сүзлектә теркәлгән лексик материалның күләме махсус рәвештә чикләнгән булу белән генә үзенчәлекле: Р.С.Газизов. Русча-татарча сүзлек (1948; 1951; 1955); М.И. Мәхмүтов. Русча-татарча мәктәп сүзлеге (1967, 1975, 1989), И.А. Абдуллин һ.б. Татарча-русча уку-укыту сүзлеге (1992); Ф.С. Сафиуллина. База сүзлеге (1997; дәреслеккә кушымта буларак бирелгән, 1998 елда кабат басылган); Ф.Ә. Ганиев, И.А. Абдуллин һ.б. Татарча-русча уку-укыту сүзлеге (1993); А.Х. Алеева. Татарско-русский словарь для начальных школ (1997); Ф.С. Сафиуллина, К.С. Фәтхуллова. Татарча-русча, русча-татарча мәктәп сүзлеге (2014) һ.б. Шулар арасында күптелле сүзлекләр дә бар: Немецча-русча-татарча мәктәп сүзлеге (1970) һ.б.

Кем өчен төзелүеннән чыгып, мәктәп сүзлекләренең сүз материалы, аларны урнаштыру һәм баету ысуллары да төрләнә бара, һәртөрле иллюстрацияләр кулланыла. Мәсәлән, Ф.Ф. һәм Ч.М. Харисовларның (1995), Ф.С.Сафиулинаның (1998) иллюстрацияләнгән татарча-русча сүзлекләре, укыту өчен русча-татарча тематик фразеологик сүзлек (1991), Ф.Ф.Харисовның аннотацияле татарча-русча мәктәп сүзлеге (1997), башлангыч мәктәпләрдәге рус телле балалар өчен лексик минимум (Ф.Ю. һәм Г.Ф. Юсуповлар, 1999) һ.б. укытучылар һәм укучылар тарафыннан актив файдаланыла.

2013 елда махсус мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлек тә дөнья күрде. Бу «Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге» укыту предметларының төп төшенчәләрен эченә ала, андагы аңлатмалар укучылар өчен җайлаштырылып киңрәк, аңлаешлырак итеп тәкъдим ителә.

**Терминологик сүзлекләр.** Терминнар туу, терминнар системасы барлыкка килү шул термин караган тармак үскәндә, аның турында фән туган һәм формалашкан очракта гына мөмкин. Татар тел белемендә терминнарга караган беренче хезмәтләр К. Насыйри (XIX гасыр азагы) исеме белән бәйле. Аның үсемлекләр, математика, химия, медицина буенча терминнарга, аларның ясалыш мәсьәләләренә багышланган хезмәтләре бар. 1904 елда Каюм Насыйри «Рус хоруфы һиҗасы үзрә мөрәттәб лөгать китабы» (Рус телендә фәнни термин буларак кулланылган һәм татар теленә кергән сүзләрне дә өстәп төзелгән русча-татарча сүзлек) исемле хезмәт чыгара. Ул берничә мәртәбә басыла. Галим шул чорда кулланылып килгән гарәп һәм фарсы теленә нигезләнгән терминнарны татар теленең үз сүзләре яки киң катлам халыкка таныш булган гарәп-фарсы сүзләре белән алыштырырга кирәк дип язып чыга, күп кенә тәкъдимнәр кертә, китапларында кечкенә-кечкенә сүзлекчәләр бирә. Шулай итеп, берничә әһәмиятле тармакка хас терминнар төзүнең аерым тәҗрибәләре татар лексикографиясендә XIX гасыр азакларында ук башланган.

Терминнар төзү, бастырып чыгару эше 1917 елгы Октябрь революциясеннән соң, Татарстан хөкүмәте формалашып, Казанда Гыйльми үзәк төзелгәч һәм аның каршында Татар телен гамәлгә ашыру комиссиясе эшчәнлеге башлангач, аеруча җанланып китә. Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую, аның вазифалары киңәю, ана телен, мәктәпләрдә генә түгел, төрле урта һәм югары уку йортларында укыта башлау, фән һәм мәдәният өлкәсендәге алгарыш һәм төрле тармаклар терминологиясен үстерүгә омтылыш – болар барысы да татар лексикографиясенең үсеп китүенә, аеруча терминнар системаларын чагылдырган сүзлекләр төзелүгә зур этәргеч була. 20–30 нчы елларда сәяси, математик, юридик, физик һәм астрономик, химия, авыл хуҗалыгы атамалары сүзлекләре дөнья күрә. Мондый күләмле эш башкаруда махсус үзәк оештыруның роле зур була. Сүзлекләр төзүне киңәйтергә, фәнни нигезгә куярга реаль мөмкинлекләр туа, җирлек барлыкка килә.

Терминологик сүзлекләр төзү өлкәсендә 70 нче елларда да берникадәр җанланыш күзәтелә. Мәсәлән, химия (1978), физика (1972; 1981), биология (1972, 1985), техника терминнары (1963), математик терминнар (1970), авыл хуҗалыгы (1971), экономика (1972), астрономия (1974), юриспруденция (1974, 1975), география (1977) өлкәләре буенча махсус сүзлекләр дөнья күрә.

XX гасырның соңгы чирегендә җәмгыятебездәге үзгәрешләр, дәүләт теле статусы кайтарылу нәтиҗәсендә татар теленең кулланылыш даирәсе киңәю, тел төзелешендәге җанлану һәм башка кайбер факторлар терминнар булдыру өлкәсендә яңадан актив эшчәнлек башлануга да сәбәпче була. Татар теленең фән теле, фәнни-техник прогресс теле буларак кулланылышы киңәя төшә. Бу исә фән һәм техниканың бөтен тармаклары буенча моңа кадәр булган терминологик сүзлекләрне барлап, яңартып, баетып чыгу, яңаларын төзү ихтыяҗын

тудыра. Мондый эш берничә юнәлештә алып барыла: сүзлек-минимумнар чыгару, терминологик сүзлекләр төзү, төрле фәннәр буенча татар телендә дәреслекләр төзү.

Кыска вакыт эчендә иң еш кулланылышлы сүзләрне, терминнарны оператив рәвештә кулланылышка кертүдә лексик минимумнар чыгару әһәмиятле роль уйный. Күп кенә алынма терминнарның татарча эквивалентларын булдыру юнәлешендә байтак эзләнүләр, беренче уңышлар нәкъ менә аларда чагылыш таба. Сәнәгать, авыл хуҗалыгы, мәдәниятнең 30лап тармагы буенча лексик минимумнар басылып чыкты. Аларны төзү эше татар терминологиясенә карата яңадан зур кызыксыну уяткан әһәмиятле факторларның берсе була.

80 нче елларның уртасыннан башлап 90 нчы елларда татар теленең әлегә тулысынча ачылмаган һәм эшкә җигелмәгән фәнни терминология ясау мөмкинлекләрен барлау дулкыны яңадан кузгала. Бу чорда җәмгыятебездә кискен сәяси һәм иҗтимагый үзгәрешләр, мәдәни вакыйгалар, милләтләргә һәм телгә карата яңа сәясәт, татар теленең дәүләт теле статусы алуы, «Татарстан халыклары телләре турында»гы Татарстан Республикасы законы игълан ителү һәм аны гамәлгә ашыру буенча Программа кабул ителү татар теленең кулланылыш мөмкинлекләрен киңәйтүгә юл ачты, аның фән теленә әверелүе өчен уңай шартлар тудырды. Нәтиҗәдә 80–90 нчы елларда терминологик сүзлекләр төзүнең гаять көчле дулкыны башлана. Шуның белән бергә, шушы ук чорда Татарстан хөкүмәте тарафыннан Татарстан Республикасы халыклары телләре турындагы Законны гамәлгә ашыру Комитеты оештырыла, аның каршында төрле юнәлешле комиссияләр төзелә (шулардан берсе — терминологик комиссия). Шулай итеп, татар теленең фәнни терминологик системасын югары дәрәҗәдә төзү эше аларны бастыру өчен финанс мөмкинлекләре булдыру җайга салына. Нәтиҗәдә әлеге чорда бу өлкәдә шактый зур уңышларга ирешелә.

Соңгырак елларда нәшер ителгән терминологик сүзлекләрнең төзелеш принциплары да үзгәрә. Типологик планда тәрҗемәле сүзлекләрдән тыш, аларның кайберләре берьюлы һәм тәрҗемәле, һәм аңлатмалы сүзлек итеп төзелә. Мәсәлән, «Финанс-икътисад һәм юридик терминнар. Аңлатмалы сүзлек» (К.М. Гарифуллин һ.б., 1996), «Русско-татарский географический толковый словарь» (Җ. Хөсәенов, 2000) кебек хезмәтләр, шундый ук характердагы агрохимия һәм туфрак белеме (М.Ю. Гыйлаҗев, С.Г. Мортазина, Ф.Ф. Гаффарова, 2003), медицина (М.М. Гыймадиев, Н.Х. Әминов, К.Ш. Зыятдинов, 2003), химия (Г.Г. Хисамиев, А.И. Нарбеков һ.б., 2004), география (А.С. Тайсин, Г.В. Сонин һ.б., 2010; З.А. Хөсәенов, 2017), биология (Ф.Г. Ситдыйков, Р.К. Зәкиев, 1998) терминнарының русча-татарча сүзлекләрен санап үтәргә була. Мондый сүзлекләрнең, бер яктан белешмәлек буларак зур әһәмияте булса, икенче яктан махсус тармак атамаларының шул фән телендә аңлатылуы татар теленең фән теле буларак гамәлдә икәнен дә ачык күрсәтә.

Тел турындагы законны гамәлгә ашыру төркеме фән һәм техника, авыл хуҗалыгы, мәдәният, икътисад, гомумән тормышның бөтен өлкәләренә (мәсәлән, сәнгать, архитектура терминнары эшләнмәгән хәлдә иде) караган термин системаларын булдыру, аларны бөтен тулылыгы белән эшкәртү-камилләштерү максатын куя. Әйтергә кирәк, бу юнәлештә гаять зур эш башкарыла. Моны түбәндәге исемлек тә бик ачык күрсәтә: төзелеш (1992, 1996), тарих (1993, 2001, 2006), медицина (1994, 1995, 2000, 2003, 2008), юриспруденция (1996), загс һәм ритуаль хезмәт күрсәтү (1994), мәдәният (1995, 1997), авыл хуҗалыгы (1995), сәүдә (1995), физика (1995, 1996, 1996), урман хуҗалыгы (1995, 1997), көнкүреш хезмәте (1995), музыка (1995, 1997, 2003, 2007), нефть сәнәгате (1996, 2004), транспорт (1996), сәясәт (1997), химия (1996, 2000, 2001, 2002, 2004), биология (1995, 1996), мәгариф (1997), математика (1997, 2013, 2014), эшмәкәрлек (1998, 1999), физик тәрбия (1998), китапханә, нәшрият (1998), тел белеме (1998, 2005, 2014, 2006), әдәбият белеме (2007), икътисад (1999, 2000, 2014), компрессорлар (1999), педагогика һәм психология (1999, 2015), гигиена (1999), хәрби өлкә (2000, 2017), техника (2000, 2014), география (2000, 2010), дәүләт идарәсе (2001), информатика (2001), фәлсәфә (2003), агрохимия һәм туфрак белеме (2003), ветеринария (2004), сәнгать (2004, 2011), агроэкология (2008), эш кәгазьләре теле (2008), ветеринария (2010), офтальмология (2011), спорт терминнары (2014), геодезия (2014), компьютер терминнары (2015), политехника (2017) һ.б.ш.

Терминологик сүзлекләр төзү эшчәнлегендә тагын бер үзенчәлекле юнәлеш күзәтелә: аларда күптелле тәрҗемәле сүзлек алымы да шактый файдаланыла. 1886 елда ук инде Казан университеты типографиясендә «Өч йөз җитмешләп дәва үләннәренең исемнәре русча, латинча, мөселманча» дигән терминологик сүзлек басылып чыккан. 1931 елда анатомия һәм гистология буенча латинча һәм татарча атамалар сүзлеге дөнья күрә. В.И. Кафиятуллина инглизчә-татарча-русча, немецча-татарча-русча төзелеш терминнары сүзлекчәләре бастырып чыгара (1996). З.М. Вәгыйзова һәм Г.Ю. Даутов, О. Аслан белән берлектә инглизчә-русча-татарча физика терминнары (1996), М.Б. Хәйруллин һәм Л.Н. Донина немецча-русча-татарча сәнгать терминнары (2004), информатика һәм мәгълүмат технологияләре терминнары: инглизчә-татарча-русча сүзлек (2006), татарча-русча-латинча кош атамалары (2018), балык атамаларының татарча-русча-латинча аңлатмалы сүзлекләрен (2019) төзиләр.

Мондый типтагы сүзлекләр төзүнең зур әһәмияте бар. Чөнки чит тел терминнарын турыдан-туры татарчага тәрҗемә итү еш кына татарча дөрес эквивалентларны табарга ярдәм итә.

Күрсәтелгән сүзлекләр дә, нигез принциплары ягыннан, берникадәр төрлелек күзәтелә. Әмма аларның барысы өчен дә уртак төп принцип куела: русча терминның татарча эквивалентын табарга-булдырырга тырышу. Бу эштә иң элек татар теленең үз

мөмкинлекләрен мөмкин кадәр тулы файдалану максаты торырга тиеш. Бары шуннан соң гына алынма термин үзе дә кабул ителергә мөмкин. Әлбәттә, бер телдә дә интернациональ терминнардан качу максат итеп куела алмый, әмма монда чама хисе истә тотылырга тиеш.

Гомумән, XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы дәвере сүзлекләр төзү өлкәсендә зур нәтиҗәләр белән аерылып тора. Төрле елларда әзерләнгән библиографик күрсәткечләрдән күренгәнчә [Якупова, 1988; Миңнуллин, Вәлиуллин, 1997; Хәкимҗан, Хәйретдинова, 1998; Каримуллина и др., 2017], татар лексикографиясенең басма сүзлекләр тарихы дәвамында (1801–2019) 400ләп сүзлек басылып чыккан.

Терминологик сүзлекләр – телнең үзенчәлекле хәзинәсе. Алар – аерым тармаклар өчен хас булган махсус төшенчәләр җыелмасы. Көчле резервлары, бай чаралары булган тел генә фән теле була ала. Соңгы елларда чыккан сүзлекләрдә татар теленең фән теле булырлык потенциалы бай һәм мөмкинлекләре зур булуы тагын бер мәртәбә расланды. Халык хуҗалыгының, фән һәм техниканың барлык өлкәләре буенча да терминологик сүзлекләр төзелү һәм дөньяга чыгарылу шул турыда сөйли.

Тагын шуны аерым ассызыклап үтми мөмкин түгел: хәзерге чорда татар фәнни терминологиясен, аның теоретик мәсьәләләрен үстерү һәм камилләштерүгә бер төркем күренекле галимнәр зур өлеш кертте: Ф.С. Сафиуллина, И.М. Низамов, Г.Ю. Даутов, К.М. Гарифуллин, М.М. Гимадиев, М.М. Миннибаев, А.К. Юлдашев, В.Ш. Фәтхуллин, Р.А. Шакиров, Н.Ш. Мифтахова, Г.Г. Хисамиев, С.Н. Тимергалиев, К.Ф. Әмиров, С.Г. Мортазина, К.Р. Галиуллин, Р.Ә. Шакирҗанов һ.б. Аеруча Ф.А. Ганиев, Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова, Ф.И. Таһирова, И.И. Сабитова, А.Ә. Тимерханов, Р.Т. Сәфәров, Э.И. Сафина, О.Н. Галимова кебек профессиональ практик лексикографлар исә, еллар буе тупланган тәҗрибәне дәвам иттереп, күләмле, академик типтагы сүзлекләр әзерләүдә актив катнашты һәм катнашып килә. Әлеге галимнәр үз инициативалары белән, зур тырышлык һәм иҗади көч куеп, катлаулы гуманитар һәм техник фәннәр терминнарын югары фәнни дәрәҗәдә эшлиләр.

Шулай итеп, татар тел белемендә сүзлекләр төзү эшчәнлегенең бай һәм дәвамлы тарихы бар. Сүзлекләр үзләренең максаты ягыннан да, төзелеш принциплары белән дә күп төрләргә аерыла. Сүзлек төзү эше кульязмадан басмага, гади исемлектән алфавитлыга, грамматик тасвирлауның камилләшүенә таба үсештә байый, фәнни-теоретик яктан тирәнәя килгән. XIX гасырда ук татар тел белеменең лексикография тармагы формалашкан, аның традицияләре урнашкан, принциплары ачыкланган. XX йөздә, аеруча татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую чорларында – 20 нче һәм 90 нчы елларда – татар лексикографиясе аеруча көчле үсеш кичерә.

## Әдәбият

*Каримуллина Р.Н., Галиуллин К.Р., Каримуллина Г.Н.* Государственные языки Республики Татарстан в словарях: аннотированный библиографический указатель (1951–2015). Казань: Магариф – Вакыт, 2017. 124 с.

*Миңнуллин К.М., Вәлиуллин Р.Н.* Татар теле – сүзлекләрдә: библиографик күрсәткеч. Казан: Мастер Лайн, 1997. 39 б.

*Хәкимҗан Ф.С., Хәйретдинова Т.Х.* Татар теле белеме библиографиясе (1981–1997). Казан: ТДГПИ, 1998. 204 б.

*Якупова Г.К.* Библиография по татарскому языкознанию (1778–1980). Казань: Татар. кн. изд-во, 1988. 134 с.

***Миңнуллин Ким Мөгаллим улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры*

***Сәфәров Ринат Таһир улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге мөдире*

УДК 81’38; 801.6

*А.Ф. Юсупов*

# 1920–1950 ЕЛЛАР ТАТАР ШИГЪРИЯТЕНДӘ ФОНЕТИК-СТИЛИСТИК ЧАРАЛАР: ТӨРЛӘРЕ ҺӘМ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Статья посвящена изучению лингвостилистических особенностей татарской поэзии 1920-1950 гг. и выявлению стилеобразующих свойств фонетических средств; в ней раскрываются художественно-эстетические особенности таких фонетических средств как *аллитерация, ассонанс, эвфония*, *элизия, синкопа, аферезис, апокопа и др.*, участвующих в семантико-стилистической организации поэтических текстов. Утверждается, что в языке поэтических произведений они употребляются в тесной связи с установками метрики, закономерностями рифмы и ритма, и правилами стихосложения.

**Ключевые слова:** фонетическая стилистика, фонетико-стилистические средства, аллитерация, ассонанс, эвфония, элизия, синкопа.

The article is devoted to the study of linguistic-stylistic features of Tatar poetry of 1920–1950s and the identification of style-forming properties of phonetic means; it reveals the artistic and aesthetic features of such phonetic means as alliteration, assonance, euphony, elisia, syncope, apheresis, apocope, etc., participating in the semantic-stylistic organization of poetic texts. It is argued that in the language of poetic works they are used in close connection with the settings of the metric, the laws of rhyme and rhythm, and the rules of versification.

**Keywords:** phonetic stylistics, phonetic-stylistic means, alliteration, assonance, euphony, elisia, syncope.

Шигъри сөйләмнең сәнгатьчә бай, югары поэтик яңгырашлы булуында, дөрес һәм матур әйтелешендә төрле фонетик-стилистик чаралар әһәмиятле роль уйный. Бу очракта аеруча «сөйләмнең шигъри яңгырашына, иҗек төзелешенә, авазларның әйтелешенә, рифма, ритм, басым мәсьәләләренә, аларның кулланылыш үзенчәлекләренә игътибар ителә... Теге яки бу төшенчәләрне тиешле эмоциональ рухта бирү, сөйләмдә югары яңгырашка һәм сәнгатьлелеккә ирешү өчен, эчтәлеккә туры китереп, күптөрле фонетик-стилистик чаралардан файдаланыла» [Хаков, 1999, б. 168].

Төрки-татар әдәбияты тарихында поэзия аеруча мөһим урын тота һәм әдәби процесста булган үзгәрешләр, иң беренче чиратта, шигъри әсәрләрдә чагылыш табалар [Юсупов, Юсупова, 2019, с. 261]. XX гасырның беренче яртысы татар шигърияте теле фонетик-стилистик чараларның кулланылыш үзенчәлеге, аларның байлыгы һәм төрлелеге ягыннан аеруча кызыклы. XX гасыр башы татар шигъриятендә аваз кабатланулары һәм фонетик стилистиканың аерым мәсьәләләре Г. Тукай, Дәрдмәнд, С. Рәмиев әсәрләре мисалында Х.Х. Кузьмина [Кузьмина, 2006] һәм Г. Гыйманова [Гыйманова,

2008] тарафыннан өйрәнелә. Сүзләрнең әйтелешенә (яңгырашына) нигезләнгән сурәтләү алымнарының байлыгы ягыннан 1920–1950 еллар татар шигърияте дә үзенчәлекле кабул ителә, мондый төр поэтик эзләнүләр аеруча Һади Такташ, Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Хәсән Туфан, Әхмәт Фәйзи иҗатларында күзәтелә һәм әсәрләрнең теле баюга, үзенчәлекле шигъри сөйләм формалашуга алып килә. Мәкалә чикләрендә әлеге шагыйрьләр тарафыннан иҗат ителгән шигъри әсәрләрнең тел-өслүб үзенчәлекләрен өйрәнүгә игътибар юнәлтелә, фонетик-стилистик чараларның кулланылыш үзенчәлекләре, фонетик чараларның сурәт тудыру алымнары һәм мөмкинлекләре үзәккә алына, аерым алганда, 1920–1950 еллар татар шигърияте телендә *аваз кабатланулары, аваз кыскарулары һәм авазлар өстәлү* кебек күренешләр тикшерелә.

**Аваз кабатланулары.** «Шигъри сөйләм теле, беренче чиратта, авазлар составы ягыннан оеша. Фонетик элементларның билгеле бер тәртипкә салынган булуы шигъри әсәрдәге сәнгати уйланмага буйсынган үзенчәлекле мәгънәне барлыкка китерә. Шигъри текстны авазлар ягыннан оештыруда төп принцип булып, кабатлау принцибы тора. Әлеге күренеш еш кына халык авыз иҗатында, матур әдәбиятта, аерым алганда, шигъриятә сурәт тудыру, әсәрнең аһәңлелеген, тәэсир көчен арттыру өчен кулланыла» [Гыймранова, 2008, б. 101–102]. Билгеле булганча, фәнни әдәбиятта аваз кабатлануларның берничә төре аерып куела: *аллитерация, ассонанс һәм эвфония.*

**Аллитерация** – билгеле бер тартык аваз кергән сүзләрне күбрәк кулланып, сәнгатьле сөйләмгә үзенчәлекле яңгыраш бирү алымы... Аллитерациядә һәркемгә диярлек иң аңлаешлы һәм иң гадие – табигать күренешләрен яки җан ияләренең хәрәкәт-яшәешләрен аваз-төс охшашлыгы аша чагылдыру [Курбатов, 2002, б. 184].

Мондый төр эзләнүләр Ә. Фәйзи иҗатында еш кулланылыш таба. Мисал өчен, «Җөйче» шигырендә [т], [ж] авазлары актив кулланылып, өстәмә эффект тудыруга юнәлтелә һәм тегүче турындагы текстта тегү машинасының тавышы булып яңгырый:

*Җырлый-җырлый,*
*Кәтүк зырлый,*
*Табан тырный,*
*Табан шуа,*
*Җөйне куа,*
*Кырылдата, тырылдата, та, та! та! та!*
(Ә. Фәйзи. «Җөйче», 1927)

Әлеге шигырьдә билгеле бер авазларның актив кулланылышы стилистик яктан сурәтнең тәэсир көчен тагын да арттыруга юнәлтелә, шул ук вакытта лирик герой күңелендәге икеләнү, шомны көчәйтүгә хезмәт итә.

Ә. Фәйзинең «Бюрократ эпипәсе» шигыре исә [с] һәм [к] тартыкларының кабатлануына нигезләнеп төзелә:

*Килеп керде секретарь,*
*Сиңа, диде, секрет бар,*
*Срочно просит прокурор,*
*Хет җәяү, хет сикереп бар!*
(Ә. Фәйзи. «Бюрократ әпипәсе», 1929).

Бу очракта аваз кабатлануы сатирик тонны көчәйтү юлында файдаланыла һәм лирик герой фикерен тирәнәйтүгә юнәлтелә. Ф. Кәримнең шигъри әсәрләрендә исә [з] һәм [т] авазлары кабатланып килеп, образ-сурәт тудыру вазифасын башкара, әлеге авазларның актив кулланылышы текстның укучыга тәэсир итү көчен арттыра, аңа аһәңлелек өсти, тамчы таму эффектын тудырып, сурәтлелекне тирәнәйтә:

*Яз, яз, яз җитә,*
*Тәрәзәне ачтылар,*
*Тып, тып, тып итә*
*Эре-эре тамчылар*
(Ф. Кәрим. «Яз җитә», 1936)

Билгеле булганча, аллитерация ике юнәлештә: «*горизонталь* һәм *вертикаль* юнәлешләрдә була» [Курбатов, 2002, б. 184]. Алдагы мисалда горизонталь юнәлештәге аллитерация күзәтелә, ягъни аерым тартыкларның кабатлануы шигырь юлларында урын ала. Вертикаль аллитерация булганда, шигырьнең һәр юлы саен билгеле бер иҗек яки авазның кабатланып килүе күздә тотыла. Бу төр аллитерация *анафора* яки *эпифора* рәвешен алып, үзенә бер төрле рифма барлыкка китерә. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, аваз кабатлануына нигезләнгән мондый сурәтлелек Һ. Такташ иҗатында актив кулланылыш таба. Мисал өчен, «Антым» шигыре [к] тартыгы чиратлашуына нигезләнеп төзелә:

*Кычкырам:*
*Килегез, әй, адашкан,*
*Канга баткан мәзлум ил халкым!*
(Һ. Такташ. «Антым», 1920).

Бу очракта [к] тартыгының чиратлашуы канга-кан барган көрәш елларын сурәтләүгә юнәлтелә.

**Ассонанс.** Эмоциональ поэтик сөйләмгә ирешү өчен, бер үк сузык авазларның кабатланып килүе һәм ешрак кулланылуы шушы алымга керә [Хаков, 1999, б. 169]. Тикшеренүләрдән күренгәнчә, мондый төр аваз кабатланулары өйрәнү үзәгенә алынган шагыйрьләр арасында М. Җәлил иҗатында актив. Мәсәлән:

*Соңгы тамчы каным тамса тамсын,*
*Тик антыма таплар кунмасын.*
(М. Җәлил «Кичер, илем!», 1942)

Әлеге мисалда [а] авазлары күбрәк кулланылса, «Ирек шагыйре сүзләре» шигырендә исә [а], [ө] һәм [и] авазларының чиратлашуы урын ала, шуның аша автор үзенең сәяси позициясен төгәлләштерә, омтылышларын декларатив төстә белдереп чыга:

*Яшим халык өчен, көчләр табам мин,*
*Халык өчен һаман алга барам мин*
(М. Җәлил. «Ирек шагыйре сүзләре», 1920)

**Эвфония.** Бер үк төрле сузык яки тартык авазларның, аваз тезмәләренең күбрәк кулланылуы нәтиҗәсендә, сөйләмнең югары һәм экспрессив яңгырашы барлыкка килә [Хаков, 1999, б. 170]. Мәсәлән, М. Җәлил күп кенә шигырьләрендә бер үк сүзләрне, иҗекләрне кабатлау ярдәмендә дә югары яңгырашка, сәнгатьлелеккә ирешә:

*Ирлек сорый көрәш егетеннән,*
*Ирешер өчен бөек өмиткә,*
*Ирек китәр, качсаң ирлектән,*
*Ирлек белән иреш ireккә.*
(М. Җәлил. «Батырлык турында», 1943)

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, шигъри әсәрләр телендә аваз кабатлануларының аерым төрләре (аллитерация, ассонанс, эвфония) башка стилистик фигуралар белән бергә кулланылып, бер-берсенә керешеп китә һәм шигъри текстлар телендә үзенчәлекле синтез күренешен формалаштыра. Өйрәнү объекты итеп алынган шигъри текстлар телендә аваз кабатлануларының аеруча *анафора* һәм *эпифора* алымнары белән үрелеп китүе үзенчәлекле. Берничә стиль чарасының бергә кулланылышы, аларның синтезы әсәр тукымасына салынган мәгънәне көчәйтүгә хезмәт итә, текстны тел-стиль ягыннан бизи һәм баета.

Бер үк сүзләрнең һәм авазларның кабатлануы Ә. Фәйзи иҗатында үзенчәлекле яңгыраш таба, аның күп шигырьләрендә строфаның һәр юлы бер үк сүзгә яки сүзләр тезмәсенә башлана:

*Без килербез, тимә,*
*Без көләрбез, көймә,*
*Безнең көлү әнәсе бар чорда.*
(Ә. Фәйзи. «Динамо һәм примус», 1930)

Әлеге күренеш Һ. Такташның шигъри текстларына да хас, үзенең фикерләрен укучыга үтемле итеп җиткерү юлында шагыйрь еш кына авазларны, иҗекләрне кабатлау алымына мөрәҗәгать итә. Алдагы мисалда юл башы рифмасы (анафора, вертикаль аллитерация) юл азагы рифмасы белән (эпифора) берлектә кулланыла:

*Бер җирдә юк андый ак каеннар,*
*Бер җирдә юк андый урманнар,*
*Бер җирдә юк камыш сабаклары –*
*Андагыдай шаулый торганнар…*
(Һ. Такташ «Мокамай», 1929)

Һ. Такташның «Урман» шигыре анафора алымы кулланылышына мисал булып тора. Әсәрдә «анда» сүзенең һәм [а] авазының юл башында кабатланып килүен күрәбез:

*Анда давыл симфониясе,*
*Анда үзенә башка тавышлар,*
*Анда кыргый кошлар,*
*Ач бүреләр җырлый,*
*Анда шаулый күлләр, камышлар…*
(Һ. Такташ. «Урман», 1924)

Шигырь юллары, сүзтезмә яки җөмләләр ахырында сүзләрнең кабатлануы *эпифора* дип атала. Ф. Кәрим иҗатында да юл ахырында сүз һәм аваз тезмәләре кабатлануларын күрергә мөмкин:

*Кемгә сөйлим серләремне,*
*Йөрәгем ялкын кебек.*
*Ялкынланган йөрәгемә*
*Берәү бик якын кебек;*
(Ф. Кәрим. «Кемгә сөйлим серләремне», 1938)

Бу алым әсәргә музыкаль яңгыраш бирә, эмоциональлекне арттыра. Шунысы үзенчәлекле: мондый шигъри текстлар еш кына көйгә салынып, популяр җырга да әверелеп китә.

**Аваз кыскарулары.** XX гасырның беренче яртысы поэзиясендә шигырь үлчәме таләбе, рифма-ритм, метрика кагыйдәләре нигезендә янәшә килгән сүзләрнең берсе сузык авазга тәмамланып, икенчесе сузык аваз белән башланганда, аерым очраклар сүз уртасында һәм ахырында да, кайбер авазлар йотылырга яки төшеп калырга мөмкин. Тикшерелә торган чор поэзиясе телендә еш очрый торган фонетик чараларның тагын берсе – ***элизия*** күренеше, бу очракта сүзләр чигендә янәшә килгән ике сузыкның берсе төшеп кала, икенче сузык тарафыннан йотыла, ягъни бер сүз ахыры белән икенче сүз башында бер төрле сузыклар очрашканда, аларның берсе төшеп кала. Шигъри әсәрләр телендә еш кына очрашучы сузыкларның беренчесе [ә], икенчесе [а] авазы булса, гадәттә, бер аваз тулысынча кыскара. Ритмикага бәйләнешле мондый төр эзләнүләр Һ. Такташ, Х. Туфан, Ә. Фәйзи әсәрләрендә урын ала, аеруча Х. Туфан тарафыннан яратып кулланыла. Мәсәлән:

*Эзлим сине, ләкин* ***табалмыйм****:*
*Күп икән, кү-үп*
*Синең төсләләр, -*
*Ландыш кебек ап-ак күңелле,*
*Кояш кебек якты йөзләләр.*
(Х. Туфан. «Ландыш», 1956)

Бу очракта ритмик таләп белән «таба алмыйм» тезмәсендә сүз азагындагы [а] авазы төшеп калган, янәшә килгән бертөрле авазларның берсе икенчесе тарафыннан йотылган.

Әлеге төрдәге аваз кыскарулары Һ. Такташ әсәрләрендә дә күзәтелә:

*Менгән саен җирнең матурлыгын,*
*Яктылыгын күбрәк* ***куралдым...***
*Ә син* ***менәлмадың...***
*Калдың, югалдың.*
(Һ. Такташ. «Мокамай», 1929)

Ике очракта да элизия күренеше метрика таләбе нигезендә язуда чагылыш таба. Әмма бер әһәмиятле үзенчәлекле билгеләп үтү мөһим: шигырь ритмы таләп иткән очракта ике сүз арасына туры килгән [ә] һәм [а] сузыклары йотылмыйлар. Мәсәлән:

*Хыялымда минем шул урманнар*
*Һаман кайный, һаман шаулыйлар,*
*Синең белән минем малай чаклар*
*Күз алдымнан китә алмыйлар.*
(Һ. Такташ «Мокамай», 1929)

Билгеле булганча, татар телендә элизия күренеше нигезендә яңа сүзләр дә ясалырга мөмкин. Тикшерелә торган шигъри текстларда беренче сүз [ә] авазына тәмамланып, икенчесе [а] авазына башланган очракта яңа сүзләр ясалалар, һәм, гадәттә, икенче сүз сингорманизм законына буйсынып үзгәрә. Элизия күренеше нигезендә барлыкка килгән яңа сүзләр аеруча Ә. Фәйзи, Х. Туфан әсәрләрендә еш күзәтелә. Мәсәлән:

*Бу очу шатлыгын*
***Яшерәлми*** *күзләрдән,*
*Төшәләр илемнең*
*Кызлары – гүзәлләр.*
(Ә. Фәйзи «Кер юучы турында җыр», 1935)

*Безнең кызлар үзе анда хәзер*
*Авыларны алга җитәкли!*
*Ә син?*
*Вагоннан да ялгыз* ***төшәлмисең,***
*Җитәкләүче*
*Егет кирәк бит.*
(Х. Туфан «Тәти кыз альбомына», 1927)

Әлбәттә, «яшерә алмый», «төшә алмыйсың» урынына «яшерәлми», «төшәлмисең» дип сөйләү барыннан да бигрәк җанлы сөйләм теленә, сөйләшү стиленә хас. Алдагы мисалларда ритмик таләп белән алар поэзия теленә дә үтеп керәләр һәм шигъри сөйләмне җанландыру, экспрессивлыкны арттыру юлында файдаланыла.

«Әгәр төзелмәнең беренче компоненты [а], [ә], икенче компоненты [у], [ү], [и] авазлары булса, соңгылары [w] яки [й] сонантлары булып әйтеләләр, ә төзелмә үзе [аw], [әw], [ай], [әй] тибындагы ялган дифтонг булып ишетелә» [Татар грамматикасы, 2015, Т. I, б. 23]. Мондый типтагы мисаллар аеруча Һ. Такташ иҗатында күп очрый. Мәсәлән, авторның «Мокамай» шигыреннән берничә мисал китерергә мөмкин:

*Бергә чабаталар үреп йөргән чакта*
*Син остарак миннән* ***үрәйдең,***
*Минем матур итеп* ***үрәлмауны***
*Булдыксызлыгымнан* ***күрәйдең...***

Яки тагын бер мисал:

*Без урманда урман кискән чакта,*
*Бергә урлап юкә* ***кисәйдек.***
*Чабаталар үреп, кояш байгач,*
*Ат узышып кайтып* ***китәйдек.***
(Һ. Такташ. «Мокамай», 1929)

Алдагы мисалда «үрә алмауны» урынына «үрәлмауны» булып ишетелә (*аферезис* күренеше күзәтелә). Әлеге өзекләрдә «үрә идең», «күрә идең», «кисә идек», «китә идек» төзелмәләрендә янәшә килгән авазлар дифтонгоид булып әйтеләләр: [ай], [әй] тибындагы ялган дифтонглар ясалып, метрик таләп белән «үрәйдең», «күрәйдең», «кисәйдек», «китәйдек» булып ишетелә.

Төзелмәдә янәшә килгән [а], [ә] һәм [и] авазларының дифтонгоид булып әйтелү һәм язылу үрнәкләре Ә. Фәйзи әсәрләрендә дә бар. Мәсәлән:

***Тоймасайдем*** *шунда*
*Оялу азабын.*
*Мин яулап* ***алсайдем***
*Шушының җавабын.*
(Ә. Фәйзи. «Артымда үтерелгән...», 1947)

Әлеге шигырьдә «тоймаса идем», «алса идем», «булса иде» төзелмәләрендә [ай] ялган дифтонгы ишетелә.

**Синкопа** – сүз уртасындагы авазның төшеп калуы (мәсәлән, халык – халкы һ.б.). Синкопа күренеше тикшерелә торган шигъри текстларда күбрәк [ы] һәм [е] авазларына кагыла. Мәсәлән:

[ы] авазы төшеп калу:

*Куык кунды барып кыз* ***борнына,***
*Кыз аптырап битен каплады...*
*Кыз торды да кинәт, әйтте миңа,*
*Еламады үзе, көлмәде:*
«*Сөям, диеп кызга үрелгәнче,*
*Сөрт* ***борныңны,*** *егет, элгәре!*»
(М. Җәлил. «Ишек төбендә», 1942).

[е] авазы төшеп калу:

*Аның* ***исме*** *белән ачылган тел,*
*Үлгәндә дә Аны кабатлар.*
(М. Җәлил. «Хөкем алдыннан», 1943).

Аерым очракларда [ә] авазы да төшеп калырга мөмкин: гадәттә мондый мисаллар җанлы сөйләм телендә күзәтелә. Мәсәлән:

*Төн **тәрәзгә***
*Кызыл якты япты.*
(Х. Туфан. «Еллар итәгендә», 1925)

Билгеле булганча, татар телендә сүз уртасында авазларның төшеп калуы исем сүз төркеменә кергән берәмлекләрдә еш күзәтелә һәм синкопа, гадәттә, сөйләм теле өчен хас күренеш булып санала. Поэзия телендә фонетик-ритмик процесслар нәтиҗәсендә авазлар төшеп калу фигыль сүз төркеменә кергән сүзләрдә дә очрый:

[ы] авазы төшеп калу:

*Кулларымны болгый-болгый, бүлмәм буйлап*
***Ашгып-ашгып** йөрим, белмим, нидер уйлап:*
(Һ. Такташ. «Күләгәләр», 1922)

[е] авазы төшеп калу:

*Син уйныйсың, ә мин шундый ардым;*
***Өзлеп-өзлеп** тыным алам да.*
(Һ. Такташ. «Урман кызы», 1922)

*Барыгыз болынга, балалар!*
***Йөгрегез,** уйнагыз, көлегез!...*
***...Китрегез** данлыклы хөр илнең,*
*Тәбрикләп, шатлыклы көннәрен.*
(М. Җәлил. «Чәчәкләр», 1943)

Метрик таләп буенча берничә аваз да төшеп калырга мөмкин (кайбер сүзләрдә). Мәсәлән, түбәндәге шигырь текстының соңгы юлындагы «асылынып» сүзе урынына «аслып» сүзе кулланылган, сүзнең өч авазы төшеп калган:

*«Барабыз»да кайтып киләм әле*
***Аслып** үлгән берәү янынннан...*
(Һ. Такташ, «Болай... гади җыр гына», 1928)

Аерым очракларда аваз гына түгел, бәлки, ритмик таләптән чыгып, тулы бер иҗек тә *(-гы)* төшеп калырга мөмкин. Мәсәлән:

*Ни була сайрамаса!..*
***Яңрата** әрәмәне.*
*Япсана тәрәзәне:*
*Үзәкне өзә ләса.*
*Ни була сайрамаса...*
(Х. Туфан. «Бу соңгы таңы анын», 1943)

Шигырь ритмикасы кагыйдәләре нигезендә сүзнең беренче авазы яки соңгы авазы төшеп калып, сүз кыскарырга мөмкин. Тикшерелә торган шигъри текстлар телендә мондый фонетик үзенчәлекләр булган мисаллар еш очрамый, әмма урын ала:

*Теләсәм дә, хәзер **ләкми** миңа*
*Бер тамаулы гына гашыйк та.*
(М. Җәлил. «Ишек төбендә», 1942)

Әлеге өзектә «эләкми» сүзендә сүз башында [э] авазы кыскарган һәм сүз сөйләм телендәге формада кулланыла.

Моннан тыш бу чор шигъри әсәрләр телендә апокопа – сүз ахырында басымсыз сузыкның төшеп калу күренеше дә урын ала:

*Әл* ***дә****, золмәтләргә йотылып,*
*Монда ил – ислам тора.*
(Һ. Такташ. «Төркстан сахраларында», 1917)

Бу мисалда «әле дә» сүз тезмәсендә [е] авазы шигырь ритмикасына буйсынып төшеп калган.

**Авазлар өстәлү.** Поэзия телендә аерым сүзләрләрнең кулланылышы, аларның үзгәреше дә шигырь ритмикасы таләпләренә буйсындырыла һәм метрика кагыйдәләре нигезендә аерым сүзләр сөйләм теленә яраклаштырыла. Әлеге максатлардан чыгып, шигъри текстларда аерым сүзләр сөйләм телендәге формада кулланыла. Шуны билгеләп үтәргә кирәк: сүз уртасына сузык аваз өстәлү күренешенә мисаллар еш очрамый. Мәсәлән, М. Җәлилнең «Нәрсә эшләдең?» шигырендә бер үк сүз («күбрәк») ритмик таләптән чыгып, ике формада кулланыла: «күбрәк» һәм «күберәк»:

***Күбрәк*** *танк, туплар, гранаталар,*
*Минометлар кирәк фронтка,*
*Син заводта эшләп чыгарышны*
*Күтәрдеңме шундый муллыкка?*
***Күберәк*** *ит, икмәк, кием кирәк*
*Фронтагы сугышчыларга.*
*Чыгардыңмы өлеш хезмәтеңнән*
*Җимешеннән өлеш шуларга?*
(М. Җәлил. «Нәрсә эшләдең?», 1941)

Поэзия телендә аерым сүзләрнең кулланылышы турыдан-туры шигырь ритмикасы таләпләренә буйсындырыла. Шигъри сөйләм теленең, беренче чиратта, авазлар составы ягыннан оешуы, фонетик-стилистик элементларның билгеле бер тәртипкә салынган булуы сәнгатьлелекне арттыру, образлылык һәм сүздән сурәт тудыруга юнәлтелә. Сөйләмнең сәнгатьчә бай, югары поэтик яңгырашлы булуында, дөрес һәм матур әйтелешендә төрле фонетик чаралар зур урын тота. Шигъри әсәрләрдә аваз кабатлануларының аерым төрләре (аллитерация, ассонанс, эвфония) башка стилистик фигуралар белән бергә кулланылып (анафора, эпифора), әсәр тукымасына салынган мәгънәне, автор идеясен тагын да калкурак итеп бирергә мөмкинлек бирә.

Шигъри текстларда аерым сүзләр шигырь үлчәме таләбе, рифма-ритм, метрика кагыйдәләре нигезендә фонетик составы ягыннан үзгәрешләр кичерә. Сүзләрдән авазлар төшеп калу (элизия, синкопа, аферезис, апокопа күренеше) һәм сүзләргә аерым авазлар өстәлү кебек фонетик закончалыклар җанлы сөйләм теле һәм сөйләшү стиленә хас күренешләр булып санала. Ритмика таләп иткәндә алар шигырь

текстларына үтеп керәләр һәм җанлы сөйләмгә якын стиль тудыруга хезмәт итә башлыйлар, табигый яңгырашны арттырып, экспрессивлыкны көчәйтү чарасына әвереләләр. Шул рәвешле, фонетик-стилистик чаралар шигъри текстлар телен нәфис, аһәңле, матур яңгырашлы итүдә зур әһәмияткә ия, һәм аларны урынлы куллану, бер-берсе белән чиратлаштыру шагыйрьләрнең осталыгын, зәвыгын, сөйләм байлыгын күрсәтеп тора.

**Әдәбият**

*Гыйmранова Г.* XX гасыр башы татар шигъриятендә аваз кабатлауларның эстетик вазифасы // Фәнни язмалар – 2007: җыентык / фәнни редакторы И.А. Гыйләҗев. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2008. Б. 101–106.

*Кузьмина Х.Х.* Фонетик стилистика мәсьәләләре // Milli mədəniət. 2006 № 11. Б. 55–57.

*Курбатов Х.Р.* Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. Казан: Мәгариф, 2002. 199 б.

Русско-татарский толковый словарь лингвистических терминов / под ред. Ф.И. Тагировой и Ф.Ф. Гаффаровой. Казань: ИЯЛИ, 2016. 248 с.

Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Ф.М. Хисамова. Тулыл. 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. I. 512 б.

*Хаков В.Х.* Татар әдәби теле (стилистика). Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 304 б.

*Юсупов А.Ф., Юсупова Н.М.* Поэтическая ономастика татарской поэзии первой половины XX века // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2019. Т. 12. Вып. 3. С. 261–264.

*Публикация статьи осуществлена в рамках научного проекта № 18-412-160008 РФФИ и Правительства Республики Татарстан*

*Мәкалә РФФИ һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 18-412-160008 номерлы проекты кысаларында әзерләнде*

***Юсупов Айрат Фаик улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбенең татар теле белеме кафедрасы доценты*

УДК 81'374

***Э.И. Сафина***

# КҮГӘРЧЕН ОРНИТОНИМЫНЫҢ СИМВОЛИК МӘГЪНӘЛӘРЕ

В статье рассматривается типичное представление, существующее в коллективном сознании носителей татарского языка, об орнитониме *күгәрчен* ‘голубь’. Анализируются коннотация, устойчивые сравнения и пословицы с данным орнитонимом, символьное значение наименования птицы. Будучи устойчивыми по составу и структуре, идиоматические выражения и паремии передают сведения о национальном характере, мировоззрении и культуре народа.

**Ключевые слова:** орнитоним, голубь, символ, коннотация, лингвокультура, устойчивое сравнение, паремия, пословица, фразеологизм.

The article deals with typical notion existing in the collective consciousness of Tatar language speakers about ornithonym ‘pigeon’. Connotation, sustainable comparisons and proverbs with the ornithonym, the character value of the name of a bird are analyzed. Being stable in composition and structure, idiomatic expressions and paroemias convey information about the national character, worldview and culture of the people.

**Keywords:** ornithonym, pigeon, symbol, connotation, linguistic culture, sustainable comparison, paroemia, a proverb, phraseologism.

Телдә кешенең әйләнә-тирәне тануы, дөньяны кабул итүе һәм аңа мөнәсәбәте, тормыштагы урыны, роле һәм үзен ничек күзаллавы һ.б. турында мәгълүмат саклана. Әлеге мәгълүмат халык авыз иҗаты аша буыннан-буынга тапшырыла һәм әдәби иҗат ярдәмендә тагын да камилләшә, яңа образ, чагыштыру, символларга байый бара.

Мәкаләдә күгәрчен кошы белән бәйле образлар, символик мәгънәләр тикшерелә. Мәкаль-әйтем, әкият, җыр, фразеологизмнарда һәм әдәби әсәрләрдәге һәртөрле чагыштыруларда *күгәрчен* орнитонимының еш очравы, язучы-шагыйрьләрнең сурәтләү чаралары ярдәмендә аларга бәйле рәвештә бай образлылык тудыра алуы үзе үк бу символларның күптөрлелеге турында сөйли.

Лингвомәдәни яссылыкта тикшеренүләр еш кына бер үк кош турында төрле караш, күзаллау, һәм аларга бәйле рәвештә каршылыклы образлар булуын күрсәтә. Мәсәлән, ябалак кошларга карата ярату, хөрмәтләү дә (*Байгышның оясын Ходай кора. Ябалакның түшенә аять язылган, ди*), шул ук вакытта, үз итмәү, шикләнү, яратмау да сизелә (*Чырайсыз ябалакны урман да куган, авыл да куган. Ябалакны сыйпау белән шоңкар булмас* һ.б.). Тупланган материалларны анализлау, башка кошлар белән чагыштырганда, күгәрченнәрнең татарлар өчен якынрак, кадерлерәк булуын ачыкларга мөмкинлек бирде.

1. Күгәрчен – тынычлык символы: *тынычлык* ***күгәрчен*** *канатында*; *Көннәрдән бер көнне карлы-бозлы илләр, ерак җирләр гизеп, дөнья*

*тирәли сәяхәттән илебезнең иминлеге өчен көрәшүче* ***ак күгәрчен*** *кайтып төшә.* (Л. Исмәгыйлева)

2. Күгәрчен – бәхет кошы: *Чөнки* ***күгәрчен****, ягъни мин – тынычлык һәм бәхет кошы.* (Р. Батулла) *Минҗамал өчен Потый Шәфикъ чын мәгънәсендә* ***бәхет күгәрчене*** *булып чыкты ла.* (З. Мәхмүди)

3. Күгәрчен – муллык билгесе: ***Күгәрченнәр*** *– мул тормыш билгесе. Элекке заманда, ачлык елларында, алар бөтенләй күренмиләр иде. Ә хәзер һәр колхоз өстендә бу гүзәл, затлы кошлар төркем-төркем булып очалар, түбә кыекларында, сарай түбәләрендә гөрлиләр.* (Г. Әпсәләмов)

4. Күгәрчен – арадашчы, дуслаштыручы, кавыштыручы: – ***Күгәрченем****, хисләремне белдерергә ярдәм итче, сине юкка гына кавыштыручы димиләрдер бит.* («Ялкын» журналыннан) *Кавыштыручы, дуслаштыручы* дию хат ташучы күгәрченнәрнең кешеләр арасында элемтә чыганагы, арадашчы ролен үтәүләреннән килә (*Айгөл яңадан кулларын чәбәкләде: – Хат ташучы* ***күгәрчен****! Әйдәгез, болай итәбез: мин хәзер йөгереп кенә өйгә кайтам, ә сез икегез, миңа хат язып, күгәрчен җибәрегез!* (Н. Акмал)

5. Күгәрчен – изге кош: ***Күгәрчен****не бездә изге саныйлар,* ***күгәрчен*** *гөрләсә сөенәләр.* (Н. Фәттах) ***Күгәрчен*** *рәсемен нәмаеш вакытларында урам буйлап күтәреп йөриләр.* (Р. Батулла)

6. Күгәрчен – сакчы: ***Күгәрченне*** *без сакчы итеп күрәбез, шуңа кадерлибез, яратабыз.* («Сөембикә» журналыннан) «Халыкның көнкүрешендә күгәрчен, тотем кош буларак, еш кына сакчы вазифасын үтәгән, һәм бу традиция бик озак вакытлар дәвам иткән: тәрәзә йөзлегенә ясалган пар күгәрчен сурәтен хәтта әле бүгенге көндә дә очратып була» [Җамалетдинов, б. 36].

Татар телендә күгәрчен кошына бәйле мәкаль-әйтемнәр күп түгел. Булганнары, нигездә, күгәрченнәрнең яшәү рәвеше яисә теге яки бу сыйфатларына кагылышлы. Мисал өчен, тырыш, ярдәмчел (*Ут чыкса – күгәрчен су ташый, чыпчык чүп ташый, имеш*), бер-берсенә дусларча мөнәсәбәттә (*Күгәрчен күгәрченне «гөлдер бу-у» дип мактаган*), иркенлектә, муллыкта яшәүче (*Күгәрченнең бодае һәркайда*) [Татар халык мәкальләре, б. 591; Сафина, 2018, б. 169] һ.б.

*Күгәрчен* орнитонимы кергән фразеологик берәмлекләр, киресенчә, актив. Мисал өчен, бик дус, тату яшәүчеләр турында сүз барганда, татарлар *күгәрченнәр кебек гөрләшү* [Исәнбәт, б. 453]; *күгәрченнәр кебек*, *күгәрченнәр кебек гөрләшеп* әйтелмәләрен куллана [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, б. 527]. Бу очракта күгәрченнәр мәхәббәт, гармония символы булып күз алдына килеп баса: *Абыстай белән пар күгәрчендәй гөрли-гөрли чәй эчәләр.* (Т. Гыйззәт) – *Әйтмә генә: ал да гөл кебек, пар күгәрчен кебек гөрләшеп торабыз.* (Г.Ибраһимов)

*Күгәрчен сөте генә юк*, *күгәрчен сөте генә булмаса булмас* [Исәнбәт, б. 453] фразеологизмнары җитешлекне, муллыкны, байлыкны яки табынның бик бай әзерләнгәнен белдергәндә кулланыла, зурлыгы, күләме, үлчәме бик кечкенә булган әйберләргә карата *күгәрчен*

*теле кадәр*, җай гына, бик ягымлы итеп сөйләү турында *күгәрчен кебек (күгәрчендәй) гөрләү* кулланыла. ***Күгәрчен тоткандай*** фразеологик әйтелмәсе ***кош тоткандай*** белән аваздаш (*Аңа кызы, авыз тутырып, туган телендә «әти» дип эндәшә, һәр шылтыраткан саен* ***күгәрчен тоткандай*** *шатлана иде.* (Н. Гыйматдинова)

*Күгәрчен сөтенең* беренче мәгънәсе үсемлекне аңлатса, күчерелмә мәгънәдә ул «аракы, спиртлы эчемлек» буларак кулланыла [Исәнбәт, б. 453; Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, б. 528]. (*Башкасын, теләсәң, оҗмах җимешләрен,* ***күгәрчен сөтен****, Шүрәле бармагын дус-иш ярдәмендә табам!..* (А. Гыйләҗев) *Кечтеки тостым шул, яшьләр хөрмәтенә, ачы булса да, эчәм шул* ***күгәрчен сөтен!*** (Г. Әпсәләмов)). Бик сирәк очрый торган әйбер турында да *күгәрчен сөте* диләр (*Мәскәү дигәч тә, Мәскәүдә* ***күгәрчен сөте*** *дә табарга була дигәч тә, анда да бөтенесен әзерләп, сине көтеп кенә тормыйлар, абзыкаем!* (В. Нуруллин)).

Мәхәббәт символы булган күгәрченнәрне күз алдында тотып, ***пар күгәрчен*** тезмәсе еш кулланыла. Күп очракта ул ***гөрләү, гөрләшү, гөргөр килү, гөрелдәү, гөргелдәү, гөлдерәү, гөлдердәү*** һ.б.ш. фигыльләр белән бергә килә (*Яшьлектә* ***пар күгәрчен*** *кебек* ***гөрләшеп*** *тормагач, соңыннан нәрсәсе сагынып сөйләргә кала аның?!* (Г. Әпсәләмов)). Әмма «пар күгәрченнәр» гөрләшеп-гөрелдәшеп кенә калмый, **чүкердәшә, чөкердәшә** дә әле (*Анастасия әле күптәнме генә* ***чөкердәшеп пар күгәрченнәрдәй*** *яшәгән иренең җәсәде артыннан килеп мәшәкатьләнмәде.* (Н. Әхмәдиев) --- ***чүкердәшеп пар күгәрчен*** *кебек.* (Г. Мөхәммәтшин)).

*Күгәрчен* атамасын татарлар бер-берсенә яратып мөрәҗәгать иткәндә дә кулланалар. Аеруча популяр вариантлары – ***күгәрченем, күгәрченкәем, күгәрченкәйләрем*** (***Күгәрченкәем****, син минә үз динеңдәге кешегә чыккан килеш тә яши алмагансың бит әле.* (А. Әхмәтгалиева). *И-и,* ***күгәрченем****. Белгән нәрсә комачауламый ул!* (А. Гыйләҗев) *Сез,* ***күгәрченкәйләрем****, салкын таш стена гына буямыйсыз, кешеләрнең тормышын бизисез, дип өйрәтә иде ул аларны.* (Г. Сабитов)). Шул ук вакытта, ***күк күгәрченем, күгәрчен тәпием*** кебек сирәк вариантлар да очрарга мөмкин (*Без оятны җүн генә бәягә базарга чыгарып саткан идек шул,* ***күгәрчен тәпием.*** (Н. Гыйматдинова) *Газинур балага текәлеп карап торды да: – Үземә охшый икән, – дип куйды, – ух син,* ***күк күгәрченем*** *минем, сандугачым, былбылым.* (Г. Әпсәләмов)).

Орнитонимның элек кеше исеме буларак кулланылуы мәгълүм. «Күгәрчен – кош исеме. Болгар-татарларда ирләр исеме булып йөргән. Казан татарларында һәм мариларда *Күгәрченев, Кугарчинов* фамилияләрендә сакланган» [Саттар-Мулилле, б. 154]. Бүгенге көндә *Күгәрчен* орнитонимы кушамат буларак кулланылуын дәвам итә. Әлеге кушаматлар, нигездә, күгәрченнәргә хас булган сыйфатларны кешеләрдә дә күреп, яисә күгәрчен белән бәйле вакыйгалар уңаеннан кушылган (*Күгәрчен Мөхетдин, Күгәрчен Сәлим, Күгәрчен Галия* һ.б.). Мисал өчен, кешенең кечкенә буйлы булуы түбәндәге

мисалда чагыла: *Бәләкәй гәүдәле булуымны кызык күрде, ахрысы. Шунда ук кушамат та такты: «**Күгәрчен**! Мин аның өчен шулай гомер буе кәефе килгәндә – **Күгәрчен**, кәефе киткәндә Чәүкә булдым.* (А. Юнысова)

Татар халкының күгәрченнәрне нинди итеп күрүе, ничек сыйфатлавы әдәби әсәрләрдә аеруча ачык күренә. Мисал өчен, *күгәрчен*:

– моңлы (үзе моңлы яисә моңлы гөрли): ***Моңлы күгәрчен** гөрли, күрәмсең, Ямьле көннәрдә ничек түзәрсең.* (Г. Макаров) *Ник, **күгәрчен, моңлы** гөрлисең син? Ник, йөрәгем, болай дөрлисең?* (И. Юзеев);

– тыныч: *Анда, тәреләр, иконалар, китап-кәгазьләр, балавыз шәмнәр арасында яулыгын иягенә төшереп бәйләгән, иске генә, әмма чиста киң киндер күлмәк кигән бер карчык, **күгәрчен** сыман **тыныч** кына укынып утыра, сорау бирүче булса, күзләрен күтәрми генә җавап кайтара.* (Д. Булатова);

– мескен: *Күргәне-белгәне булмаганга, Гөлшәһидә аны буе-сыны, төсе-башы белән түгел, бәлки бөкрәйгән бер хатын кыяфәтендә генә күз алдына китереп, шушы карлы-бозлы иртәдә тәрәзә почмагына сыенган **мескен күгәрчен**гә охшатты.* (Г. Әпсәләмов);

– ваемсыз: *Аяк астында буталып йөрүче кызыл томшыклы, түгәрәк бүксәле **ваемсыз күгәрченнәр** бөтен кыяфәте белән Рүдәлгә охшап күренделәр аңа.* (Р. Вәлиев);

– әрсез: *Алар, **базар күгәрчене** кебек, **әрсез** булалар, китапханәдә утырасы урынга, дәрәҗәле кешеләр белән танышу юлларын эзлиләр.* (М. Мәһдиев);

– күркәм: **---** ***күгәрчендәй күркәм** кодачалар, Сандугачтай сылу сеңелләр.* (Х. Туфан);

– шапшак*: Чыпчык-чырылдык – минем иң яраткан кошым Башсыз тукран да түгел, мактанчык сыерчык та түгел, көяз саескан да түгел, **шапшак күгәрчен** дә түгел, минем иң яраткан кошым – чыпчык-чырылдык. Ни өчен шулаймы?* (Р. Мингалим);

– җитез, өлгер: *Сиңа **Күгәрчен** исемен юкка гына бирмәгәннәр. Агачтан агачка күчеп кунып йөрисең.* (Г. Кутуй).

Метафоралаштыру һәм һәртөрле сыйфатларына бәйле рәвештә күпертеп сурәтләүдән тыш, әдәби әсәрләрдә күгәрченне башка кошлар белән каршы куеп чагыштыру еш очрый. Аннан теге яки бу сыйфатлары белән аерылып торган кошлар белән каршы кую нәтиҗәсендә, күгәрченнәргә хас башка сыйфатлар да калкып чыга.

1. Күгәрчен – карчыга: *Безнең – **күгәрчен**, сезнең **карчыга** икәнегез дөньяга фаш булыр!* (Р. Батулла);

2 Күгәрчен – чәүкә: *Менә шул **күгәрчен** балалары арасында мин **чәүкә** дә укып йөрим.* (И. Нәбиуллина). *«Бабайның **күгәрченнәре** арасында мин бер **чәүкә** идем» дигәндәй, Казанның эшмәкәр егетләре арасында мин дә аерылып торам.* (Т. Миңнуллин);

3. Күгәрчен – чыпчык: *Алты **күгәрчен** арасында бер **чыпчык** сыман, мин дә алар уртасында миннекне тотып утырган булам.* (И. Ядкәрова);

4. Күгәрчен – карга: *Тезләрен чүгә төшеп пыр тузып килгән юан хатыннар фонында ул* ***каргалар*** *арасындагы* ***күгәрчен*** *кебек иде*. (М. Маликова);

5. Күгәрчен-козгын: *Әти сөйли торган иде:* ***күгәрчен*** *күченә* ***козгын*** *җитәкче булса, бөтен күгәрчен дә үләксә ашый башлар, дип*. (М. Мәһдиев) ***Ак күгәрченне*** *кулымнан алдылар,* ***козгын*** *биреп, Ак кирәк, дип, пакь кирәк, дип, күпме күз яшь түкмәдем*. (Г. Тукай). Аклык, күңел юанычы, ярдәмчеллек символы булган «ак күгәрчен»гә контраст итеп кара көчләр, ерткычлык, явызлык рухы «козгын» капма-каршы куела.

Чагыштыруларның барысында да *күгәрчен* орнитонимы уңай коннотацияле. Биредә авторлар күгәрчен образына матур, нәфис, тыныч холыклы, мәрхәмәтле, изге күңелле, ипле, җайлы һ.б.ш. уңай сыйфатлы кешеләрне сурәтләү яисә зурлык-кечкенәлек кебек нейтраль характеристика бирү өчен мөрәҗәгать иткәннәр.

*Күгәрчен* татар халык әкиятләрендә дә уңай образ. Ул, нигездә, кызга яки егеткә әверелә һәм киресенчә: *Озак та үтми, тәрәзә ачылып китә, тәрәзәдән өч күгәрчен гөрләтеп кайтып керә. Күгәрченнәр кайтып керәләр дә бик чибәр өч егеткә әвереләләр* [Татар халык әкиятләре, б. 274]; *Егет камыш төбенә утыргач кына, теге өч ак күгәрчен, лыпыр-лыпыр очып, диңгез өстендә өч тапкыр әйләнәләр. Аннары чишенә торган урынга төшәләр дә кызларга әвереләләр* [Татар халык әкиятләре, б. 332] һ.б.

Җырларда күгәрчен образлары күбесенчә тынычлык, мәхәббәт, бәхетле тормышны, сирәк кенә моңсулыкны белдерү өчен кулланыла (*Яшь гомерләр узмый диләр, Ак күгәрчен, сандугачым, Уйнап-көлеп уза икән; Күгәрчен гөрлидер, Язын, көзен белмидер; Минем күңлем сине уйлый, Күк күгәрчен, сандугачым, Синең күңелең кемне уйлый? Утырамын да уйга батам, Күк күгәрчен кулда уйнатам*. һ.б.) [Татар халык җырлары, б. 130, 157, 200, 82]. Мисалларда *күк күгәрчен* тезмәсенең еш очравы гаҗәп түгел. Этимологик тикшеренүләр күгәрчен орнитонимының күк төсеннән барлыкка килүен дәлилли [Сафина, б. 37].

Күгәрченнәрнең элек-электән мәхәббәт, гүзәллек, тынычлык символы булуы тәрәзә йөзлекләренә балта осталары уеп ясаган пар күгәрченнәрдән дә күренә. Татар кызлары мендәр тышлары, тастымалларга пар күгәрченнәр чиккән, вәгъдә билгесе итеп егетләренә бүләк итә торган кулъяулыкларына чәчәккә кунган пар күгәрченнәрне төшергән (*Ул алъяпкычка зәңгәр җеп белән* ***ике күгәрчен*** *чигелгән*. (Г. Гыйльманов) ***Күгәрчен*** *сурәтен халкыбыз гомер-гомергә тәрәзә йөзлекләренә, капкаларга уеп ясаган, ул гаилә татулыгын, тигезлекне аңлаткан*. (Ә. Мөхәммәтҗанова)).

Күгәрчен белән бәйле ышануларны халкыбызның аларны изге күрүе белән аңлатып була (*Пәри кешегә еш кына яхшылык эшли, алар ир-ат яки хатын-кыз,* ***күгәрчен****, хайваннар кыяфәтендә күренәләр*. (Г. Рәхим) ***Күгәрчен*** *– җәннәткә алып керүче кош. Үзен ашаткан кешене күгәрчен танып җәннәткә алып керер*. («Кәеф ничек?»

газетасыннан) ***Күгәрченне** үтерү, ашау гөнаһ булып санала. Ахырзаман көне җиткәч, **күгәрчен** үзенең томшыгына су алып, гөнаһлы мөселманнар янган тәмуг утын сүндереп йөриячәк.* (Г. Рәхим)). Төштә күгәрчен күрүне дә татарлар яхшыга гына юрый (*Бүген төштә **ак күгәрчен** күрдем, Мәчет кәрнизендә гөрләде. Нигә юрыйм – бары изгелеккә.* (М.Сәгъдиев)).

Күгәрченнәрне изге дип санау ниндидер дәрәҗәдә «кеше җаны күгәрчен булып оча» диюгә һәм элек-электән килә торган ышануларга барып тоташадыр. «Мифологиядә һәм фольклорда җанның кош булып очып китүе дә саклана. Гомумән, төркиләр үлгән кешенең җаны күгәрчен яки башка кош булып оча дип күзаллыйлар» [Закирова, б. 207].

Күгәрчен орнитонимының халык авыз иҗаты әсәрләрендә һәм авторлар иҗатында еш очравы, күчерелмә һәм символик мәгънәләргә бай булуы әлеге кошның татар халкының көндәлек һәм рухи тормышында тоткан урыны турында сөйли. Күгәрчен кошына кагылышлы үзенчәлекле образлар фразеологик берәмлекләрдә һәм чагыштыруларда аеруча күп. Алар стилистик бизәк буларак сөйләмнең эмоциональ-экспрессив яңгырашын, аһәңен көчәйтә, аның сәнгатьлелеген, тәэсирлелеген арттыра. Мисаллардан күренгәнчә, татар халкы өчен күгәрчен, беренче чиратта, тынычлык, бәхетле тормыш, мәхәббәт, гүзәллек символы.

**Әдәбият**

*Җамалетдинов Л.Ш.* Татар экиятләрен барлау юлында / төз. И.И. Ямалтдинов. Казан: ТӘһСИ. 2015. 264 б.

*Закирова И.Г.* Төрки фольклорда һәм Г. Тукай иҗатында җан белән бәйле ышанулар // Габдулла Тукай и тюркский мир: материалы международной конференции, посвященной 130-летию со дня рождения Г. Тукая / сост.: Ф.Х. Мингуллина, А.Ф.Ганиева. Казань: ИЯЛИ, 2016. 484 с.

*Исәнбәт Н.* Татар теленең фразеологик сүзлеге: Ике томда / фән. ред. В.Х. Хаков. Казан: Татар. кит. нәшр., Т. 1. 1989. 495 б.

*Саттар-Мулилле Г.* Татар исемнәре ни сөйли? (Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге). Казан: Раннур. 1998. 486 б.

*Сафина Э.И.* Названия птиц в татарском языке и их лексикографирование. Казань: Дом печати, 2006. 160 с.

*Сафина Э.И.* Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге. Казан: ТӘһСИ, 2018. 184 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: III том: К. Казань, ТӘҺСИ, 2017. 744 б.

Татар халык экиятләре: Тылсымлы экиятләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 415 б.

Татар халык җырлары: Лирик җырлар. Йола җырлары / төз., сүз башын һәм аңлатмаларны яз. И. Надиров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. 455 б.

Татар халык мәкальләре: өч томда / төз.: Н. Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. Т. 1. 914 б.

***Сафина Эльвира Ирфатовна,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 28(093)

*И.Г. Гомәров*

# ТАТАР ИЛЯҺИЯТ ГЫЙЛЕМЕ ТРАДИЦИЯЛӘРЕНЕҢ БИЛГЕСЕЗ ЧЫГАНАКЛАРЫ: СӨЛӘЙМАН БИНЕ ДАУД ӘС-СУВАРИНЫҢ «ЗӨҺРӘТ ӘР-РИЙАЗ...» ХЕЗМӘТЕ

Данная статья посвящена средневековому мусульманскому богослову из Поволжья Сулейману бин Дауду ас-Сувари ас-Саксини и его труду «Зухрат ар-рийаз ва нузхат ал-кулюб ал-мирад». Сулейман бин Дауд, бывший учеником булгарского казыя XII века Абу ‘Аля Хамид бин Идриса ал-Булгари, упоминается во многих источниках по мусульманскому историческому и богословскому наследию, также о нем пишут Шигабутин Марджани и Мурад Рамзи, однако деятельность ученого и его труды целенаправленно не изучались. В статье также дается краткий обзор основного труда ученого – арабский вариант «Бахджат ал-анвар…» под названием «Зухрат ар-рияз ва нузхат ал-кулюб ал-мирад».
**Ключевые слова:** Сулейман бин Дауд, Зухрат ар-рийз, Бахджат ал-анвар, Булгар, Сувар, Саксин, медиевистика, исламское богословие.

This article is devoted to the medieval Muslim theologian from the Volga region, Suleiman bin Daud al-Suvari al-Saksini and his work «Zuhrat ar-riyaz wa nuzhat al-kulub al-mirad». Suleiman bin Daud, a student of the 12th century Bulgarian qaziy Abu ‘Ala Hamid bin Idris, is mentioned in many sources on the Muslim historical and theological heritage, Shigabutin Marjani and Murad Ramzi also write about him, however, the scholar’s activities and his works have not been deliberately studied. The article also provides a brief overview of the scholar’s main work – the Arabic version of Persian «Bahjat al-Anvar ...» under the title «Zuhrat ar-riyaz wa nuzhat al-kulub al-mirad».
**Keywords:** Suleiman bin Daud, Zuhrat ar-riyaz, Bahjat al-Anwar, Bulgar, Suvar, Saksin, medieval studies, Islamic theology.

Тарихи чыганакларда Идел буе Болгар дәүләтендә яшәгән Ягъкуб бине Ногман Болгари, Хуҗа Әхмәд Болгари, Әбел-Галя Хәмид бине Идрис әл-Болгари, Борһанеддин Ибраһим бине Хозыр әл-Болгари, бертуганнар Таҗетдин һәм Хәсән әл-Болгарилар кебек мәгълүм голямалар рәтендә Сөләйман Дауд улының да исеме еш телгә алына. Ул иң әүвәл безнең көннәргә кадәр килеп ирешкән һәм Урта гасырлар мөселман дөньясында киң кулланылышта йөргән «*Зөһрәт әр-рийаз вә нөзһәт әл-колүб әл-мирадз*» (Бакчаларның матурлыгы һәм сырхау йөрәкләрнең юанычы – Красота садов и утешение страдающих сердец) исемле әсәре белән билгеле.

Сөләйман бине Дауд хакында бүген фәнгә нәрсәләр мәгълүм соң? Аның тормышы һәм иҗатының өйрәнелү тарихы турында сөйләгәндә иң беренчел чыганаклардан шәех Хөсәен бине Гали әл-Вәгыйз әл-Кәшифинең (1463–1533) «Төхфәт әс-салават», Мөхәммәд Чокырыкчызадәнең (XVI–XVII йөзләр) «Алты бармак», Хаҗи Хәлифәнең (1609–1657) «Кәшф әз-зөнун...» хезмәтләрен күрсәтергә мөмкин. Шулай ук XIX гасыр азагы XX гасыр башында Шиһабетдин Мәрҗани-

нең «Мөстәфад әл-әхбар...», Морад Рәмзинең «Тәлфикъ әл-әхбар...» китапларында Сөләйман бине Дауд турында кайбер мәгълүматлар китерелә. XX гасырда үз фәнни эзләнүләрендә аның иҗатына галимнәр Зәки Вәлиди Тоган, Әнвәр Халидов, Нурия Гәрәева, Дамир Шәрәфетдиновлар теге яки бу күләмдә тукталып узалар. Әмма шунысын да искәртү урынлы булыр: бүгенге көнгә кадәр Сөләйман бине Дауд һәм аның «Зөһрәт әр-рийаз...» әсәрен максатчан рәвештә өйрәнгән аерым бер фәнни хезмәт юк. Шулай ук әлеге әсәрнең тексты да фәнни әйләнештән, галимнәр игътибарыннан читтә кала килә.

Бу шәхеснең тулы исеме – *Сөләйман бине Дауд әс-Сувари әс-Саксини*. «Кәшф әз-зөнун...»да бер урында *Сөләйман бине Дауд әс-Сувари* [Хәлифә Х., б. 257], икенче бер җирендә *Сөләйман бине Дауд әс-Саксини* [Хәлифә Х., б. 962] дип телгә алына. Д.Шәрәфетдинов әлеге хезмәтнең 1982 елда Бәйрүттә басылган нөсхәсендә авторның тулы исеме *Сөләйман бине Дауд Әбү әр-Рәбига әс-Сәбти әс-Сувари* рәвешендә китерелгән булуына игътибар итә [Шарафутдинов, 2003, с. 21]. Без «Зөһрәт әр-рийаз...» әсәренең төрле чорларда һәм төрле төбәкләрдә күчерелгән дистәдән артык кулъязма нөсхәләрен күздән кичердек: аларның күпчелегендә авторның исеме тотрыклы рәвештә *Сөләйман бине Дауд әс-Саксини* шәкелендә телгә алына. Каһирә шәһәрендә Фуад Сәгыйди исемендәге китапханәндә саклanучы бер кулъязма нөсхәдә алдагы исем тезмәсенә *әл-Каини* сүзе дә өстәлгән. Шулай ук әлеге кулъязмаларда, бу мөхтәрәм зат шәхесенә мөнәсәбәттә, «Таҗ әл-Ислам» – ислам диненең таҗы, «Имамнарның бөеге» кебек эпитетлар да мул кулланылган.

Сөләйман бине Дауд әс-Саксининың яшәгән чоры XI гасырның ахыры-XII гасырның беренче яртысына туры килә. Ул үз әсәренең һәрбер диярлек мәҗлес-бүлекчәсе башында Болгар иленең казые Әбел-Галя Хәмид бине Идрис әл-Болгаридан ишеткән хәдисләрне китерә, аны үзенең остазы дип атый. Бу шәхеснең һиҗри белән 500, милади белән 1106 елларда әле исән булуы мәгълүм. Үз чиратында Идрис әл-Болгариның әлеге хәдисләрне Әбү Бәкер Мөхәммәд бине Гомәр әл-Баззар (1106 елда үлгән), Әбү Бәкер Мөхәммәд бине Хәсән бине Мансур ән-Нәсәфи әл-Гавидни (1111 елда үлгән), Әбү әл-Мөгыйнь ән-Нәсәфи (1114 елда вафат) кебек хәбәр китерүче – равий һәм мөхәддисләрдән ишетүе турында искәртелә. Шиһабетдин Мәрҗани фикеренчә, болар барысы бергә Сөләйман бине Дауд әс-Саксини XI гасырның ахыры – XII гасырның беренче яртысында яшәгән, иҗат иткән дияргә ныклы нигез бирә.

Әсәр авторының исем-нисбәсенә караганда аның тормыш-яшәеше берничә географик урын – торак пунктлар белән бәйле. Шуннан чыгып ул Идел буе Болгар дәүләте шәһәрләреннән саналган Суварда туган (шунда ук укыган булу ихтималы да зур), Саксинда яшәгән дип сак кына фараз итә алабыз. Шулай ук *«әс-Сәбти»* ләкабе аны әс-Сәбт исемле торак пункт белән дә бәйли. Д.Шәрәфетдинов бу атаманы Мәгъриб илендәге хәзерге Сеута порт-шәһәрчеге белән тиңләштерә.

Бу фикерне расларлык яки инкарь итәрлек дәлилләр кызганычка каршы бүген табылмады.

Сувар (*суар, савир*) термины нигездә ике мәгънәдә кулланылышта йөри: беренчесе шәһәр исеме булса, икенчесе Идел буе Болгар дәүләтендә яшәгән аерым бер этник төркемне белдерә. Алар Сувар шәһәреннән тыш Болгарның башка торак пунктларында, шул исәптән, Саксин шәһәренең аерым бер өлешендә дә зур бер төркем булып яшәгәннәр. Бу хакта 1130 елда Саксинга килгән һәм егерме елга якын гомерен шунда уздырган урта гасыр сәяхәтчесе Әбү Хәмид әл-Гарнатый да яза [ал-Гарнати, 2010, 54]. Исем-нисбедәге *«әс-Сувари»* сүзе Сөләйман бине Даудның әлеге этник төркем вәкиле булуын да күрсәтергә мөмкин.

Исем тезмәсендәге *«әс-Саксини»* атамасы да аерым игътибарга лаек. Урта гасыр тарихи чыганакларында әлеге шәһәр турында мәгълүматлар еш очраса да, аның кайда урнашканлыгы турында төрле чорларда фәндә төрле фикерләр булды. Археолог галимнәр Саксин шәһәренең калдыкларын Идел елгасының урта агымыннан да, аның түбәнге буеннан да эзләделәр. Хәтта әлеге шәһәрнең калдыкларын Җаек елгасы буеннан эзләргә кирәк дигән фикер дә яшәп килде. Аны Сувар шәһәре, Ител һәм Сарай шәһәрләре белән дә тиңләштерделәр. Хәзер исә, күпчелек археологлар тарафыннан Саксин шәһәре Астраханьнан ерак булмаган җирдә, бүгенге Самосдельное городище исемле урында булган дигән фикер куәтләнә. [Васильев, 2015; 2016].

«Кәшф әз-зөнун...»да Сөләйман бине Даудның иң әүвәл фарсы телендә «*Бәһҗәт әл-әнвар мин хакыйкат әл-әсрар*» (Серләрнең хаклыгыннан килүче нурларның яктылыгы) исемле әсәр язуы, аннан соң аны гарәпчәгә тәрҗемә итеп, «*Нөзһәт әл-колуб әл-мирадз*» дип исемләве искәртелә. [Хәлифә Х., б. 962]. Алга таба автор Коръәннән аятләр китерү, хәдисләр һәм риваятләр өстәү юлы белән бу әсәрен тагын да камилләштерә, аны алтмыш алты мәҗлескә бүлә һәм аңа «*Зөһрәт әр-рийаз вә нөзһәт әл-колүб әл-мирадз*» (Бакчаларның матурлыгы һәм сырхау йөрәкләрнең юанычы) дип исем бирә. Шулай ук бу хезмәт «Бәһҗат әл-әнвар вә раузат әл-әфкяр», «Нөзһәт әл-колуб әл-мирадз», «Зөһрәт әр-рийаз вә шифа әл-колүб әл-мирадз» исемнәре астында да Урта гасырлар сүз сәнгатендә киң таралыш тапкан.

Әсәрнең композицион корылышы Урта гасырлар Шәрык әдәбияты традицияләре кысаларында башкарылган: ул 66 (аерым бер нөсхәләрдә 70 кә җитә) бүлек – *мәҗлес*кә бүленгән. Һәр мәҗлес билгеле бер хәдис белән башланып китә. Бу җәһәттән караганда ул Алтын Урда чоры әдибе Мәхмүд бине Галинең «Нәһҗ әл-фәрадис» (Оҗмахларның ачык юлы) әсәре белән аваздаш. Хәдисләр, нигездә, алга таба китереләчәк текстның мәгънәви эчтәлеген билгели. Еш кына автор тарафыннан әйтелгән уй-фикер аерым риваять һәм хикәятләр ярдәмендә ныгытып барыла, нәтиҗә ясала. Әйтик, дөньяның яратылышы, Кәгъбәнең барлыкка килүе, Гарәфә көн, Тәрвийә көненең барлыкка килүе, Таифә кызы, Хөсәен бине Галинең шәһид булу тарихы, елан турындагы хәбәр-риваятьләр әнә шундыйлардан.

Сөләйман бине Дауднын «Зөһрәт әр-рийаз...» исемле әсәр язганлыгы мәгълүм булса да, аның кульязмалары XX гасыр азагына кадәр татар медиевистикасы өчен билгеле булмады. Дөрес, Шиһабетдин Мәрҗани әлеге әсәрнең бер нөсхәсе үз кулында булганлыгын хәбәр итә [Мәрҗани, 1897], Морад Рәмзи Мәккәдә яшәгән вакытларында «Зөһрәт әр-рийаз»ның таркау бер кульязмасын күрүе турында искәртә [Рәмзи, 1908]. XX гасырның соңгы чирегендә Төркиянең Төп Капу музеенда «1420» саны белән бу ядкярнең бер күчермәсе саклануы мәгълүм була. Шушы ук вакытларда тарихчы-галим Сөләйман Рәхимов тарафыннан Төркиянең «Сөләймания» китапханәсе фондларында «Зөһрәт әр-рийаз...»ның берничә кульязма нөсхәсе барлыгы ачыклана һәм араларыннан иң борынгысының копиясе алына. Тәбриз шәһәрендә 1329 елда күчереп язылган бу нөсхәнең копиясе бүген Татарстан Милли китапханәсе фондларында саклана.

Хаҗи Хәлифә мәгълүм китабының бер урынында «Зөһрәт әр-рийаз» әсәре киң билгеле булмады, дигән фикер белдерә. Әмма әлеге әсәрнең кульязма нөсхәләренә күз ташлау белән үк бу фикернең бәхәсле булуы ачык күренә. Безнең тарафтан бүген Россия һәм Төркия, Иран, Голландия, Франция, Германия кебек илләр архивларында Сөләйман бине Дауд әс-Сувари әс-Саксини әсәренең ике дистәгә якын күчермәләре барлыгы ачыкланды. Аларның кайберләре тулы вариантта, кайберләре исә *мунтәхәб*, ягъни кыскартылган яки сайлап тупланган шәкелдә күчерелгәннәр. Әйтик, Төркиядә аларның саны дистәдән артып китә: иң борынгы нөсхәсе югарыда телгә алынган «Сөләймания» китапханәсендә «Tirnovali 968» шифры белән саклаучы нөсхә (Тәбриздә 1329 елда күчерелгән). Моннан тыш түбәндәге кульязма нөсхәләр игътибарга лаек:

1. Амасия Ил Халык көтепханәсендә саклаучы кульязма (*05 Ba 707. Zehretü'r-Riyâz. Tâc el-İslâm Süleymân b. Dâ'ûd es-Sebtî es-Sivârî (öl. 550/1155 civarı). Amasya Beyazıt İl Halk Kütüphanesi. 223 б.*) Күчерелү вакыты – 853 (1448) ел.

2. Эрзурум Ил Халык китапханәсендә саклаучы нөсхә *(25 Hk 23918. Zehretü'r-Riyâz ve Nuzhetü'l-Kulûbi'l-Miraz. Süleymân b. Dâvud es-Saksinî (550/1155 civarı sağ).* Күчерелү вакыты – 1319 (1900) ел. *Erzurum İl Halk Kütüphanesi. 290 б.*); Шунда ук тагын бер нөсхә саклана (*25 Hk 23936. Zehretü'r-Riyâz ve Nuzhetü'l-Kulûbi'l-Miraz. Süleymân b. Dâvud es-Saksinî (550/1155 civarı sağ). Erzurum İl Halk Kütüphanesi. 288 б.*) Күчерелү вакыты – 874 (1469) ел.

3. Анкара Милли Китапханәсендә 1449 елда күчерелгән бер нөсхә бар. (*06 Mil Yz B 412. Zehretü'r-Riyâz ve Nüzhetü'l-Kulûb. Süleymân b. Davûd es-Sevârî. Milli Kütüphane-Ankara, Milli Kütüphane Yazmalar Koleksiyonu. 177 б.*) Күчерелү вакыты – 853 (1449) ел.

4. Иранның Ислам Шурасы Мәҗлесе китапханәсендә саклаучы 1791 елда Гөлмөхәммәд Бәһәрпури исемле кеше тарафыннан күчереп язылган нөсхә. Аерым төпләнгән ике кульязмадан гыйбарәт.

5. Мисырда Каһирәнең Фуад Сәгыйди исемендәге китапханәсе фондында хисапка алынган кулъязма. Монда авторның яңа бер ләкаб-тәхәллүсе ачыклана – әл-Каини.

5. Франциянең Милли Китапханәсендә саклanучы 1607 елда Әхмәд бине Хозыр исемле хаттат тарафыннан күчерелгән нөсхә.

6. Лейпциг китапханәсе фондларында саклanучы нөсхә. Мунтахәбә варианты. Күчерелгән вакыты билгеле түгел.

Россиядә Дагыстан Тарих, археография һәм этнография институты архивында 2 кулъязма нөсхә, Казанда Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас Үзәгендә XVIII–XIX гасырларда күчерелгән бер нөсхә һ.б. кулъязма списокларны атап үтәргә мөмкин. Моннан тыш күренекле татар археографы Зәйнәп Максудова туплаган һәм өйрәнгән кулъязмалар арасында да әлеге әсәр текстларын үз эченә алган кулъязмаларның булуы турында да хәбәрләр бар [Бустанов, 2019 с. 107, 181, 200].

Сөләйман бине Дауд әс-Сувари әс-Саксининың мәгълүм бу әсәре үзеннән соңгы әдәбиятка һәм дини фикер үсешенә зур йогынты ясый. Бу мәсьәлә алга таба аерым өйрәнүне сорый. «Зөһрәт әр-рийаз»-дан алынган хикәятләрне XV гасыр госманлы галиме Ягъкуб бине Сәид Гали язган *«Мәфатих әл-җәнан фи шәрхе шәригат әл-ислам»* әсәрендә, XVI йөз ядкяре *«Бостан әл-кодус вә Гөлестан әл-Өнес»*тә, Мөхәммәд Чокыраклызадәнең *«Алты бармак»* китабында, XIX гасыр татар галиме Хөсәен Әмирханның *«Нәҗм әт-тәварих»* һ.б. әдәби-тарихи һәм дини әсәрләрдә күрергә мөмкин. Бу исә әлеге ядкярнең безнең төбәктә генә түгел барлык мөселман дөньясында киң таралыш алуын тагын бер кат раслап тора.

**Әдәбият**

*Бустанов А.К.* Библиотека Зайнап Максудовой. М., 2019. 464 с.

*Васильев Д.В.* Город Саксин: местоположение и население (по письменным источникам и материалам Самосдельского городища) // Ученые записки Казанского университета. Серия: Гуманитарные науки. 2015. Т. 157. № 3. С. 12–24.

*Васильев Д.В.* Дельта Волги в XIII веке (по материалам Самосдельского городища и новых памятников, выявленных в дельте) / Диалог городской и степной культур на евразийском пространстве. историческая география Золотой Орды. Материалы Седьмой Международной конференции, посвящённой памяти Г.А. Фёдорова-Давыдова. Под редакцией С.Г. Бочарова и А.Г. Ситдикова. 2016. С. 153–155.

*ал-Гарнати А.Х.* Сочинения. М.: Директ-Медиа, 2010. 184 с.

*Мәрҗани Ш.* Мөстәфад әл-әхбар фи әхвале Казан вә Болгар. Казан. 1897.

*Рәмзи М.* Тәлфикъ әл-әхбар вә тәлкыйх әл-әсар фи вакаигъ Казан ва Булгар ва мөлүк әт-татар. Оренбург, 1908. (гарәп телендә)

*Хәлифә Хаҗи.* Кәшф әз-зөнүн ган әсами әл-көтүб вә әл-фөнүн. I, II томнар. Бәйрүт: Дар Ихъйа әт-турас әл-гараәби. (гарәп телендә)

*Шарафутдинов Д.* Рукопись из древноего Саксина // Эхо веков. 2003. № 1/2.

***Гомәров Илһам Госман улы,***

*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире*

УДК 821.512.145

***Л.Р. Надыршина***

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ШИГЪРИЯТЕНДӘ ЭКЗИСТЕНЦИАЛЬ МОТИВЛАР

В статье рассматриваются экзистенциальные мотивы в поэзии Габдуллы Тукая. Автор акцентирует внимание на семантических особенностях отдельных мотивов лирики поэта. В статье выделены и проанализированы наиболее частотные экзистенциальные мотивы в поэзии Г. Тукая: угасание, отчуждение, одиночество, обреченность и бессилие перед судьбой. Автором статьи установлены социально-политические и биографические предпосылки экзистенциального мировосприятия поэта, сделан вывод о национальной семантике изучаемых мотивов.

**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, мотив, поэзия, экзистенциальная картина мира, поэтика.

In this article existential motives in Gabdulla Tukay's poetry are considered. The author focuses on the semantic features of individual motives of the poet's lyrics. The article highlights and analyzes the most frequent existential motives in G. Tukay's poetry: extinction, alienation, loneliness, doom and impotence before fate. The author of the article establishes the socio-political and biographical prerequisites of the poet's existential worldview, concludes about the national semantics of the studied motives.

**Keywords:** Gabdulla Tukay, motive, poetry, existential picture of the world, poetics.

XX йөз башында татар әдәбиятында, шул исәптән поэзиядә дә, кискен индивидуализм һәм төшенкелеккә бирелү берлеген хасил иткән экзистенциализм агымы шактый зур урын ала. Чарасызлык, үлем, җәза, ялгышу һ.б. төшенчәләр милләт, халык язмышы турындагы гамьнәрне бер ноктага җыя һәм әдәбиятта төп мотивларның берсенә әверелә. Н. Исәнбәт, С. Сүнчәләй, Ф. Бурнаш, Б. Мирзанов, Ф. Ибраһимов кебек авторларның иҗатында гареб әдәбияты рухында язылган экзистенциаль үрнәкләр күзәтелсә, XX йөз башында иҗат иткән башка шагыйрьләрнең әсәрләрендә бу фәлсәфәгә хас аерым мотивлар (елау, ялгызлык, үлем, чарасызлык, өметсезлек һ.б.) киң тарала. Тукай иҗатында да экзистенциаль дискурс, нигездә, мотивлар дәрәҗәсендә чагылыш таба.

Тукай шигъриятенең Уральск чорында экзистенциаль мотивлар аерым бер үрнәкләр белән генә чикләнә, алар сызлану фәлсәфәсе контекстында каралмый, ә бәлки халык әдәбияты традицияләре кысаларында кабул ителә. Әйтик, шагыйрьнең шәркый традицияләр йогынтысында язылган «Ифтиракъ соңында» (1906); «Сәгадәт юк, фәкать наме сәгадәт...» (1906), «Дәрдемәнд дәгелмием?» (1906) кебек мәхәббәт лирикасы үрнәкләрендә сызланулы хиссият билгеле

бер дәрәҗәдә урын ала. Тикшерүчеләр билгеләп үткәнчә, көнчыгыш әдәбияты белән аваздашлык образлар системасы, поэтика дәрәҗәсендә чагылыш таба. Лирик герой мәхәббәттән акылын җуйган, җанын biләгән сөю хисеннән өзгәләнгән шәхес буларак ачыла [Материалы, с. 375], шул рәвешле, әлеге шигырьләрдә мәхәббәт газабы төп мотив буларак формалаша.

Жанры буенча пейзаж лирикасына караган «Яз» (1907) шигырендә капма-каршы семантикалы мотивлар берлеге – яз фасылына бәйле яңару һәм кыямәт көне, ахырзаман белән ассоциацияләр рәвешендә чагылган бетү, юкка чыгу мотивлары – үзара бинар оппозициядә килә. Шул рәвешле, шигырьдә ике катлы дөнья сурәте торгызыла: язгы күренешләрне тасвирлаган пейзаж өлеше ахырзаман турында искәрткән куркыныч, шомлы сурәтләр белән алмашына: *Төшерә искә язның бу томаны / Дөханы ахыр – ахыры заманы. <...> Белерсең син боларның мәхшәре дип, / Бу бозларны – үлекләр гаскәре дип; / Өрелмеш дип белерсең санки мөгез, / Вә яки мөгезен селкеткән үгез. / Болар әллә бара дәһшәтле судка, / Беленми: кайсы – җәннәт, кайсы – утка / Бу галәмне тота бертөрле каушау. / Бөтенләй болганадыр, килә шау-шау* [Тукай, 1 том, б. 167]. Әлеге ассоциатив сурәттә чагылган юкка чыгу мотивы чарасызлык, үлемнең котылгысызлыгы, газап кебек экзистенциаль фикерләү тибына бәйле башка мотивлар хисабына тулыландырыла, дини инануларга ишарәләгән образлы ассоциацияләр яшәешнең фанилеге турында уйлануларга җирлек әзерли. Киләсе строфаларда бу хыялый сурәт яңадан чынбарлык тасвиры белән алмашына, салмак, тыныч интонация алгы планга чыга. Хисси-психологик кичерешләрендә ике дөнья – фани һәм бакый дөньялар чигендә калган лирик герой уйлануларына нәтиҗә буларак яңгыраган соңгы строфа яшәешнең табигый канунын раслау буларак укыла: *Шулай шул: уйлата яз төрле якны, / Димәк ки – бер мәматны, бер хәятны* [Тукай, 1 том, б. 167].

Г. Тукайның «Сөальләр» (1907), «Дөньяда торыйммы? – дип киңәшләшкән дустыма» (1907) шигырьләрен фәлсәфи тематиканы калкыткан әсәрләр рәтендә карарга мөмкин, һәм аларда нәкъ менә экзистенциаль дөнья картинасы үзәктә тора. Әйтик, беренче шигырьдә лирик геройның Илаһка юнәлдерелгән монологы экзистенциаль эчтәлекле: ул яшәешнең гаделсезлеген, кешенең язмышы алдан билгеләнгәнлеген, тәкъдирне үзгәртүнең мөмкин түгеллеген аңлаудан туган фаталистик уйлануларны үз эченә ала. Монологның риторик шәкелдә бирелүе бу уйларны тагын да тирәнәйтә һәм әсәрдәге төп мотив – газап мотивын нигезли: *Йа Ходая! нигә төрле-төрле кыйлдың бәндәни? / Ни сәбәб соң җөмлә әдна бәндәләрдән бән дәни? / Ник бәни шад идмәдең, ник әйләдең гамь һәмдәми? / Юхса бәхре гамь мәсиле, мәнсабе дә бәндәми?* [Тукай, 1 том, б. 149]. Газаплы халәт, киләсе строфаларда тагын да үстерелеп, кеше яшәешенең аерылгысыз бер өлеше буларак раслана, газап мотивы тәкъдир, язмыш мотивлары белән семантик бәйләнештә бирелә. Кеше, никадәр генә тырыш-

са да, газапланса да, язмышын үзгәртә алмый дигән фикер шигырьдә кызыл җеп булып уза.

XIX йөзнең икенче яртысы һәм XX йөз башы – татар халкының уяну, милләт буларак формалашу, милли азатлык өчен көрәш чоры. Бу чорга милли аң уяну, әдәбиятта, сәнгатьтә милли идеяләргә игътибар арту, милли мәсьәләләрнең һәм милләткә мәхәббәт тойгыларының үзәктә булуы хас [Ханнанова, б. 46]. Шушы олы үзгәрешләрнең үзәгендә торган шәхес буларак, Тукай шигырьләрендә экзистенциаль мотивлар да еш кына иҗтимагый алшартлана һәм шагыйрьнең дөньяга карашларын, заманга, чорга бәясен җиткерүнең бер чарасына әйләнә. Татар халкының тарихы, үткәне, хәзергесе белән бәйле хәсрәтле-ачынулы уйланулар Тукай шигырьләрен сызланулы рухка көйли, иҗтимагый дискурс татар халкының данлы, әмма моңлы, фаҗигале тарихи сәхифәләрен ачып бирү вазифасына хезмәт итә. Әйтик, «Кичке азан» (1906) шигырендә бер төенгә тупланган төрле экзистенциаль мотивларның (елау, өметсезлек, гомернең бетүен аңлау, бәхилләшү) нәкъ менә шушы модификациясе алга чыга. Азан тавышы тәэсирендә лирик герой күңелендә туган тетрәнүле уй-кичерешләр, сагышлыхәсрәтле гамьнәр татар халкының тарихын, язмышын, төрки дөнья фаҗигасен аңлау белән бәйле. Касыйм, Казан, Әстерхан һ.б. юкка чыгарылган дәүләтләрне бер-бер артлы санап китү, бердән, дәүләтчелекне югалтудан туган ачынулы үкенү хисен көчәйтә, икенчедән, дини эчтәлекле азан мотивы белән янәшәлектә, һәр яшәешнең бетүгә юнәлгәнлеге, бар нәрсәнең вакытлыча булуы турындагы фәлсәфи күзаллауны алга чыгара, «инде беттек» гыйбарәсен кабатлау аша шагыйрь бу идеяне шигырьгә лейтмотив итеп кертә: *Инде беттек; / Бетәргә сүз- / не беркеттек; / Вактында җир- / не селкеттек, / Инде беттек, / Инде беттек!* [Тукай, 1 том, б. 135]. Тукай татар халкы яшәешен үткән – бүгенге – киләчәк берлеге буларак күзаллый һәм инкыйраз мотивын ерак гасырлар аша үз чорына китереп җиткерә, XX йөз башында хөкем сөргән милли таркаулыкны кире кага, татар халкын юкка чыгарачак төп фактор буларак карый. Үлем, бәхилләшү мотивлары белән тулыландырылган инкыйраз мотивы милләт киләчәгенә өметне юк дәрәҗәсенә җиткерә, «инде беттек» гыйбарәсенең гомумфәлсәфи мәгънәсеннән тыш икенче – милли семантикасы калкып чыга, лирик геройның сагышлану, хәсрәтләнү хисенең дә төп сәбәбе милли гамьнәр белән алшартлана. Шигырдә урын алган экзистенциаль мотивлар милли яссылыкта карала, милләт фаҗигасен аңлап сыкрану әсәрне үтәли иңләп уза.

Иҗатының Казан чорында (1908–1913) Г.Тукай әсәрләрендә лирик, романтик аһәңнәр көчәя, шул кысаларда кулланылган аерым бер экзистенциаль мотивларның семантикасы үзгәреш кичерә: хәзер инде алар лирик геройның эмоциональ күңел халәтен, дөньяны күзаллавын җиткерүгә буйсындырыла. Бу чорда иҗат ителгән шигырьләрдә еш кына яшәүнең чикләнгәнлеге, вакытның тиз агышы турында уйланулар белән нигезләнгән фәлсәфи башлангыч алга чыга, автор

кешеләрдән, тормыштан ваз кичкән шәхес буларак күзаллана. Хәсрәтләнү, сагышлану, күз яше түгү, газап, өметсезлек, дөньядан тую, күңел төшенкелеге, ялгызлык һ.б. мотивлар күп кенә әсәрләрдәге дөнья сурәтенең үзәгендә тора. Тукай шигъриятендә мондый тенденция иҗтимагый-сәяси һәм биографик факторлар белән алшартлана. Мәгълүм булганча, 1905–1907 елгы инкыйлаб дулкыннары тынгач, илдә кара реакция еллары башлана, һәм ул милли мәдәният үсешенә зур киртә була. Рөхсәт алу өчен күп тырышлык куеп дөньяга чыгарылган газета-журналлар ябыла башлау, күп кенә татар әдипләренең жандармерия эзәрлекләвенә дучар булуы, китапларын конфискацияләү, тикшерү, цензураның артык катгыйлыгы нәтиҗәсендә сүз иреге кысылу һәм башка шундый тискәре үзгәрешләр татар әдәби-мәдәни мохитендә гомуми төшенкелеккә китерә, шушы чорда иҗат иткән татар әдипләренең әсәрләрендә яшәеш ямьсезлегеннән зарлану, хәсрәт, өметсезлек, моңлану, киләчәккә ышанычны югалту кебек мотивлар төп эчтәлекне хасил итә. Реакция нәтиҗәсен анык татыган, тормышыннан, яшәү шартларыннан канәгать булмаган, рухи тынычлык таба алмаган Тукай шигырьләренә дә шәхси җирлекле экзистенциаль мотивлар үтеп керә. Шагыйрь күңелен биләгән төшенкелек, өметсезлек, чарасызлык хисләре аның «Бер кайгы көнендә» (1908), «Теләү бетте» (1909), «Өзелгән өмид» (1910) кебек шигырьләрендә төп урын били. Мәсәлән, «Бер кайгы көнендә» шигырендә (аның беренче варианты «Күңелсез минутта» дип бастырылган булган, 1912 елда дөнья күргән җыентыкта инде исеме үзгәртеп бирелгән) күңел төшенкелегенә бирелгән лирик герой халәте рухи кризис кичергән шагыйрьнең үз кичерешләре булып укыла, бетү, гомернең узуы, бәхетле үткәннең кире кайтмаячагын аңлау әсәрнең төп эчтәлеген нигезли, бу мотивлар беренче строфада ук калкытыла: *Беттем мин, яшь малай, беттем гомергә дә; / Эссе кан, көчле җан кайтмас гомер дә* [Тукай, 1 том, б. 230]. Икенче строфада югалту мотивын ялгызлык мотивы тулыландыра, ялгызлыктан туган бәхетсезлек хисе шигырьдә иң югары дәрәҗәсендә тәкъдим ителә: лирик герой *«Бар микән дөньяда миннән бәхетсезләр?»* дип өзгәләнә. Өченче строфада традицион образлар аша ачылган сагыш, газап мотивлары үзәккә куела: татар шигъриятендә киң кулланылган *зәгъфрандай саргаю* гыйбарәсенең үзгәртелгән варианты лирик геройның сагышлы халәтен ачу вазифасына хезмәт итә: *Саргайдым, зәгъфраннан сары мин, / Бу чокырлы йөзләр тулмас гомер дә* [Тукай, 1 том, б. 230]; ягъни аның хәсрәте тагын да олырак, тирәнрәк. Шул рәвешле, экзистенциаль иҗатка хас булган бетү, вакыт агышы, гомернең үтүе, ялгызлык кебек мотивлар татар әдәбиятында киң кулланылган традицион мотивлар хисабына семантик яктан тагын да көчәйтелә.

«Милли моңнар» (1909), «Милләтчеләр» (1908) кебек шигырьләрдә дөньяны экзистенциаль күзаллауга хас мотивлар милли контекстта яңгырый, татар халкы язмышы белән бәйле гамьнәрне җиткерү ысулына әйләнә. Әйтик, «Милли моңнар»да милләт тарихы,

халык язмышы мәсьәләләре «зарлы, моңлы» көй образына салынган сызлану, моңлану мотивы аша сәнгатьчә гәүдәләнеш ала, икенче-өченче строфада милли тарихның фаҗигале сәхифәләрен ачкан изелү (*Өзлеп-өзлеп кенә әйтеп бирә / Татар күңлениләр сизгәнен; / Мескин булып торган өч йөз елда / Тәкъдир безне ничек изгәнен* [Тукай, 2 том, б. 230]), михнәт чигү, күз яшьләре түгү (*Күпме михнәт чиккән безнең халык, / Күпме күз яшьләре түгелгән* [Тукай, 2 том, б. 230]) мотивлары бер бәйләмгә туплана. Дүртенче строфада килеп кергән Болгар һәм Агыйдел хронотоплары автор уйлануларында үткән һәм бүгенгене кисештерә, сызланулы, сыкраулы хиссиятне милли тарихтан хәзергегә кадәр суза.

Тукайның Казан чоры шигъриятенә хас экзистенциаль дөнья сурәте шагыйрьнең тормыш сәхифәләре белән турыдан-туры бәйле. Мәгълүм булганча, шагыйрь Казанга ашкынулы, өмет тулы хисләр белән рухланып килә, мондагы әдәби-мәдәни мохит аны үзенә тарта, әмма бередә ул хыял-омтылышларын тормышка ашыра алмый. Тукайның дусты, сердәше Ф. Әмирхан истәлекләрендә әйтелгәнчә, бер очрашканда шагыйрь Казанга килгәннән бирле соң дәрәҗәдә эшлексезләнүе, эшсез, идеалсыз, чиле-пешле кешеләр тирәсеннән котылырга теләве, ләкин үзендә шуңа көч таба алмавы турында ачынып сөйли [Тукай турында замандашлары, б. 80]. Бу рухи гасабилык шагыйрьнең авыруы белән көчәйтелә. Киләчәккә өмете сүнгән, гомеренең азагына якынлашуын аңлаган әдип иҗатында дөньяны экзистенциаль тоемлау зур урын ала башлый. Мәсәлән, «Өзелгән өмид» шигырендә сызлану фәлсәфәсенең төп категорияләреннән булган өметсезлек төшенчәсе көчле позициядә килә, әсәрнең исеменә чыгарылып, теманы билгели. Өметсезлек үзе төрле экзистенциаль мотивлар үрелмәсеннән оеша: яшьлекнең узуы, иҗат утының сүнүе, җиһанда үзеңне ят тою, читләшү, халкыңнан аерылу, сагыш, ялгызлык. Тикшерүчеләр билгеләвенчә, бу мотивлар семантик яктан бер-берсенә якын: аларда кире кайтарып булмаслык югалту бар. Нәтиҗәдә укучы лирик геройның барлык кыйммәтләрне югалтуы сәбәпле туган фаҗигасенә төшенә, бу халәт трагик пафоска тәңгәл килә [Әдәби, б. 33]. Шигырьдә гомернең үтүе, вакыт агышын туктатып булмау яшәешнең табигый кануны буларак кабул ителә *(Күз теген баксам әгәр дә тормышымның күгенә, / Яшь һилал урынында анда тулган айның яктысы* [Тукай, 2 том, б. 152]), һәм шушы хакыйкатьне аңлаудан туган чарасызлык хисе дүртенче строфада «мин сүнәмен» гыйбарәсендә реальләшкән сүнү/бетү мотивы белән кушылып китә. Кабатланып килгән «моңлы» эпитеты сагышлы эмоциональ-психологик халәтне билгеләүче төп берәмлек буларак кулланыла.

Лирик геройның ялгызлыгын тоюдан туган төшенкелек, өметсезлек хисләрен, ачынулы күңел халәтен ачып биргән елау мотивы да шигырьдә ике тапкыр кабатлана. Беренче очракта бу мотив кайгы-хәсрәт, күз яше түгү кешенең даими халәте икәнлеген раслау вазифасына буйсындырыла: *Күз яшең дә кипмичә еглап вафат булган әни! /*

*Гаиләсенә җиһанның ник китердең ят кеше?!* [Тукай, 2 том, б. 152]. Соңгы строфада елау мотивы яңадан калка һәм лирик геройның юану, бушану, рухи чистарыну мизгеле буларак укыла: *Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы, – Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!* [Тукай, 2 том, б. 152]. М. Ибраһимов билгеләвенчә, кабер ташы, дөнья әдәбиятындагы кебек үк, изге, сакраль урын, тормышның үзәге кебек аңлашыла башлый, символга әверелә, <...> хәтернең, ана – халык – милләт тарихын яшәртүче буларак, барлык кыйммәтләрдән өстенлеге хакындагы фикер калкып чыга. Ана кабере – яшь агызырлык изге урын булу лирик геройны кайгыга салган яшьлекнең узуы, иҗат дәрте сүнү, милләт киләчәгенә булган өметнең өзелүе тудырган фаҗигане киметә, үзенчәлекле фәлсәфи-моңлы өмет чаткысы пәйда була [Бу турыда: Әдәби, б. 34].

«Өмидсезлек» (1910) әсәрендә дә экзистенциаль яңгыраш әсәр исеменә чыгарылган темада ук ассызыклана. Өметсезлекнең сәбәбе – истибдад (реакция, искелек, тиранлык), һәм шуңа мөнәсәбәтле туган ачынулы-гасабилы халәт һәр строфаны иңләп үтә. Дөньядан ваз кичү, яшәеш кануннарын кире кагу – шушы халәтне нигезләгән төп мотивлар, лирик геройның мондый яшәештән үлемне артык күрүе аларның семантикасын билгели: *Тәндә җаным, чык та Тәңреңә юнәл, бар, кайт кире! / Китте җаннар азыгы, һәм кайтты истибдад кире* [Тукай, 2 том, б. 131]. Шигырьдә лирик геройның үзгәрешләргә мөнәсәбәтле күңел халәте эмоциональ каршылыклар рәвешендә ачып бирелә, һәм бу – әсәрнең композицион төзелешендә дә чагылыш таба: һәр строфа мәгънә ягыннан капма-каршы укылган икеюллыклар рәвешендә оеша. Мәсәлән, икенче строфада яңару һәм бетү мотивлары бинар оппозициядә килә: *Яз башы дип, башны калкытмагыз, и гөл-ганҗәләр! / Бел, янарсыз: җир хәзер ялкынлы истибдад җире!* [Тукай, 2 том, б. 131]. Алга таба өметсезлек, киләчәккә ышанычны югалту халәте белән сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендәге бетү/юкка чыгу мотивы яңадан берничә мәртәбә кабатлана, җир яшәешенең төп юлдашы итеп күрсәтелгән фөрьяд (зарлану, ыңгырашу) төшенчәсе экзистенциаль укылышны көчәйтә. Тукай яшәгән чор рухын ачып бирү максатына буйсындырылган яшәеш – җәһәннәм янәшәлеге шагыйрьнең шул еллардагы иҗтимагый-сәяси вазгыятькә бәясе булып аңлашыла.

Гомумән, шагыйрьнең Казан чоры иҗатында үзен ялгыз хис иткән, максат-омтылышларын бүлешүче булмавына, даирәсендә ялганчы, икейөзле затлар өстенлек алуына борчылган лирик герой шактый еш урын ала, бу аның шигырьләрендә җәмгыятьтән читләшү, качу, алдану, дөньядан ваз кичү кебек мотивларны активлаштыра. Мәсәлән, яшәеш ямьсезлеген аңлау, адашу, алдану, киләчәккә ышанычны югалту мотивлары Тукайның «Үкенеч» (1910), «Тәләһһеф» (1910), «Дошманнар» (1912) кебек шигырьләрен экзистенциаль укылышка көйли. Әйтик, «Үкенеч» шигырендә адашу һәм алдашу мотивлары лирик геройның эмоциональ халәтен билгели: ул дус итеп кабул иткән зат-

ларның «тышы яхшы, бозыклыгы эче» турында уйлана, изге юлдан адашуына борчыла, икейөзле, хыянәтчеләр даирәсендә калуына ачына, чарасызлыктан үрсәләнә. Шушы эмоциональ киеренкелек тәэсирендә шигырьдә ялгызлык һәм читләшү мотивлары көчле позициядә килә, бу мотивлар символик эчтәлекле йолдыз образы аша тәгъбир ителә: *Нигә мин тормадым бер читтә ялгыз – / Ничек күктә яна бер данә йолдыз? / Шулай янсам, ни булды, төшми җиргә, / Якынлашмыйча һәр мәгърур сәфилгә! / Янып ялгыз шулай, күп еллар үткәч, / Сүнәр идем, Ходайдан вәгъдә җиткәч* [Тукай, 2 том, б. 133]. Ялгызлык мотивы, семантик яктан үстерелә килеп, лирик геройның хәятен тасвирлаган караңгылык төшенчәсендә бөтен тулылыгы белән ачыла, психологик кичерешләрдә реальләшкән өмет сүнү мотивы белән тулыландырыла: *Әсирмен, ычкыналмам инде мәңге, / Күңелсез һәр ягым – нурсыз, караңгы! / Монафикълар камап һәр дүрт ягымны, / Күрәлмим мин кояшым һәм аемны. / Кырылды алда изге эшкә вәгъдәм, / Караңгыда күренми чөнки кәгъбәм!* [Шунда ук]. Соңгы строфада көрәш һәм бетү мотивлары семантик каршылык барлыкка китерә: *Читен хәл. Гайрәтең җитсә – ерып чык, / Әгәр җитмәс исә – бет, шунда тончык!* [шунда ук], бу каршылык яшәеш кануннарын калкыткан фәлсәфи бетем буларак укыла, шулай ук лирик геройның бу яшәештән канәгатьсезлеген дә бөтен төсмерләре белән ачып бирә.

Гомеренең соңгы елларында каты авыруы сәбәпле дөньяга сызлану, газап, хәсрәтле моң күзлегеннән караган шагыйрь әсәрләрендә аның шәхси кичерешләрен чагылдырган экзистенциаль мотивлар аеруча киң кулланыла башлый. Әйтик, гомернең азагы якынлашуын аңлау, үлем көтү, сүнү/бетү кебек мотивлар «Кичке теләк» (1912), «Үтенеч» (1912), «Хәстә хәле» (1913), «Кыйтга» (1913) кебек шигырьләрне бер бәйләмгә туплый, аларда лирик герой дөньядан гайрәте чиккән, язмыш караңгылыгыннан алҗыган, яшәүнең мәгънәсезлеген аңлаган халәттә сурәтләнә, аның сызланулы кичерешләре лирик-эмоциональ эчтәлектә ачыла. Караңгылык/золмәт төшенчәләре әсәрләрдәге дөнья сурәтенең төп категорияләренә әйләнә. Мәсәлән, «Кичке теләк» шигырендә әсәрнең исемендә үк урын алган хронотоп лирик геройның рухи халәтенә, яшәешкә мөнәсәбәтенә ишарә итә: кич – көннең азагы, экзистенциаль укылышта ул гомер кояшы сүнү белән ассоциацияләшә, гомер соңына керү рәвешендә кабул ителә. Иҗат мотивы күңелендәге шигырьләрен ак кәгазьгә төшереп калдырырга ашкынган шагыйрь образын нигезли, аның төшенкелек, авыр уйлар белән тулы кичерешләре *сүнгән лампа* метафорик образы аша җиткерелә: *Күп тә үтмәстән, утым ялт-йолт итә һәм селкенә, / «Гөлт!» итеп актык нурын бер күрсәтә, аннан сүнә* [Тукай, 2 том, б. 235]. Шунысын искәртү зарур: шәм/ут сүнү мотивы татар әдәбиятында традицион мотивлардан санала, XX йөз башы татар шигъриятендә ул милли эчтәлек белән баетыла, милләтнең алгарышы, киләчәге белән бәйле уйлануларны җиткерү чарасына әйләнә, караңгылык, төн образлары бу мотивның юлдашына әверелә (Хәбибулла Габидов

«Нигә бу шәмнәр сүнә?», 1914 һ.б.). Тукайның әлеге шигырендә ут сүнү мотивы шагыйрьнең күп кенә шигырьләрендә кабатланган өметсезлек мотивын яңарта: өмет сүнүе буларак укыла. Кабатланып килгән караңгылык төшенчәсе лирик герой яшәешен характерлаучы доминанта образга әйләнә, елау мотивы хәсрәтле, сагышлы хәятнең төп юлдашы булып кабул ителә: *Нишлисең? Һәр якта золмәт. Ихтыярсыздан ятам; / Мин, ятып, яткан җиремдә төрле уйларга батам. / Мин, караңгылык эчендә уйланып яткан көйгә, / Нечкәреп күңлем, җылыйм да бер сүз әйтәм лампага* [шунда ук]. Шигырь дәвамында кешене өмет яшәтүе турындагы фикер үстерелә килә, һәм шигырьнең соңгы строфасында өметсезлек иң югары дәрәҗәсенә җитә, иҗат уты сүнү – өмет сүнү, ә өмет сүнү – үлемгә тиң дигән идея булып формалаша: *«Ни бәхет! – дим, – иртәгә кич син тагын да янмасаң, / Бу ятыштан мин дә мәхшәр җитмичә кузгалмасам!»* [Шунда ук].

Гомер азагында иҗат ителгән шигырьләрендә Тукай үлем, әҗәл көтү мотивларына да мөрәҗәгать итә. XX йөз башы татар әдәбиятындагы модернистик күренешләрне җентекле өйрәнгән Д.Ф. Заһидуллина билгеләвенчә, XX гасыр башы татар әдәбиятында үлемне куркыныч, фаҗига дип аңлаудан аның кешене яшәү газабыннан азат итү мөмкинлеген тануга кадәр ара узыла, кайбер әсәрләрдә әҗәл яшәүгә нокта куючы булса, кайсыларында аның дәвамы ролен уйный. Кайбер авторлар үлемне тормыш аһ-зарыннан котылу мөмкинлеге итеп карый [Заһидуллина, б. 114]. Тукайның «Читен хәл» (1911) шигырендә яшәү һәм үлем фәлсәфәсе нәкъ менә шушы яссылыкта бирелә. Тулаем экзистенциаль эчтәлектә иҗат ителгән бу әсәрдә дөньядан ваз кичкән лирик герой күз алдына килеп баса. Беренче строфада аның үкенечле, ачынулы психологик халәте дөньяга туганыңа үкенү, суфичылык әдәбиятыннан килгән шәраб эчү мотивын семантик яктан капма-каршы эчтәлектә бирү хисабына ачыла: *Ни була тугмак сыйратын кичмәсәм, / Бу ачы гомрем шәрабен эчмәсәм?!* [Тукай, 2 том, б. 192]. Икенче строфада яшәешнең табигый агышын инкяр итү һәм яшәүдән тую мотивлары бер-берсен тулыландырып, семантик бөтенлек барлыкка китерә: *Әйләнә бит, үтми, бетми гомре дә! – / Килә утлар чәчеп, син кышласаң* [шунда ук]. Шагыйрьнең өметсезлек, рухи төшенкелек тулы халәтен җиткерүгә, яшәешкә, дөньяга, язмышка ачуын һәм газаплы-ачынулы уйларын ачып бирүгә юнәлдерелгән көтелмәгән ассоциацияләр сискәндереп җибәрә: *Каршыма чыкма, кояш, син – канлы тап! / Ак кәфендәй син җәелмә өсткә, таң!* [Шунда ук]. Тормыш ямьсезлегеннән, дөнья караңгылыгыннан алҗыган халәттә төп юаныч – үлем көтү, бу фикер шигырьдә беренче строфадан ук кабатлана, шул рәвешле, сызлану белән бәйле эчтәлек көчәйтелә: *Ардым инде, кайда актык мәүфыйкем? Җилкенәмен – бер басарга өч басам; Катле нәфситсәм, Ходайдан куркамын, / Ләкми чир, аурып та булмый, ичмасам!* [Шунда ук]. Тукай шигъриятендә мондый тенденция «Хәстә хәле» шигырендә дә урын ала. Әсәрнең һәр строфасында башка экзистенциаль мотивлар белән үрелгән

өметсезлек мотивы калкытыла, әйтик, беренче строфада ул яшәү мәгънәсен җую, йокысызлык, төш мотивлары белән бәйле булса (*Көн туа. Һәр көнне хикмәт, мәгънәдән буш эш күрәм; / Күз йомалмыйм төн буе, йомсам – коточкыч төш күрәм* [Тукай, 2 том, б. 277]), икенче строфада кешеләрнең икейөзлелеге, чын йөзләрен битлек астына яшерүләренә бәйле алдану һәм читләшү мотивлары белән тыгыз бәйләнә *(Юк янымда чын кеше, булганда да – мин чит күрәм*; / *Белмәдем капшап, фәкать һәр йөздә кәгазь бит күрәм* [шунда ук]), гомумән, лирик геройның экзистенциаль кичерешләре строфа саен үстерелә килә, иман, мәрхәмәт, шәфкать, мәхәббәт кебек иң төп кыйммәтләрдән мәхрүм калган җиһанның ямьсезлеге, зәмһәрир суыклыгын образлы итеп ачып бирү җан туңу мотивы аша тормышка ашырыла: *Бетте иман, мәрхәмәт, шәфкать, мәхәббәткә тәмам; / Бәйле корбанлык кеби, алда кызыл кан, ит күрәм. / Бар хәятем салкыныннан туңды җан, катты күңел; / Һәр ягында бар җиһанның зәмһәрирдән чик күрәм* [шунда ук]. Шигырь, гомумән, тулысы белән яшәеш ямьсезлеген раслауга буйсындырылган, строфа саен җанны чолгап алган торгынлыктан котылуның мөмкин түгеллеге, җиһан кануннарының тамырдан үзгәрүе, мантыйкка сыешсызлыгы ассызыклана килә, җиденче-сигезенче строфаларда бу фикерләр иң югары дәрәҗәсенә җитә: *Акмый тышка мәгънәләр – кипкән күңелнең чишмәсе. / Калган урнында һәлакәт чокры, баткаклык күрәм. / Юк нәҗат, фикрем чөерсәм дә үземнән үзгәгә; / Козгын – ислам гәүдәсендә, кәгъбәсендә пот күрәм* [шунда ук]. Лирик герой күңелен биләгән чарасызлык, өметсезлекнең соң чиккә җитүе үлемне яшәеш авырлыкларыннан котылу чарасы итеп күрүдә чагылыш таба: *И үлем! Мин син бер хәсрәт вә бер шатлык күрәм* [шунда ук]. Шигырьнең соңгы строфаларында хәстәлек мотивы физик һәм рухи газаплардан өзгәләнгән лирик геройның сызланулы кичерешләре аша реальләшә, ул инде язмышына буйсынган, көрәшеп арыган халәттә күз алдына килеп баса, укучы шагыйрь җанын биләгән тирән сагыш, сызлануны ачык тоя: *Ауру җанның бишмәте-тәнне дәваның төрлесе / Берлә һәр көнне ямыйм, иртән тагын ертык күрәм* [шунда ук]. Соңгы строфадагы өзелгән җыр образы укучыны янып-яшьнәп торган иҗат утының сүнүенә шаһит итә: *Бар иде ялгыз калып, җырлап юанган чакларым, / Ярты җырда инде күкрәкне тотам да йөткерәм!* [Шунда ук].

«Кыйтга» (1913) – Тукайның эчке дөньясын, гомеренең азагына якынлашуын сиземләүдән туган ачынулы җан авазын чагылдырган шигырь, сызланулы үкенү хисе әсәрнең лейтмотивына әверелә, аның һәр сүзеннән сагыш, бетмәс газап тама кебек. Беренче строфада көчсезлек, гомер ахырын тою, үткәннәрне уйлап үкенү мотивлары шигырьне экзистенциаль укылышка көйли, лирик геройның яшәешен характерлаган *кара көннәр* метафорасы аның күңел халәтенә аваздаш яңгырый: *Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым, / Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым* [Тукай, 2 том, б. 284]. Икенче строфада исә шагыйрьнең үзе буларак күзалланган лирик ге-

ройның яшәү позициясе ачыла: *Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым, / Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым* [шунда ук], ягъни хакыйкатькә тугрылык – аның тормыш һәм иҗат мәсләге. Өченче строфада үкенү мотивы семантик төсмерләр хисабына баетыла, гомеренең азагы якынаюын, язмыш каршында көчсезлекне аңлаудан туган өметсезлек мотивы белән кушылып, үзенең шагыйрьлек миссиясен дөньяны агартуда күргән, әмма омтылыш-тырышлыкларының юкка булуына төшенгән шагыйрьнең ачынулы җан авазын җиткерә: *Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш: / Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым* [шунда ук].

XX йөз башы татар шигъриятенең әһәмиятле бер үзенчәлеге – шәрык һәм гареб әдәби традицияләренең гаҗәеп синтезы. Сызлану фәлсәфәсенә хас үзенчәлекләр турында сүз алып барганда да, без экзистенциаль характердагы мотивларның шәрык әдәбияты йогынтысында үскән татар сүз сәнгате өчен дә ят булмавын билгеләргә тиеш: хәсрәтләнү, елау/сыктау, ялгызлык, җәмгыятьтән читләшү кебек мотивлар татар әдәбиятында киң таралган, XX йөз башындагы яңа тенденцияләргә бәйле рәвештә, гареб әдәбиятларына хас экзистенциализм фәлсәфәсе шушы җирлектә үсеп китә. Аерым бер шагыйрьләр иҗатында шушы яңа рухтагы агым төп үсеш юнәлешләрен билгеләп, әдипнең дөньяга карашын җиткерүдә төп терәк булып торса, күпчелек сүз ияләрендә, шул исәптән Тукай иҗатында да, ул аерым агым рәвешендә үсеп китми, теге яки бу шигъри үрнәкләрдә хис катламын, идеяне җиткерү өчен нигез булып тора. Ә инде Тукайның эчтәлеге, идеясе, фикер сөреше ягыннан тулаем сызлану фәлсәфәсе кысаларында каралырлык әсәрләре биографик фактлар белән алшартлана: аларның барысын да шагыйрь гомеренең соңгы елларында иҗат иткән һәм бу шигырьләренә күңелендәге чиксез үкенеч, хәсрәт, газапларын сыйдырган.

### Әдәбият

Әдәби әсәргә анализ язау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / Д.Ф. Заһидуллина, М.И. Ибраһимов, В.Р. Әминева. Казан: Мәгариф, 2005. 111 б.

Габдулла Тукай. Энциклопедия / Баш мөх. З.З. Рәмиев. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. 864 б.

*Загидуллина Д.Ф.* Основные мотивы поэзии Габдуллы Тукая: отражение посвященной народу жизни // Научный Татарстан. 2011. № 2. С. 46–52.

*Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 255 б.

Материалы к хронике жизни и творчества Габдуллы Тукая (1886-1907). Казань, 2018. 448 с.

*Тукай Г.* Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 1 т.: шигъри әсәрләр (1904–1908). 407 б.

*Тукай Г.* Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 2 т.: шигъри әсәрләр (1909–1913). 384 б.

Тукай турында замандашлары: Истәлекләр, мәкаләләр һәм әдәби әсәрләр җыентыгы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. 256 б.

*Ханнанова Г.М.* Г. Тукайның башлангыч чор лирикасында матбугат темасы: төп мотивлар һәм жанр төрләре // Фәнни Татарстан. 2018. № 3. Б. 46–53.

*Публикация статьи осуществлена в рамках научного проекта № 18-412-160012 РФФИ и Правительства Республики Татарстан*

*Мәкалә Россия фундаменталь тикшеренүләр фондының һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтенең финанс ярдәме белән 18-412-160012 номерлы фәнни проект кысаларында әзерләнде*

***Надыршина Ләйсән Рәдиф кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.162.1+821.512.145

*Л.Ш. Галиева*

# ГЖЕГОЖ ЧЕРВИНСКИЙ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ ПОЛЯК ҺӘМ КАЗАН ТАТАРЛАРЫ ӘДӘБИЯТЫ

В данной статье рассматриваются труды ученого из Польши Гжегожа Червинского по исследованию польско-татарской литературы, а также польско-татарской литературы в сравнительном аспекте с литературой казанских татар. Особый акцент сделан на монографии Г. Червинского «*Jam z rodu Nomadów». Literatura polsko-tatarska po 1918 roku («Я из рода номадов». Польско-татарская литература после 1918 года)*, которая была опубликована в 2017 году в городе Белосток (Польша) на польском языке.

**Ключевые слова:** Гжегож Червинский, польские татары, польско-татарская литература, литература казанских татар, степь.

This article discusses the works of a scientist from Poland Grzegorz Czerwinski on the study of Polish-Tatar literature, as well as Polish-Tatar literature in a comparative aspect with the literature of the Kazan Tatars. Special emphasis is placed on the monograph of G. Chervinsky "Jam z rodu Nomadów". Literatura polsko-tatarska po 1918 roku ("I am of the nomad family". Polish-Tatar literature after 1918), which was published in 2017 in Bialystok (Poland).

**Keywords:** Grzegorz Czerwinski, Polish Tatars, Polish-Tatar literature, literature of the Kazan Tatars, steppe.

Гжегож Червинский (1978 елда туган) – Белосток университеты филология факультетында гуманитар фәннәрнең әдәбият белеме өлкәсендә хабилитацияләнгән докторы, адъюнкт, славян әдәбиятлары тарихы (барыннан да бигрәк нон-фикшн әдәбият) өлкәсендә тикшеренүләр алып бара, шулай ук поляк, белорус һәм Литва татарлары әдәбияты белән кызыксына. Польша, Бельгия, Голландия, Германия һ.б. илләрнең фәнни журналларында үз мәкаләләрен бастырып килә («Russian Literature», «Zeitschrift für Slavische Philologie», «Pamiętnik Literacki», «Ruch Literacki», «Slavia Orientalis» һ.б.). Соңгы елларда Россия, Татарстан басмаларында да аның фәнни мәкаләләре дөнья күрде [Czerwiński, 2014; 2015; Червинский, 2010; 2014; 2015, Ориенталистская…; 2015, Бүгенге...]. Игътибар итсәк, аларның күбесендә галим Польша татарлары иҗатын тикшерә, шул нисбәттән XX гасыр поляк-татар әдәбиятында чагылыш тапкан көнчыгыш традицияләр, мотивларны барларга тырыша, әлеге әдәбиятның үзенчәлекле якларын, тарихын, хәзерге проблемаларын ачарга омтылыш ясый. Поляк галименең хезмәтләре, әлбәттә, төрлечә бәяләнергә хаклы. Шулай да татар галимнәре һәм, гомумән, җәмәгатьчелеге өчен аерым карашлар һәм фикерләр кызыклы булыр, чөнки Г. Червинскийның Польша һәм Казан татарлары әдәбиятын чагыштырма планда өйрәнүгә багышланган хезмәтләре

дә бар. Һәм алар бу өлкәгә кагылышлы беренче тикшеренүләр булып тора.

Польша татарларын Казан татарлары әдәбияты белән таныштыруны поляк галиме Г. Тукай иҗатыннан башлый [Czerwiński, 2011]. Әлбәттә, Г. Червинский бер мәкалә кысаларында татар шагыйренең иҗатын тулаем күзәтүгә дәгъва итми, шулай ук яңалык ачарга да тырышмый. Аның төп максаты – Польшада яшәүче татарларны Идел буеның бөек татар шагыйре белән таныштыру, аның биографиясенә кыскача тукталу. Ул бары тик Г. Тукай иҗатында чагылыш тапкан аерым мәсьәләләрне калкытып куя. «Кызганычка каршы, – дип яза галим, – Польшада Тукай шигърияте белән танышу шактый авыр мәсьәлә, чөнки татар әдәбияты буенча поляк телендә басылган публикацияләр юк дәрәҗәсендә» [Czerwiński, 2011, s. 31].

2013–2016 елларда «1918 елдан соңгы поляк-татар әдәбияты» грант проектын тормышка ашыру максатыннан Г. Червинский поляк-татар дөньясына кагылышлы шактый эзләнүләр алып бара, конференцияләр оештыруда катнаша (2014 ел – «Поляк, литва, белорус татарлары әдәбиятларының эстетик аспектлары»), монографияләр әзерләп бастыра, редакцияли («Станислав Кричинский» (2014), «Поляк, литва, белорус татарлары әдәбиятларының эстетик аспектлары» (2015), «Поляк әдәбиятында мөселман Көнчыгышы. Идея һәм образлар» (2016) һ.б.). Галимнең әлеге өлкәдәге эзләнүләре хакында матбугат битләрендә уңай бәяләмәләр да басылып чыга [Loska]. Шул елларда ул Татарстанда да булып китә. Бары тик 2017 елда гына Г. Червинскийның Польша һәм Казан татарлары әдәбиятын чагыштырып өйрәнүгә багышланган беренче хезмәтләре дөнья күрә. «Татарның күзаллау (хыял) картасы. Польша һәм Казан татарлары шигъриятендә географик киңлек (пространство) тудыру тәҗрибәсе турында» мәкаләсендә галим поляк-татар авторларыннан Селим Хасбиевич, Муса Чахоровски, Михаил Адамович, Казан татарларыннан Г. Тукай, М. Әгъләмов, Р. Харис, Р. Вәлиев һ.б. иҗатларына мөрәҗәгать итә, охшаш якларны барлый [Czerwiński, 2017, Mapa…]. Галимнең поляк һәм Казан татарлары әдәбиятына кагылышлы эзләнүләренең төп нәтиҗәләре исә аның 2017 елда басылып чыккан шактый күләмле монографиясендә урын алган [Czerwiński, 2017, Jam…].

«Мин күчмәннәр ыруыннан» дип исемләнгән әлеге хезмәт 1918 елдан соңгы поляк-татар әдәбиятын өйрәнүгә багышлана. Биредә шул хезмәтнең резюмесын һәм Казан татарлары әдәбияты тарихына кагылышлы өлешнең эчтәлеген кыскача татар теленә тәрҗемә итеп бирәбез.

*Тәкъдим ителә торган китап поляк-татар язучылары тарафыннан 1918 елдан соң язылган әдәби әсәрләргә багышлана. Әлеге әдәбият бары тик поляк – бүгенге көндә Польша татарларының бердәнбер туган телендә иҗат ителгән. Польша татарлары Бөек Литва кенәзлеге мөселманнарының варислары булып санала. XIV–XVI гасырларда Бөек Литва кенәзлеге биләмәләренә килеп урнашкан татарлар*

*татар һәм ислам мәдәниятеннән читләшеп яшиләр. XVI гасырда аларның үз туган телләре – төрки телләр төркеменә караган кыпчак теле Бөек Литва кенәзлегендәге рәсми телләр – белорус һәм поляк телләре тарафыннан кысрыклап чыгарыла. Польша-Литва татарларының барысы да мөселманнарның гарәп телен бертигез дәрәҗәдә белми.*

*Күченеп килгән татарлар үз тарих һәм мәдәниятләрен башта Бөек Литва кенәзлеге, XX гасырда исә Польша Республикасы белән бәйләп карыйлар. Хәзерге вакытта поляк татарларының милли үзенчәлекләре Польшада яшәүче башка төп азчылык халыклардан (белорус, украин, рус, алман яки лемклардан) аерылып тора. Польша татарларының бердәйлеге бер-берсенә тиң өч компоненттан тора: алар бер үк вакытта үзләрен поляк, татар һәм мөселман дип исәплиләр. Һәм әлеге өч сүзне алар синоним буларак кабул итә. Аталып үткән төркем әгъзаларының бердәйлеген аңлау өчен, аларны полякныкына каршы куеп түгел, ә Аурупа һәм Азия элементларының үзенә бертөрле синтезы итеп карау дөрес булыр.*

*Китап кереш, алты бүлек, бетем һәм библиография өлешләреннән тора. Керештә тикшеренү эшенең максаты һәм материаллары күрсәтелә, Польша татарлары әдәбиятын өйрәнгән галимнәрнең хезмәтләренә күзәтү ясала һәм эш барышында кулланылган методология атала.*

*Хезмәтнең беренче бүлегендә автор Бөек Литва кенәзлеге җирләренә күченеп килгән татарларның тарихын, ике сугыш арасындагы вакытта (1919–1939), сугыштан соң һәм безнең көннәрдә Польшадагы татарларның мәдәни һәм дини тормышын сурәтли. Моннан тыш китап авторы укучыны аны кызыксындырган этник төркемгә карата кулланылган терминология, шулай ук «поляк татарлары», «литва татарлары», «Бөек Литва кенәзлеге татарлары» этнонимнары белән таныштыра.*

*Беренче бүлектә Г. Червинский шулай ук үзенең тикшеренү алымын нигезләргә һәм ни өчен Польша татарлары иҗатын поляк әдәбияты контекстында өйрәнүне зарур санавын аңлатырга тырыша. Ул шулай ук хәзерге Польшада яшәүче поляк мөселманнары һәм башка милли һәм мәдәни азчылыкны тәшкил иткән халыкларның әдәбиятлары арасындагы мөһим аерымлыкларга игътибар итә.*

*Китапның калган өлешләре Польша татарлары иҗатындагы конкрет әдәби жанрларга багышлана.*

*Икенче бүлек лирикага юнәлтелгән. Аның аерым бүлекчә темалары Станислав Кричинский, Селим Хазбиевич, Муса Чахоровский, Анна Кайтохова, шулай ук яшь дебютант һәм профессионал булмаган авторларның шигъри әсәрләрен өйрәнүгә багышлана. Мондый композиция танылган поляк-татар шагыйрьләре иҗатын күзалларга гына түгел, ә бәлки барлык татарларга хас кайбер символик фикерләү үзенчәлекләрен күрсәтергә, татар язучылары әсәрләрендә урын алган мөселман мәдәнияте архетипларын, һәм шулай ук төрки*

*халыкларда ислам динен кабул иткәнче таралган ышануларны аңларга мөмкинлек бирә.*

*Өченче бүлектә өйрәнү объекты итеп репортаж алына. Поляк-татар әдәбиятының әлеге жанры ике сугыш арасындагы вакыт аралыгында аеруча активлаша. Бу күренеш татарларның мөселман илләренә еш баруы белән аңлатыла. Бүлекнең аерым бер өлеше мөфти Якуб Шинкевич сәяхәтнамәләренә багышлана. Авторның репортаж жанрына якын торган берничә тексты билгеле, бу исә аларны төрле интерпретация контекстларында анализларга гына түгел, ә бәлки үзгәлек проблемасын антропологик һәм социаль контекстларда күзалларга мөмкинлек тудыра. Өченче бүлектә каралган язучыларның иҗатларында (алар арасында Леон Кричинский, Эдиге Шинкевич, Али Воронович, Мустафа Александрович) да бер яки берничә кыска репортаж бар. Аларның иҗаты бер бүлекчә эчендә тикшерелә. Бу бүлек поляк-татар репортажының «кайнар темаларын» һәм татарларның хәзерге вакытта әдәбиятның әлеге төре белән шөгыльләнергә омтылышын өйрәнү белән тәмамлана.*

*Дүртенче бүлек («Татар эссесы. Эстетика – историософия – публицистика») өч бүлекчәдән тора. Шуларның беренчесендә татар авторлары арасында эссеист буларак танылган Станислав Кричинскийның иҗаты тикшерелә. Әлеге автор әсәрләренең күптөрле проблематикасы аның иҗатын бер үк вакытта төрле яклап, шул исәптән романтик фәлсәфә, «поляк эссесы», Икенче Бөтендөнья сугышы чоры истәлекләре һ.б. контекстларда шәрехләргә мөмкинчелек бирә. Икенче бүлекчәдә бертуган абыйлы-энеле Леон (Арслан) һәм Ольгерд Кричинскийларның этник һәм тарихи темаларны яктырткан эсселары анализлана. Эссе жанрын үзәккә алган бүлек «Татар тормышы» дип исемләнгән татар журналы битләрендә басылган публицистик текстларны тикшерү белән тәмамлана. Шул рәвешле, китап авторы фикеренчә, публицистик текстлар үз тарихы булган, Польша һәм бөтен дөнья тарихында үзенчәлекле роль уйнаган татарларның төркем буларак оригиналь фикерләү сәләтенә ия булу күрсәтеп тора.*

*«Үткән заман һәйкәлләре һәм гаилә легендасы арасында. Польша татарларының истәлекләре» дип исемләнгән бүлек фикциональ булмаган татар әдәбияты турында уйлануларны дәвам иттерә. Биредә истәлекләр киң мәгънәдә кулланыла. Сугышлар арасындагы егерме еллыкта әдәбиятның фикциональ булмаган жанрлары репортаж һәм эссе аеруча популяр булган кебек, XX гасыр ахыры – XXI гасырның беренче унъеллыгында татар авторлары, аерым алганда өлкән буын вәкилләре арасында мемуарлар еш басыла.*

*Китапның соңгы өлеше поляк-татар әдәбиятын компаративистик контекстта өйрәнүгә юнәлтелгән. Бүлектә Польша мөселманнары әдәбиятын анализлау, бер яктан, татар телендә иҗат ителгән Казан татарлары әсәрләренә, икенче яктан рус һәм белорус телләрендә язган Литва һәм Белоруссиядә яшәүче татар авторла-*

*рының әсәрләренә барып тоташа. Беренче очракта китап авторы Польша һәм Казан татарлары поэзиясендәге архетип һәм символларны анализлый. Бу аңа ике төркем татар вәкилләренең иҗади күзаллавын билгеләргә, алар арасындагы күп кенә уртак һәм аермалы якларны табарга мөмкин булуын күрсәтә. Компаративистик эзләнүләрнең башлангыч ноктасы булып киңлек (пространство) категориясен анализлау тора. Шул ук вакытта Польша татарлары кебек үк Бөек Литва кенәзлеге мөселманнары этник төркеменең варислары булган Литва һәм Белоруссия татарларының иҗаты исә үзгәлек проблемасын аңлау төрлелеге һәм хәзерге поляк-татар әдәбиятында чагылыш тапмаган рус һәм белорус әдәбияты традицияләренең таралыш дәрәҗәсе белән шаккатыра.*

«Поляк-татар әдәбияты» дигән термин поляк филологы һәм политологы, татар чыгышлы шагыйрь Селим Хасбиевич тарафыннан тәкъдим ителә. Бу аңлатма Польша һәм татар-мөселман мәдәнияте кисешендә үсеш алган әдәбият өчен ышандырырлык яңгырый. Г. Червинский фикеренчә, термин бигрәк тә әдәбиятның креатив (иҗади) ягын ассызыклар өчен актуаль, чөнки аны, бер яктан, төрки-мөселман, икенче яктан поляк әдәбиятының татар этник агымы буларак карарга мөмкин. Хезмәтенең төп максаты исә поляк татарлары әдәбиятының поляк (Европа) һәм мөселман көнчыгышы мәдәнияте белән берлеге тәшкил итә дигән гипотезаны тикшерү. Шунысын да билгеләү әһәмиятле: төрки-мөселман традициясе азмы-күпме архетипик катламда мөселман булмаган татар авторларында (Станислав Кричинский), яки христиан традицияләрен тирән үз иткән Анна Кайтохова иҗатында чагылыш таба. Беренчесе төньяк-көнчыгыш чикләрне хыялда торгызган дала киңлеге, икенчесе өчен борынгы баба турында хәтердә сакланган татар «минен» әдәби эзләү юлында илһам чыганагы булып тора. Хезмәттә тарихи вакытны нәкъ менә 1918 елдан башлау юкка гына алынмый. Нәкъ менә шушы елдан алып Польша татарлары әдәбиятының яңа үсеш дәвере башлана. Татар әдәбиятын периодизацияләү дигәндә ике чор аерып чыгарыла: XIX гасыр ахырына кадәр борынгы әдәбиятны үз эченә алган иске поляк чоры һәм XX йөз башыннан алып хәзерге әдәбият. Поляк телендәге татар сәнгате Яңарыш дәверендә үсеш ала башлый.

Тикшеренүдән күренгәнчә, поляк мөселманнарын Идел-Урал төбәгендә яшәүче кардәшләре белән охшаш поэтик типлар, символлар гына түгел (дала символикасы, ат, татарлар бердәмлеге һ.б.), ә шулай ук пространствоны (киңлекне) охшаш күзаллау картасы да берләштерә. Әмма ул охшаш булу белән беррәттән аерыла да, чөнки Идел буе татарлары өчен булган «үзәк» Польша татарлары өчен «чик», һәм Казан татарларына «перифирия» булган җирләр поляк татарлары өчен «үзәккә» әйләнә. Үзәкләре төрле булса да, ике карта да шул ук кала. Икенче караш мәдәни-географик планда күзәтелә. Казан – Идел буе татарларының шигъри үзәге – Казанка елгасы тамагында урнашкан тарихи татар шәһәре. Аның тирәли Татарстан

урнашкан (Татарстан Республикасы, татарлар яшәгән төбәкләрдәге авыллар, ягъни тормышка ашмаган Идел-Урал проектын тәшкил иткән урыннар). Читтәрәк Мәскәү, даладагы Казакъстан, мөселманнар үзәге Мәккә һәм Мәдинә урнашканнар. Казан татарлары әдәбиятында ханлыкларны берләштереп (Казан, Әстерхан, Кырым) карау таралса да, Бөек даланың мәдәни мирасын төрле яктан колачлау күзәтелми. Ягъни татарлар тува, алтай, якут, кыргыз халыкларының үзлекләрен яисә шаманизм традицияләрен кабул итмиләр. Галим бу күренешне Казан татарларының сөнниләр булуы белән аңлатып карый. Поляк-татар шагыйрьләре исә телне югалтып, шактый гына христиан йогынтысына дучар ителү белән беррәттән суфичылык һәм шаманизм мотивларын да үз итәләр. Идел-Урал төбәге татарлары иҗатында Польша, Польша-Литва татарлары хакында, алар яшәгән төбәкләргә бәйле әсәрләр күзәтелми. Шулай да, мисал өчен Грюнвальдка бәйле, аерым моментларны төгәлләштермәгән әсәрләр бар. Польша татарлары өчен исә Крушиняны, Бохоники кебек авыллар, Белосток, Вильно кебек шәһәрләр кадерле. Поляк-татар авторларында Казан Бохара, Стамбул, Кашгар һ.б. шәһәрләр кебек архетипик урын рәвешендә калкып чыга. Дала Идел буе татарлары иҗатында азатлык һәм бәйсезлек символы, Польша татарларында дала – тарихи хәтерне, ерак тарихи Ватанны хыялда тудырган киңлек. Ике әдәбиятны да трагик мотивлар, язмыш тарафыннан дөнья буйлап сибелеп яшәү мәсьәләсе берләштерә.

Г. Червинский үз хезмәтендә Г. Тукай, Ш. Бабич, Х. Туфан, Ш. Галиев, М. Әгъләмов, Р. Вәлиев, Р. Харис, Р. Аймәт һ.б. татар шагыйрьләренең иҗатларына мөрәҗәгать итә, аларның әсәрләрендә урын алган Алтын Урда, Казан ханлыгы, Кол Гали, Кабан күле һ.б. кебек тарихи образларны өйрәнә, шулар аркылы Казан татарлары хыялында, аңында тудырылган киңлек картасын торгыза. Әлбәттә, поляк галименә Татарстанның татар әдәбиятын тикшерү җиңел эш түгел. Бу тулаем мөмкин дә түгел: моның өчен поляк һәм татар телләрен бер дәрәҗәдә камил белү сорала. Шулай да Г. Червинскийның әлеге темага алынуы сокландыра, чөнки галим эчтәлеге белән үзенә ят булган поляк-татар, һәм бер үк вакытта һәм эчтәлеге, һәм теле ягыннан үзенә бөтенләй таныш булмаган Казан татарлары әдәбиятына кагылырга җөрьәт итә. Һәм өйрәнү ноктасы итеп нәкъ менә географик һәм хыялда тудырылган киңлек төшенчәсен алу бу очракта уңышлы килеп чыга. Китапны Николай Коперник исем. университет галиме, профессор Чеслав Лапич, Силезия университеты галимәсе, профессор Анна Шаверна-Диршка да уңай бәялиләр. Соңгы елларда күренекле татар галимәсе Д. Заһидуллинаның мәкаләләрендә дә Польша һәм Казан татарлары әдәбиятларын өйрәнү өлкәсендә тикшеренүләр алып бару кирәклеге, кызыклыгы ассызыкланды [Заһидуллина, 2017, 2018]. Г. Червинскийның хезмәтләре бу юнәлештә нигез итеп алынырга хаклы. Алар шулай ук татар әдәбиятына чит бер халык вәкиле күзлеге аша карау мөмкинчелеге дә бирә.

Әдәбият

*Czerwiński Grzegorz.* Wieszcz narodu tatarskiego // Przegląd tatarski. 2011. № 1. S. 29–31.

*Czerwiński Grzegorz.* The Research Project «The Polish-Tatar Literature since 1918» at the University of Białystok in Poland (2013–2016) // Проблемы филологии, культурологии и искусствоведения в свете современных исследований. Сборник материалов. IV Международная научно-практическая конференция. 14 апреля 2014 г. Махачкала. 2014.

*Czerwiński Grzegorz.* The Prominent Orientalist and Religeous Figure Jakub Shinkevich / Известный ориенталист и религиозный деятель Якуб Шинкевич // Tatarica. 2015. № 4. С. 210–213.

*Czerwiński Grzegorz.* Mapa wyobraźni tatarskiej. O doświadczeniu przestrzeni geograficznej w poezji Tatarów polskich i Tatarów kazańskich // Geograficzne przestrzenie utekstowione. red. B. Karwowska, E. Konończuk, E. Sidoruk, E. Wampuszyc. Białystok. 2017. S. 117–138.

*Czerwiński Grzegorz.* «Jam z rodu Nomadów». Literatura polsko-tatarska po 1918 roku, Białystok: Alter Studio; Wydział Filologiczny Uniwersytetu w Białymstoku, 2017. 524 s.

*Loska Anna.* Literatura tatarska oczami białostockich naukowcow // Przegląd tatarski. 2014. № 2. S. 11–12.

*Заһидуллина Д.* Кем ул – Нобель бүләге лауреаты Һенрик Сенкевич? // Казан утлары. 2017. № 12. 144–149;

*Заһидуллина Д.* «Бүркем икәү...» // Казан утлары. 2018. № 3. Б. 174–178.

*Червинский Г.* Культура польско-литовских татар как пример наследства европейского ислама (введение в проблематику) // Язык. Культура. Общество. 2010. Выпуск 2.

*Червинский Г.* Польско-татарские писатели в годы первой мировой войны // Татарский народ и народы Поволжья в годы Первой мировой войны: сборник материалов Всероссийской научной конференции с международным участием, приуроченной 100-летию начала войны (г. Казань, 10–11 октября 2014 г.), под общ. ред. Л.Р. Габдрафиковой. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани, Академия Наук Республики Татарстан. 2014. С. 77–88.

*Червинский Г.* Ориенталистская традиция в современной поэзии польских татар // Tatarica. 2015. № 5. С. 103–118.

*Червинский Г.* Бүгенге Польша татарлары әдәбияты проблемалары хакында // Фәнни Татарстан. 2015. № 1. Б. 54–68.

*Мәкалә басмага Татарстан Республикасы*
*яшьләр гранты кысаларында әзерләнде.*
*Проект номеры: 17-100-ч Г 2019*

***Галиева Ләйсән Шәукәт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 7.072.3

***И.А. Еникеев***

# ТАТАРСТАННЫҢ РУС ТЕЛЛЕ ЯЗУЧЫЛАРЫ ҺӘМ ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘР

Русскоязычные писатели Татарстана формировались в литературных объединениях республики. В них создавалось литературное поколение своего времени и культурная среда с определенными традициями. В статье представлены краткая история этих объединений в 1970–2000-е годы. Обозначены некоторые особенности творчества русскоязычных татарских писателей.

**Ключевые слова:** русскоязычная литература; литературные объединения; культурная среда; Р. Кожевникова; Н. Ахунова; Р. Бухараев.

Russian-language writers of Tatarstan formed in the literary associations of the Republic. They created a literary generation of their time and a cultural environment with certain traditions. The article presents a brief history of these associations of the 1970s – 2000s. Some features of creativity of the Russian-language Tatar writers are designated.

**Keywords:** Russian-language literature; literary associations; cultural environment; R. Kozhevnikova; N. Akhunova; R. Bukharaev.

1980–2000 елларда рус телле язучыларны әдәби берләшмәләр тирәсендә туплау традициясе дәвам иттерелә. Алар чын мәгънәсендә республикабыздагы яшь талантлар мәктәбенә әверелә. Биредә алар язучылык осталыгы нигезләренә төшенәләр, тәүге күнекмәләрен алалар. Татарстанда сигез әдәби берләшмә эшли: Казанда – дүрт, Чаллыда, Түбән Камада, Әлмәттә һәм Яшел Үзәндә – берәр. Әдәби берләшмәләрнең иҗади мохитендә авторлар шактый тиз «өлгерәләр». Күптән билгеле: мөстәкыйль иҗатка иң кыска юл – әдәби ширкәт аша. Түбән Кама, Әлмәт, Яшел Үзән әдәби берләшмәләрендә әллә ни үсеш-үзгәреш күзәтелми диярлек, буыннар алмашынып тора, алар һаман үз йөзен эзләү белән шөгыльләнә. Казанда һәм Чаллыда исә бөтенләй башка картина күзәтелә. Әдәби берләшмәләрнең әһәмияте – осталык серләренә төшендерүдә генә түгел, ә язучыларның яшь буынын берләштерүдә дә. Алар үз заманының әдәби иҗат белән шөгыльләнүчеләр буынын формалаштыралар, билгеле бер әдәби традицияләргә ия мәдәни мохит тудыралар.

Казанның иң борынгы әдәби берләшмәсе А.М. Горький музее каршында төзелә һәм чирек гасыр дәвамында (2003 елга кадәр) үзенең алыштыргысыз җитәкчесе Марк Зарецкий хөрмәтенә «ЛИТО у Марка» дип атап йөртелә. Үтә нык таләпчән һәм көчле артистлык сәләтенә ия җитәкчене укучылары «Марк Зверецкий» дип тә иатап йөртәләр. Нәкъ менә шушы кеше әлеге берләшмәдә Казан язучыларының тулы бер буынын тәрбияли. Музей каршындагы әдәби мохит язучыларны гына түгел, ә фән һәм иҗат белән шөгыльләнүчеләрне,

эшчеләр интеллигенциясен дә үзенә тарта. Язучыларның сайланма әсәрләрен Татарстан китап нәшрияты белән берлектә әзерләү һәм бастыру эше киң җәелдерелә. М. Зарецкийның вафатыннан соң, берләшмәгә В. Мостафин, С. Малышев, А. Кәримова, Б. Вайнер җитәкчелек итә. Студиягә йөрүчеләр арасында танылган язучылар бик күп: Р. Бохараев, С. Малышев, С. Говорухин, Р. Сабиров, С. Юзеев, Ф. Рәсүлева, А. Кәримова, Т. Алдошин, А. Әпсәләмова, А. Монрес (Хәиров), А. Хәсәнов, С. Хәйруллина, Э. Блинова, Н. Ахунова, Л. Газизова, Н. Борнаш, Д. Гыйниятуллин, Р. Гыймранов, З. Арсланов, Г. Зорина. Соңгы унъеллыкта берләшмәнең Айрат Бикбулатов, Аяз Хәсәнов, Талия Шәрәфиева, Наил Ишмөхәммәтов кебек әгъзалары ТР Язучылар берлегенә кабул ителде. Элегрәк әдәби десант тәҗрибәсе кулланышта булса, ягъни язучылар республика районнарына чыгып, клубларда, китапханәләрдә чыгыш ясасалар, хәзер бу – әдәби фестиваль, клуб һәм урам перфоманслары рәвешен ала. Әдәби берләшмә яшь язучыларның җыентыкларын һәм антологияләрен дөньяга чыгарырга булыша. 90 нчы елларда ел саен М. Горький исем. премия тапшырыла башлаган иде һәм ул 2009 елга кадәр дәвам итте. Төрле елларда Р. Кутуй, Р. Кожевникова, Т. Алдошин, Н. Ахунова, В. Мостафин, А. Кәримова, И. Бикбулатова әлеге бүләк ияләре булды. «Үткән унъеллыкта музей диварларында безнең төбәкнең әдәбият осталары тарафыннан барлыкка китерелгән традицияләрен аларның күпсанлы укучылары күтәреп алды, һәм алар үз әдәби клубларын, берләшмәләрен төзеделәр. Мондый фонда беренче әдәби берләшмә арткы планда кала һәм аннан берөзлексез яңалык кертеп тору таләп ителә» [Ахунова, 2017]. Бүген бу әдәби берләшмәдә яшь авторлар юк диярлек, башка берләшмәләр һәм социаль челтәрләр арасындагы конкуренция үзен нык сиздерә.

1972 елда Казан университетында тагын бер Парнас эшли башлый. Ул КДУ каршында әдәби клуб яки «ARS poetica» студиясе буларак яши. Анда университет студентлары гына түгел, ә шәһәрнең башка югары уку йортларында укучы яшьләр дә бик теләп йөри. Студия җитәкчесе шагыйрь Николай Беляев сүзләренә караганда, биредә шигъри телне яңарту мәсьәләләре куела һәм «күп кенә, хәтта эксперимент рәвешендә язылган шигырьләрдә дә давыллы һәм каршылыклы замана (анда яшәү бәхетен без дә татыдык) чагылыш таба... ул шагыйрь һәм прозаик Р. Сабиров, мединститут студенткасы Л. Газизова иҗаты белән таныштыра. Л. Газизова үзенең Нур (Луч) дигән романтик тәхәллүсеннән баш тартырга булды, бу – аның өлгергәнлек билгесе» [Беляев, 1989]. Бүгенге көндә ARS берләшмәсенә Алексей Кириллов җитәкчелек итә. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, Казанда яңа каләм тибрәтә башлаган яшьләр төрле әдәби берләшмәләргә йөреп, берничә язучыдан өйрәнү мөмкинлегенә ия була.

Алар арасында 1978 елда «Комсомолец Татарии» газетасы каршында оешкан «Әдәби остаханә» дә («Литературная мастерская») бар. Аның өстенлеге шунда: авторлар иҗаты газета битләре аша

укучыларга бик тиз барып ирешә. Э. Блинова, М. Вәлиева, В. Ногманов, Р. Усманов, Р. Сабиров, Х. Гыйльметдинов язмалары беренче мәртәбә нәкъ менә «Комсомолец Татарии» газетасында басыла. Ә. Мушинский СССР Язучылар берлеге әгъзасы була. М. Вәлиева хайваннар турында хикәяләр җыентыгы чыгара. 16 авторның «Начало» дип исемләнгән коллектив җыентыгы әзерләнә (1981). «Әдәби остаханә»дә дәресләр гадәти формада үткәрелми. Бирегә республикада яшәүче язучылар, режиссерлар, кызыклы һөнәр ияләре генә түгел, ә партия, совет һәм хуҗалык җитәкчеләре дә килә. Бу остаханәне язучы Диас Вәлиев оештыра һәм җитәкли дә. «Әдәби остаханә»гә йөрүчеләр рәссамнарның күргәзмәләрендә һәм мастерскойларында еш булалар, үзләренең язганнарын да даими рәвештә тикшереп, фикер алышып торалар. Мондый очрашулар яшь язучыларның дөньяга карашларын киңәйтә. Иҗат яшьләренең республика семинарлары да нәтиҗәле эшли. Әдәби остаханә яшь язучыларның яхшы якларын гына түгел, җитешсезлекләрен дә ачыкларга мөмкинлек бирә. Алар арасында чынбарлык темаларыннан читләшү, фикерләүдә инфантильлек, балачак истәлекләрендә һәм уңышсызлыка очраган яшьлек мәхәббәте вариацияләрендә казыну да бар. Ә. Мушинский бу турыда болай дип яза: «Үз хатирәләре, кичерешләре эчендә генә кайнамыйча, кыю рәвештә тирә-юньгә дә күз салган яшь авторлар (алар сирәк) шунда ук игътибарны җәлеп итә. Әлбәттә, тема уңышны гарантияләми. Әмма яшьләр тема турында күбрәк бәхәсләшә. Яхшы рус шагыйре булу гына аз, яңача гәүдәләндерү осталыгына ия булу кирәк, башка образлы дөньяга үтеп кереп, әлеге дөньяны башка телдә яңадан тудыру өчен бердәнбер мөмкин булган чараларны табу зарур» [Мушинский, 1982]. Дүртенче әдәби берләшмә – «Белая ворона» – 1997 елда «Казанский медик» студентлар газетасы базасында КДМУның студентлар профкомы ярдәме белән булдырыла. Оештыручысы – шагыйрә һәм драматург, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Наилә Ахунова. «Ун ел дәвамында «Белая ворона» «Галактика любви» дигән поэзия һәм авторлар җырлары фестивальләре, шулай ук шагыйрьләр һәм бардларның «Пересмешник» дип аталган турнирын уздыра» [Каримов, 2007, б. 29]. Медицина белән бәйләнеш берләшмәнең иҗат принцибында да чагылыш таба, һәм ул нәтиҗәле арт-терапия дип билгеләнә. Бирედә норматив булмаган лексика, агрессивлык һәм әшәкелек, кыланып, җиңел генә данга ирешү кабул ителми, креативлык һәм яхшы мөнәсәбәт хуплана. Л. Газизова, Н. Ишмөхәммәтов, А. Әпсәләмова, Т. Алдошин, А. Кәримова, А. Гайсин, Д. Садыйкова шушы берләшмә аша узды. Җитәкчеләре Н. Ахунова берләшмә эчендә япон хокку жанрын сөючеләрне берләштергән Хайдзиннар клубы «17» не төзи. Ул үзе дә бу жанр белән бик нык кызыксына һәм мавыга.

Чаллы шәһәрендәге «Орфей» әдәби берләшмәсе КамАЗ төзелә башлагач оеша һәм тиз арада бөтен илгә танылა. Төзелешне башлаучыларның хезмәт романтикасы СССРның төрле почмакларыннан

җыелган яшьләр иҗаты белән кушыла. Шуңа күрә ул җирле һәм союз күләмендәге вакытлы матбугат органнарының да, телевидение һәм радио редакцияләренең дә игътибар үзәгендә була. Әдәби берләшмәгә нигез салган Валерий Суров аны «Орфей» дип атарга тәкъдим итә, ә ВЛКСМның шәһәр комитеты мифологик җырчының исемен бирүне раслый. Бу әдәби берләшмәне оештыруда ТАССР Язучылар берлегенең рус әдәбияты һәм тәрҗемәләр секциясе җитәкчесе, фронтовик Г. Паушкин, М. Скороходов, Н. Беляев зур ярдәм күрсәтә. Ул 50 дән артык кешене берләштерә. Аларның 13 е Мәскәүдә А.М. Горький исем. әдәбият институтында укый. Алар арасында VII Бөтенсоюз яшь язучылар киңәшмәсендә катнашкан Н. Алешков, П. Юлаев, Е. Кувайцев, Р. Асылбаева бар. Аеруча талантлы язучылар өчлегенә Р. Галимов, В. Суров һәм Е. Кувайцевны кертәләр. Аерым алганда, рус телле татар язучылары үзләренең әдәби карашлары белән башка телдә язучыларга һәм әдәби берләшмәләрдәге остазларына күп яктан бурычлы. А.М. Горький музеенда студиячеләр җыелышларында аның җитәкчесе Марк Зарецкий белән Булат Галиев, Равил Бохараев, Лоренц Блиновлар арасында дискуссияләр башланган вакытта, алар дөнья әдәбиятының бөтен катлауларын яттан өземтәләр китерүгә корылган чын эрудитлар турнирына әверелә. Бу яшь язучылар өчен чын әдәби мәктәп булды. Роза Кожевникова – Казандагы әдәби берләшмәләргә кермәгән аз санлы язучыларның берсе, ул Мәскәүдә укый. «Идел» журналының русча басмасын нигезләп һәм аны 1991 елдан җитәкләп, Казандагы рус телле әдәбият өчен гаять зур эш башкара. Басма рус телле язучыларга үзләрен таныту, укучылары белән очрашу мөмкинлеге тудырган мәйданчыкка әверелә. Р. Кожевникова журналда «Зеленая поляна», «Дебют», «Я» рубрикалары ача, аларда яшь авторлар үзләренең тәүге язмаларын бастыралар.

Һәр әдәби күренеш әдәби тәнкыйть, галимнәр тарафыннан танылгач, ул киң даирә укучыларга барып ирешкәч кенә төбәк мәдәни тормышының кануни факторына әверелә. Әлеге җәһәттән 1960–1970 еллардагы рус телле язучыларның мөмкинлекләре күбрәк булса да, алар әллә ни күп түгел иде, әмма җәмәгатьчелек аларның иҗатыннан хәбәрдар булды; әсәрләре җыентыкларда, газеталар һәм журнал сәхифәләрендә басылды, аерым басмалар дөнья күрде. Ләкин төрле сәбәпләр аркасында 1980 еллар ахыры – 2000 еллар буыны өчен китаплар нәшер итү кыенлашты. Җирле вакытлы матбугат басмалары гына калды («Казан», «Идел», «Аргамак» журналлары, «Республика Татарстан», «Молодежь Татарстана» һәм «Вечерняя Казань» газеталары). Кемгәдер үзәк басма саналган әдәби-нәфис журналлар игътибар итте. Әмма әдәби тәнкыйтьнең җитенкерәмәве тагын да аянычрак булды, нәкъ менә әдәби тәнкыйть рус телле язучыларны киң даирә укучылар белән таныштыра, рус телендә иҗат иткән язучылар үстергән әдәби процессны чорларга бүлеп бәяли алачак иде. Рус телле язучыларның иҗаты кулуар әдәбият рәвешенә керде, ул тар даирәгә генә мәгълүм иде.

Татарстанда 1980–2000 еллардагы рус телле әдәбият өчен төрле мәдәниятләрнең мәгънәләре белән мавыгу, нәтиҗәдә текстта әдәби реминисценцияләр һәм аллюзияләр күбәю хас. Бу реализм һәм мистика кушылмасында, әдәби форма белән кыю тәҗрибәләр ясауда чагыла. Әлеге чор рус телле әдәбияты прозада да, шигърияттә дә кече формаларга тартыла. Драматургияне без фәкать Р. Бохараевның һәм Н. Ахунованың курчак театры өчен, балаларга багышлап язылган әкияти пьесаларында гына очратабыз. Рус телле әдәбиятның кулуарлыгы һәм киң танылмавы, шулай ук чын әдәби тәнкыйтьчеләрнең азлыгы да үзен сиздерә. Әсәрләрен дөньяга чыгару мөмкинлекләре киму сәбәпле, язучылар укучылар белән аралашуның яңа формаларын табарга омтыла. Әлеге проблемаларның барысы да 2000–2020 елларга күчте. Алар төрле юллар белән хәл ителә – яңа басмалар барлыкка килү, кино һәм телевидениенең роле кочәюдән алып, интернет һәм социаль челтәрләрнең көндәшлеге артуга кадәр.

**Әдәбият**

*Ахунова Н.* Воспоминание о литобъединении // http://stihi.ru/2017/08/31/4959 – мөрәҗәгать итү вакыты 21.06.2018.

*Беляев Н.* У нас в гостях – творческая смена. // Вечерняя Казань. 1989. 16 мая.

*Каримов Тимур.* «Белая ворона» попала в «десятку»: юбилей молодежного ЛИТО КГМУ. // «Идель». 2007. № 7. 29 б.

*Мушинский А.* Автор книги – молодой писатель // Комсомолец Татарии. 1982. 12 декабря.

***Еникеев Илдар Әхнәф улы,***
*илология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 94 (575)

*А.С. Эркинов*

## УРТА АЗИЯ-ИДЕЛ БУЕ БАГЛАНЫШЛАРЫ ТАРИХЫННАН БЕР СӘХИФӘ
### (М. Мөхәммәдҗанов истәлекләре буенча, 1908–1910 еллар)

Среднеазиатско-татарские (поволжские) связи в сфере образования имеют свою интересную историю. Многие поволжские татары получали религиозное образование в Бухаре, в Средней Азии. Случалось, также, и обратное. К примеру, туркестанский просветитель начала XX века Муминджан Мухаммаджанов (1883–1964) в юные годы учился в мадраса Ташкента. После, узнав о Мадрасаи Галия, в 1908 г. поехал в Уфу учиться в этой мадраса. В 1908–1909 гг. он частично учится в Мадрасаи Галия. В 1926 г. он опубликовал свои мемуары под названием «Турмуш урунушлари» (Мои жизненные старания). В них на ряду с описанием своей жизни в Средней Азии, он описывает свое пребывание в Мадрасаи Галия. Особо подчеркивает, что учеба в этом заведении и пребывание в татарской среде помогли ему лучше понять мир и свое окружение. Он стал знакомиться с произведениями татарских, азербайджанских и турецких авторов-просвятителей. В конце-концов это привело к тому, что у него появился интерес к созданию описания своей жизни в виде мемуаров. В нашем статье будут представлены воспоминания Муминджана Мухаммаджанова и анализ его восприятия учебы в Мадрасаи Галия.

**Ключевые слова:** Средняя Азия, Туркестан, мадраса, Ташкента, Уфа, Мадрасаи Галия, Муминджан Мухаммаджанов, мемуар.

Central Asian-Tatar (Volga) relations in the field of education have their own interesting history. Many Volga Tatars received religious education in Bukhara, in Central Asia. The opposite also happened. For example, the Turkestan enlightener of the early twentieth century, Muminjan Muhammadjanov (1883–1964), studied in the madrasah of Tashkent in his youth. After learning about Madrasa-i Galiah, in 1908 he went to Ufa to study in this madrasah. In 1908–1909 he partially studies in Madrasa-i Galiah. In 1926, he published his memoirs entitled “Turmush urunushlari” (“My efforts in life”). In them, along with a description of his life in Central Asia, he describes his stay in Madrasa-i Galiah. He emphasizes that studying in this institution and being in the Tatar environment helped him better understand the world and his environment. He began to get acquainted with the works of Tatar, Azerbaijani and Turkish authors, educators. In the end, this led to his interest in creating a description of his life in the form of memoirs. In our article, memories of Muminjan Mukhammadjanov and an analysis of his perception of studying in Madrasa-i Galiah will be presented.

**Keywords:** Central Asia, Turkestan, madrasah, Tashkent, Ufa, Madrasa-i Galiah, Muminjan Muhammadjanov, memoir.

Мәгариф өлкәсендә Урта Азия-татар (Идел буе) багланышларының тарихы бик кызыклы. Идел буе татарларының күбесе дини белемне Бохарада, Урта Азиядә алганнар. Шулай ук бу күренешнең киресе дә күзәтелгән. Урта Азия реформаторларының бер өлеше

Идел буенда укыган яки бу төбәкнең мөселман реформаторлары йогынтысында булган. Төркестан мөселман реформаторлык хәрәкәте үзенең барлыкка килүе белән күп очракта Госманлы һәм Идел буе реформаторларына бурычлы. Без мондый йогынтының булуын беләбез, әмма аның механизмнарын гына һәрвакыт белеп бетермибез. Чыганаклар аз. Җәдитче-реформаторларның мемуарлары бу тема буенча аз санлы чыганакларның берсе булып хезмәт итә ала. 1926 елда Ташкентта бер мемуар басылып чыга, анда XX гасыр башы Төркестан мәгърифәтчесе Мөминҗан Мөхәммәдҗановның (1883–1964) студент вакыты һәм алга таба яңа ысуллы мәктәпләрдә мөгаллимлек итүе бәян ителә.

Ул яшь чагында Ташкент мәдрәсәсендә укыган. «Галия» мәдрәсәсе турында ишеткәннән соң, ул 1908 елда, шушы мәдрәсәдә уку өчен, Уфага китә. 1908–1909 елларда ул бераз «Галия» мәдрәсәсендә дә укый. 1926 елда ул үзбәк телендә үзенең «Тормышым иҗтиһатлары» (Турмуш уринушлари) исемле мемуарларын дөньяга чыгара. Аларда Урта Азиядәге тормышын тасвирлау белән бергә, «Галия» мәдрәсәсендә гыйлем алуын да бәян итә. Әлеге уку йортында белем эстәү һәм татар мохитендә булу аңа дөньяны һәм үз даирәсендәгеләрне яхшырак аңларга ярдәм итүен ассызыклый. Ул татар, азәрбайҗан һәм төрек мәгърифәтче авторларының әсәрләре белән таныша башлый. Нәтиҗәдә, үзенең тормышы турында мемуарлар язу белән мавыгып китә. Безнең мәкаләдә Мөминҗан Мөхәммәдҗановның истәлекләре һәм аның «Галия» мәдрәсәсендәге уку-укытуны ничек кабул итүе анализланалачак.

XX гасыр башы Төркестан мәгърифәтчесе Мөминҗан Мөхәммәдҗанов (1883–1964) шагыйрь, журналист булган. Ул гомере буе Ташкентта яшәгән. Хәзерге Үзбәкстан территориясендәге төрле шәһәрләрдә ул яңа ысуллы мәктәпләр ача (ысулы җәдит) һәм үзе дә аларда укыта. Төркестанның һәм Совет Үзбәкстанының төрле газеталарында журналист булып эшли. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Үзбәкстан ССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтында хезмәт куя (1944–1950).

Мөминҗан Мөхәммәдҗанов Ташкенттә ике мәдрәсәдә укый. «Галия» мәдрәсәсендә укыган үзбәк дусларының йогынтысы астында ул Уфага шушы мәдрәсәдә укырга китә. Мөминҗан мемуарларында «Галия»дә уку өчен үзенең нинди авырлыклар аша узуын тасвирлаган. Башта ул традицион дөньяга карашка ия традицион мөселман эшлеклесе булган. Әмма Төркестан мәгърифәтчеләре дә аңа «Галия»гә барырга киңәш иткәннәр. Нәкъ менә XX гасыр башында Төркестанда җәдитчелек хәрәкәте көчәя. Һәм мондый дәвернең атмосферасы үзе үк үзгәрешләр тудыра.

1906 елда Мөхәммәдҗанов Бохара мәдрәсәсенә укырга барырга җыена. Әмма анда акчасыз укып булмый. Ул бу хакта үзенең танышына – Төркестанның танылган реформаторы Мөнәүвәр карига (1878–1931) хәбәр итә. Соңгысы аңа Идел буе (Нугай иле) мәдрәсәсенә

барырга киңәш итә. Билгеле булганча, Бохара, ислам диненең иң мөһим үзәкләреннән берсе буларак, үзенең мәдрәсәләре белән дан тота. Гадәттә, укырга Идел буеннан Бохарага киләләр. XX гасыр башына Россия империясе чикләрендә барысы да киресенчә була.

Аннан соң авторның Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенә укырга кергән элеккеге курсташы аңа бу уку йорты турында сөйли. 1908 елда Төркестан шәкертләренең кайберләре «Галия»дә укый да башлый инде. Алар, Ташкентка барып, Төркестанның әле ачылган яңа ысуллы мәктәпләрендә укытучы булалар.

Мөхәммәдҗановның мемуарларында аның 1895–1925 еллардагы тормышы чагылдырыла. Шулардан 1908–1909 елларда ул «Галия» мәдрәсәсендә укый.

Мемуарлар авторы Уфага барырга тели. Шул максат белән, үзен мәдрәсәгә укырга алуларын үтенеп, «Галия» мәдрәсәсе җитәкчесенә хат яза. Һәм уңай җавап ала. Ул Уфа тарафына юл ала. Юлда Төркестан шәһәре аша уза һәм, юллык һәм укырга акча эшләү өчен, 3 айга шунда кала. Шуннан соң автор Оренбургка китә, аннан – Уфага.

Ул керү имтиханнарын уңышлы тапшыра, әмма уку өчен түләрлек акчасы булмый. Зур тырышлык куеп,түләүсез нигездә алуларына ирешә. Шуңа да карамастан, ул бик зур авырлыклар күреп укый, азык-төлеккә көч-хәл белән акча юнәтә. Авторга ул вакытта нибары 25 яшь була һәм өеннән, Ташкенттан аңа бернинди дә ярдәм килми. Кайвакыт аңа Урта Азиядән булуы сәбәпле дә булышалар. Уфада аңа Бохара кебек изге шәһәре булган илдән килгән кеше итеп карыйлар. Шуңа күрә ул гел Урта Азия чалмасын һәм халатын киеп йөри, бу әле аңа саллы кыяфәт тә бирә.

Мәдрәсәнең уку программасында төп урынны традицион ислам фәннәре алып тора. География, геометрия һәм математика кебек дөньяви фәннәр дә була. «Галия»дә дин гыйлеме белән беррәттән кайбер дөньяви фәннәрнең дә укытылуы М. Мөхәммәдҗановның күңеленә хуш килә. Автор мәдрәсәдә укытуның заманчалаштырып яңартылган системасын да ошата. Аның сүзләренә караганда, «Галия»дә уку аның тормышында бик күп яңа нәрсәләр ача.

Мәсәлән, Галиядә мәдрәсә шәкертләре җыелышлар үткәрәләр. Әйтер сүзләре, үз фикерләре булганнар, башка шәкертләр алдында чыгыш ясау өчен, мәдрәсә идарәсенә кереп, алдан язылганнар. Мемуарларында автор үзенең әлеге җыелышларда нәрсәләр әйтә алу мөмкинлеге турында яза.

1) «Безгә нинди фәннәр кирәк, мин алар турында үз фикеремне әйтер идем?» – дип, беренче соравын бирә.

2) Ни өчен безнең мөселманнар башкалардан артта калган?

3) Уку һәм алга бару өчен безгә нинди мәктәпләр кирәк?

4)Хатын-кызларыбызның (ягъни мөселман хатын-кызларының) дөньяви һәм башка белемнәрне (фәннәрне) белмәүләре XX гасырга туры киләме?

5) Мәдрәсәне тәмамлагач, безнең шәкертләр, үз идеяләрен тарату өчен, нинди мөгаллимнәр һәм тагын кемнәр белән хезмәттәшлек итәргә тиеш?

«Галия»дә укыган вакытта мемуарлар авторы, Төркестанда уку-укыту һәм мәгариф системасының тиешле дәрәҗәдә булмавына бик борчыла. Ул болай дип яза: «Миңа хәзер 25 яшь, монда Россиядә миннән күпкә яшьрәк шәкертләр Төркестандагы яшьтәшләренә караганда күбрәк беләләр һәм гыйлемнәре дә күбрәк». Ягъни автор «Галия»дә бераз иркенрәк фикер йөртә башлый һәм үз ватанындагы уку-укыту системасына тәнкыйть күзе белән карый. Автор әйтүенчә, «Галия»дә генә ул үзенең тормышы турындагы мемуарларын яза башлый.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, Урта Азиядәге ысулы җәдит мәктәпләре мөгаллимнәренең беренче буыны вәкилләре арасында Идел буе татарлары да була. Мемуарлар авторы үзе «Галия»дә ике елга якын укый, аннан соң, матди проблемалар аркасында, укуын ташлый. Әмма Төркестан генерал-губераторлыгына тиз генә кайтырга ашыкмый, Казакъ даласындагы төрле авылларда укытучылык итә.

«Тормышым иҗтиһатлары» авторы Төркестандагы ватандашларының белем ягыннан артталыгында – беренче чиратта, аларның үзләрен, моннан тыш, Россия империясе хакимиятен гаепли.

Россия дәүләте һәм аның Төркестандагы генерал-губернаторлыгы мөселманнарның (җирле халыкның) яңа (ягъни яңартылган, заманча) белемнәр алуын теләмиләр. Шуңа күрә әлеге юлдан барырга, ягъни балаларын яңа мәктәпләрдә укытырга теләүчеләрне эзәрлекләгәннәр һәм утыртканнар. Хакимиятне русларның гына белем алуы һәм һөнәрле булуы кызыксындырган. Хакимият кул астындагы башка милләтләр колларча буйсынырга һәм аз грамоталы булырга тиеш булган. Алар мөселманнарның чиркәүгә баруын, руслар кебек гыйбадәт кылуын телиләр һәм рус халкының йогынтысын арттырырга омтылалар.

Татарларның казакъ һәм үзбәк балаларын укытуын тыйган боерык (указ?) чыга. Бу империя хакимиятенең татар муллаларыннан куркуын күрсәтә. Алар бит, яңача белем биреп, Урта Азия мөселманнарын да үзгәртә алганнар. Нәтиҗәдә Урта Азия мөселманнары да хакимияткә буйсынудан туктарлар иде. Алга таба автор, Верный шәһәрендә (бу хәзерге Алматы) урыс муллаларының киңәшмәсе узуын раслый (дөресен әйткәндә, авторның «урыс муллалары» дигәндә, кемнәрне күз алдында тотуы безгә аңлашылмый). Россиядәге мөселман авторитетларынмы, әллә рус зыялыларынмы?) Әлеге киңәшмәдә түбәндәгеләр хәл ителә:

1) Татарлар казакъ һәм үзбәк балаларын, таҗикларны укытмасыннар! Без белемле татарларга Төркестанда (ягъни Төркестан генерал-губернаторлыгында) яшәргә мөмкинлек бирергә тиеш түгел. Алар Урта Азия халкы арасында гыйлем таратып, аларның күзләрен ачарга мөмкин. Шулай булганда, безгә Төркестанда бер эш тә калмый.

2) Яңача укыткан мәктәпләрнең мөгаллимнәре инспекторларга үз программаларын һәм дәреслекләрне күрсәтергә тиеш. Аларга кемнәрнең әсәрләре кертелүен белү өчен. Югыйсә, аларга балаларны җыярга һәм укытырга рөхсәт ителми.

Мемуарлар авторы язуынча, моннан соң ул үзе куллана торган китап-дәреслекләрнең һәм мәктәп программаларының исемнәрен, русчага тәрҗемә итеп, шәһәр инспекторына күрсәткән.

Үзбәкстан Республикасы ҮДА документлары күрсәткәнчә, чыннан да, Төркестан генерал-губернаторлыгына яңа методлы мәктәпләрдә эшләргә татар укытучылары килгән.

Иң мөһиме, «Галия» мәдрәсәсе һәм гомумән Идел буендагы тормыш мемуарлар авторына, аның дөньяга карашына бик көчле йогынты ясый. Төркестанга кайткач, ул барысын да чагыштыра һәм үз даирәсенә тәнкыйть күзлегеннән карый башлый. Мисал өчен, ул кылган гамәлләре өчен җирле байларны тәнкыйтьли. Безнең байлар туйларга, күңел ачуларга күп акча тота, дип яза ул. Кайвакыт алар үз акчаларына мәдрәсә яки мәчет тә төзи. Әмма алар Төркестан балалары өчен мәктәп төзүгә бер тиеннәрен дә кертмиләр.

Аның фикеренчә, Татарстанда һәм Азәрбайҗанда байлар акчаларын яңа мәктәп һәм мәдрәсәләр төзүгә тота, һәм анда балаларны яңа метод белән укыталар. Мәсәлән, дип яза ул, Татарстан белән Азәрбайҗанда яшәүче төрки халыкларның күзләре бездән алданрак ачылган. Чөнки аларның байлары яңа мәктәпләр, яңа мәдрәсәләр салалар. Аларда меңләгән бала европача белем аша дөньяны танып белә. Уфа шәһәрендә – «Галия», «Госмания», Казанда – «Мөхәммәдия», Оренбург шәһәрендә –»Хөсәения» һәм Кавказда мөселман мәдрәсәләре бар. Аның фикеренчә, телгә алынган төбәкләрнең хәлле кешеләре яңа мәктәп һәм мәдрәсә төзүгә миллионлаган акчалар сарыф итә. Төркестанның бай кешеләре дә үз халкы өчен мондый игелекле эшне эшли алмаслар иде микәнни? Мемуарлар авторын шушы сорау борчый.

Бөтен китерелгән фактлар күрсәткәнчә, «Тормышым иҗтиһатлары» дип исемләнгән мемуарлар авторы – Төркестан мәгърифәтчесе һәм XX гасыр башы реформаторы Мөминҗан Мөхәммәдҗанов «Галия» мәдрәсәсендә укып һәм Россия мохитендә яшәп, бик күп нәрсәне уңай якка үзгәртә. Әлбәттә, авторның «Галия»дәге тормышын тулысынча сөйләп бирү мөмкин түгел. Шулай да әлеге мемуарларның дүрттән бер өлеше чамасы Мөхәммәдҗановның шушы мәдрәсәдә яки Урал һәм Идел буендагы тормышына багышланган. Киләчәктә мемуарларны рус телендә дә бастырып чыгарырга уйлыйбыз.

**Әдәбият**

*Дўстқораев Б.* Ўзбекистон журналистикаси тарихи (1-қисм. 1870–1917 йил ноябрь). Тошкент: Ғафур Ғулом номидаги нашриёт, 2009.

*Муҳаммаджонов М.* Турмуш урунишлари. Тошкент: Mumtoz so‘z, 2015.

*Муҳаммаджонов М.* Турмуш уринишлари. Тошкент: Бадиий адабиёт нашриёти, 1959.

*Сукталиев Ф.* Уфимское медересе «Галия» // Эхо веков. 1996, № 3–4.

*Abdirashidov Z.* Jadid studies in Uzbekistan after the independence with a bibliography // Asian Research Trends. New Series. 2015. P. 3–29.

*Baldauf I.* Jadidism in Central Asia within Reformism and Modernism in the Muslim World // Die Welt des Islams. 2001. Band 41, 1. P. 72–88.

Bibliography of Islamic Central Asia. Parts I–III / comp. and ed. by *Yu. Bregel*. Bloomington, Indiana, 1995.

Empire, Islam, and Politics in Central Eurasia / T. Uyama (ed). Sapporo: Slavic Research Center, Hokkaido University, 2007.

*Frank A.* Bukhara and the Muslims of Russia: Sufism, Education, and the Paradox of Islamic Prestige. Leiden-Boston, 2012.

*Khalid A.* The Politics of Muslim Cultural Reform: Jadidism in Central Asia. Oxford, 2000.

*Komatsu H.* From Holy War to Autonomy: Dar al-Islam Imagined by Turkestani Muslim Intellectuals // Le Turkestan russe: une colonie comme les autres? [Cahiers dAsie Centrale 17–18] / S. Abashin, S. Gorshenina (eds.); IFEAC-Cdisud. Tachkent; Aix-en-Provence, 2009. P. 449–475.

*Pickett J.* The Persianate Sphere during the Age of Empires: Islamic Scholars and Networks of Exchange in Central Asia, 1747–1917. Ph.D. диссератция, Princeton University, 2015 (рукопись).

*Эркинов Афтандил Садирхан улы,*
*филология фәннәре докторы, Үзбәкстан Республикасы*
*Министрлар кабинеты каршындагы Үзбәкстанның*
*чит илләрдәге мәдәни байлыгын өйрәнү үзәге*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

Ташкент, Узбекистан
Ведущий научный сотрудник,
*Центр исследований культурных ценностей*
*Узбекистана, находящихся за рубежом*
*при кабинете Министров Республики Узбекистан*
aftandilerkinov@gmail.com

УДК 81.373

*Л.Х. Дәүләтшина*

## ТАТАР МИФОЛОГИЯСЕНӘ КАРАГАН ЧЫГАНАКЛАР

В работе рассматривается источниковедческая база по татарской мифологии, включающая рунические памятники, сведения из работ китайских, арабских, византийских, персидских и армянских авторов, исследования и полевые материалы известных тюркологов, фольклористов, диалектологов этнографов, путешественников. Автор обращает внимание на существущий разрыв между колоссальным объемом сведений, хранящихся в архивах или опубликованных в редких и труднодоступных изданиях, и теми материалами, которые традиционно попадают в поле зрения фольклористов. Многочисленные фольклорные тексты по актуальной «живой» мифологии (в основном народной мифо-ритуальной традиции), собранные в ходе экспедиционных исследований последних десятилетий, практически недоступны широкому кругу – студентам, аспирантам, исследователям-филологам, этнографам, музыковедам, интересующимся татарской мифологией. Насущной представляется задача сбора всех важнейших источников в единое место, так как они носят раздробленный, фрагментарный характер и нуждаются в научной систематизации.

**Ключевые слова:** источниковедение, памятники, мифология, ритуал, традиция, текст.

The work considers the source base on Tatar mythology, including runic monuments, information from the works of Chinese, Arabic, Byzantine, Persian and Armenian authors, research and field materials of famous Turkologists, folklorists, dialectologists of ethnographers, travellers. The author draws attention to the existing gap between the enormous amount of information stored in archives or published in rare and difficult publications and those materials that traditionally fall within the field of view of folklorists. Numerous folklore texts on current «living» mythology (mainly folk mytho-ritual tradition) collected during expeditionary research of recent decades are almost inaccessible to a wide range - students, postgraduate students, researchers-philologists, ethnographers, musicologists interested in Tatar mythology. The problem of collecting all major sources to the uniform place as they have the shattered, fragmentary character is represented essential and need scientific systematization.

**Keywords:** source, monuments, mythology, ritual, tradition, text.

Яшәү дәверендә елның һәр мизгеле, көне, ае адәм баласыннан билгеле бер кагыйдәләрнең үтәлүен таләп итә. Әлеге кагыйдәләрнең бер өлеше күп гасырлар элек кешенең үзен әйләндереп алган дөнья, тирәлек турындагы фантастик карашлары нигезендә барлыкка килгән. Кеше әле бу чорда үзен табигать дөньясыннан аерып карамаган һәм әйләнә-тирәсендәге барлык әйберләрне «җанландырган», аларны үзе кебек яши, фикерли һәм хисләнә-кичерә белә дип исәпләгән. Шул ук вакытта «ыруглык җәмгыятендә барлыкка килгән социаль мөнәсәбәтләрне борынгы кеше табигатькә күчергән, шул рәвешле

мифологик карашлар реаль яшәеш белән берләшеп табигать дөньясы һәм кешелек дөньясы арасында гармония барлыкка китергән» [Мелетинский, с. 164-165]. Вакытлар узган саен мифологик ышанулар үзгәреш кичергән, кайсылары төшеп калган, кайсылары яшәештәге яңа кануннарга яраклашкан, әмма нигездә татар халкының мифологик күзаллаулар системасы борынгы төрки мифология белән бәйләнешен югалтмаган.

Татар халкының мифологик мирасын, фәнни әдәбиятта кабул ителгән классификацияләү принципларына нигезләнеп, югары мифологиягә һәм түбән мифологиягә бүлеп карау гамәлдә йөри. Татар мифологиясендә тәңречелек тәгълиматы белән бәйле югары аллалар (Тәңре, Җир-Су, Умай, Алас һ.б.) һәм «культуралы герой»лар хакында телдән һәм язмача рәвештә тапшырыла торган реаль миф текстлары сакланмаган, әмма мифологик карашларның бер өлеше безнең заманга тарихи чыганаклар, борынгы төрки язма истәлекләр, күренекле тюрколог, фольклорчы, тарихчыларның хезмәтләре аша килеп җиткән. Бүгенге көндә татар халкының мифологик системасын реконструкцияләү өчен борынгы мифологик ышануларны чагылдырган чыганак ролен «түбән мифология», ягъни ияләр, кара көчләр, йолалар, ышанулар, кешенең көндәлек яшәеше белән бәйле мифологик мәгълүмат та үти. Түбән мифология персонажлары турындагы текстлар архивлардан тыш татар халкының төрле этник традицияләрендә локаль вариантларда бүген дә саклана, мифологик ышанулар системасыныңбүгенге халәтенә караган мәгълүмат экспедицияләр барышында язып алына.

Төрки-татар мифологиясен өйрәнгән галимнәр аның тарихын һуннардан башлыйлар. Тарих фәнендә һуннар ике исем астында йөри: Азия һуннары (хунн/хунну) һәм Европа һуннары (гунн) [Гумилев, кн. 2, с. 266]. Хуннар дип б.э. II гасырына кадәр, Үзәк Монголия һәм Байкал арты далаларында яшәгән этноска әйтәләр. Ә гуннар дип Бөек халыклар күчеше вакытында Каспий буе Дагстан территориясенә килеп чыгып, шунда бер-ике гасыр яшәп, угыр, сармат кабиләләре белән аралашып, шуның нигезендә физик кыяфәтләрен үзгәртеп, асылда яңа этноска әверелгән, әмма төрки телләрен саклап калган кабиләләрне күздә тоталар [Дәүләтшин, с. 17].

Һуннарның тарихын, мәдәниятен, мифологик карашларын чагылдырган чыганаклар нигездә кытай, грек, әрмән авторларына карый. XIX гасырда Н.Я. Бичурин (Иакинф) тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителгән кытай хроникаларында төрки кабиләләрнең килеп чыгышына бәйле генеалогик легендалар, дәүләт төзелеше, йола-гадәтләренә караган информация теркәлсә, әрмән чыганаклары (Лазарь Парбский, Малала, Феофан Исповедник, Мовсес Каланкатуаци, VII гасыр әрмән географиясе һ.б.) V–VII гасырларда Төньяк Кавказ һәм Каспий буйларын иңләгән «гун иленең» тарихын һәм мәдәниятен ачыклый. «Гун иле»нең мифологик күзаллауларын чагылдырган хезмәтләр арасыннан бай мәгълүмат туплаганы әрмән тарихчысы Мовсес Каланкатуациның «История страны албан» дигән хезмәте. 682 елда

христиан миссиясе белән Каспий буе территориясенә килгән тарихчы язып алган мәгълүматлар борынгы төрки аллалар пантеонын, төркиләрнең дини-мифологик карашлар системасын реконструкцияләргә мөмкинлек бирә [Гмыря, с. 5]. VI гасырда бу якларга килеп чыккан көнбатыш гуннар Тәңри-хан (Тенгри-хан), яшен алласы Гуар/Куар һәм җир рухы хөрмәтенә корбан чалу йоласы үткәрә торган булганнар. Тәңре-ханга корбан чалу йоласы аның үзен гәүдәләндерә торган биек агачлар үскән изге урманнарда (роща) үткәрелгән. Бу хезмәттә Төньяк Кавказ гуннары пантеонында аерым урын алып торган Куар алласыда ачыклана. Тәңре-ханнан кала икенче рангтагы әлеге алла кояш/яшен алласы буларак күзалланган, һәм яшен суккан кеше яки хайванны гуннар Куар алласының корбаны дип исәпләгәннәр [Калан-катуаци, с. 193–194, 200–201].

Төрки каганлыклар чорына караган рун язулы истәлекләр дә борынгы төрки мифологик мирасны барлауда зур урын алып тора. Орхон-Енисей истәлекләре дигәндә, иң беренче чиратта өч тарихи шәхескә – Күлтәгин, Билгә Каган һәм Төньюкукка багышланган күләмле каберташ язмалары күздә тотыла. Тарихи чыганак буларак кыймммәтләре зур әлеге истәлекләрдә борынгы төркиләрнең дини идеологиясенә нигезләнгән тәңречелек тәгълиматының асылы һәм төп пантеоны (Тәңре, Умай, Җир-Су) ачыклана. Борынгы төрки язма истәлекләрдә күзалланган мифологикдөнья моделе Югары, Урта һәм Җир асты өлешләреннән гыйбарәт. Югары дөньяның хуҗасы һәм борынгы төрки пантеонның югары алласы – илаһи Күк буларак кабул ителгән Тәңре кешеләр язмышы белән идарә итә, «күк түркләрнең яшәү рәвешен билгели», каганнарга акыл һәм хакимлек сыйфатларын бүләк итә һ.б. Урта дөнья белән Изге Җир-Су («Ыдук Йер-Суб») хакимлек итсә, Җир асты дөньясы «кешеләрне бер-берсеннән аеручы» һәм аларга «үлем хәбәрчеләрен җибәрүче» Эрлик-ханга буйсына [Кляшторный, 1979, с. 91–95]. Эрклик-ханга бәйле мәгълүматлар,фәндә якынча VIII–X гасырларга караган һәм рун алфавиты белән язылганборынгы уйгур истәлеге – «Ырк битиг» китабында да очрый. «Ядкәрдә «тәңре» атамасы бик еш телгә алына», һәм күп очракта «төркиләрнең баш алласы – Күк тәңре күздә тотыладыр дип уйларга нигез бар» – дип яза Х. Мәхмүтов [Мәхмүтов, 2002, с. 50].

Фәндә, һуннарның мифологик карашларында чагылыш тапкан пантеон VI–VII гасырларда Алтай, Көнбатыш Себер һәм Төньяк Монголия җирләрендә яшәгән Төрки каганлыклар дәверендәге Орхон-Енисей язмаларында ачыкланган дини-мифологик система белән тәңгәл килә дигән караш яши. Кляшторный С.Г. фикеренчә, «гунн-борынгы төрки-праболгар пантеоннарының тәңгәллеген һәм праболгар кабиләләренең (теле кабиләләре союзы) Үзәк Азия территориясеннән V гасырдан да калмыйча китүләрен исәпкә алганда, фәндә «борынгы төрки пантеон» дип исемләнгән катлаулы дини-мифологик системаның б.э. I меңьеллыгы уртасына кадәр формалашып бетүе шик тудырмый» [Кляшторный, 1987, с. 62].

Тәңре культы төрки һәм төрки-монгол халыклары яшәгән киң территориядә таралыш таба, XI гасыр галиме М. Кашгари әле ислам динен кабул итмәгән төркиләрнең «биек тауларны», «олуг агачларны» «Тәңре» дип атауларын яза [Дәүләтшин, с. 76]. Тәңре белән бәйле мифологик карашлар Идел буе болгарларында да дәвам итә. Аның исеме Кол Галинең монгол яуларына кадәр язылган «Кыйссаи Йосыф» поэмасында һәм болгарларның XIV гасырга караган каберташ язмаларында очрый [Урманчеев, 2002, с. 42–43]. IX–X гасырларда ислам дине рәсми рәвештә кабул ителеп, халык арасында да таралгач, Тәңре Аллаһ исеме белән алыштырыла. Ислам белгечләре фикеренчә, «Тәңре төрки телләрдә Аллаһ сүзе белән бер үк мәгънәдә кулланыла» башлый [Ислам, с. 151], вазифаларының уртаклыгы тәңречелек тәгълиматының ислам дине белән органик рәвештә керешеп китүенә китерә.

«... татар халык иҗаты әсәрләрен язып алу, кәгазьгә теркәп калдыру тарихын X гасырның беренче яртысыннан, Ибне Фадлан китабыннан ук башларга кирәк,» – дип яза Ф. Урманче [Урманче, 2005, с. 15]. Ибне Фадланның сәяхәте турындагы язма чыганакларда Идел буенда алыплар турындагы легендаларның киң таралуы, ислам диненең бу якларга үтеп керүе белән бәйле фикерләр чагылыш таба. «X–XII гасырларда иҗат ителгән язма әдәбиятта да шул чор фольклоры буенча материаллар табарга мөмкин. Аларда фольклор әсәрләреннән фрагментлар, сюжетлар сакланган, шул чорга караган афоризмнар теркәлгән» [Закирова, 2003, с. 9]. Мифологиягә караган мәгълүматлар туплаган хезмәтләр арасында Әбү Хәмид әл-Гарнати сәяхәтнамәсе, «Кодекс Куманикус», «Дәфтәре Чыңгызнамә», «Тәварихы Болгария», «Казан тарихы» һ.б. язма ядкярләрнең дә урыны зур.

Бер генә халык та Җир йөзендәге башка халыклардан изоляциядә яшәми. Татар халкы да гасырлар дәвамында рус халкы белән, төрле тарихи сәбәпләргә бәйле рәвештә, бик тыгыз элемтәдә яшәгән. Борынгы заманнардан ук бу ике халык арасында сәүдә, мәдәни һәм фәнни багланышлар булуы билгеле. Татар фольклористикасының фәнни нигезләре барлыкка килү дә рус фольклористикасы фәне белән тыгыз бәйләнгән.Россиядә татар фольклоры әсәрләрен язып ала башлау XVIII гасырга туры килә. 1725 елда Петербургта Фәннәр академиясе оештырылганнан соң, Россиядә яшәүче халыкларның, шул исәптән татарларның да, көндәлек яшәешен, мәдәниятен һәм авыз иҗатын максатчан рәвештә өйрәнү һәм һәм җыелган материалларны бастыру юнәлеше үсеш ала [Ямалтдинов, 2016, с. 13]. Г.Ф. Миллер, П.С. Паллас, И.И. Лепехин, Н. Рычков, М.Д. Чулков, И. Идес, Н. Костров, Г. Георги һ.б. хезмәтләрендә, башка халыкларныкы белән беррәттән, татарларның да җыр-биюләре, уеннары, халык бәйрәмнәре, легендалары, мифологик ышанулары турындагы мәгълүматлар урын ала.

XIX гасырда, этнографик эзләнүләр уңаеннан, фольклористик тикшеренүләр дә башлана. 1816 елда Иван Добровольский тарафыннан чыгарылган «Азиатский журнал»да һәм 1830 еллардагы И. Снегирев хезмәтләрендә татар фольклоры үрнәкләре инде махсус туплана

башлый. Шулай ук 1804 елда Казан университеты ачылу, аның каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте оештырылу Идел буе һәм Көнчыгыш халыкларының телен, әдәбиятын, тарихын, мәдәниятен өйрәнүнең шактый алга китүенә этәргеч бирә. Университет галимнәреннән К. Фукс, И. Березин, В.В. Радлов, Н.Ф. Катанов һ.б. татар халык иҗаты әсәрләрен җыюга һәм өйрәнүгә зур өлеш кертәләр.

XIX гасыр ахыры – XX йөз башында татар халкының, бигрәк тә керәшеннәрнең йолаларын һәм йола поэзиясен, имләү-дәвалау традициясен, мифологик ышануларын өйрәнү җанланып китә. «Оренбургский листок» газетасы битләрендә бер-бер артлы М.В. Лоссиевский һәм В.Н. Витевскийның Албасты, Бичура, Убыр, Шайтан, Кирәмәт кебек мифологик персонажларга багышланган мәкаләләре дөнья күрә [Витевский, 1878; Лоссиевский, 1878], И.М. Софийскийның керәшен татарларында язып алынган имләү текстлары [Софийский, 1878], Н.Ф. Катановның Бәләбәй өязендә яшәүче керәшен татарларында таралыш тапкан төрле авыруларга бәйле ышанулар һәм аларны дәвалау ысуллары (күз, баш, теш авыртуы, бизгәк, эт имчәге һ.б.) җәмәгатьчелеккә тәкъдим итерә [Катанов, 1900]. Венгр галиме Г. Балинтның 1875 елда басылган хезмәтендә керәшен татарлары яшәешендә Өй иясе, Сарай (ат) иясе, Урман иясе, Шүрәле, Албасты һәм Убыр турындагы ышануларның тасвирламасы бирелә [Balint, 1875]. Г.Н. Потаниннның 1884 елда басылган мәкаләсе Алабуга өязендә яшәгән удмурт, татар һәм мари халыкларының традицион мәдәниятенә багышлана. Биредә йорт-җир, кием-салым турындагы этнографик мәгълүмат белән бергә мифологик ышанулар һәм әкиятләр дә игътибар үзәгенә куела [Потанин, 1884].

XIX гасырның икенче яртысында татар фольклоры үз галимнәребез тарафыннан да өйрәнелә башлый. Мәгърифәтче, телче, тарихчы, этнограф Каюм Насыйри – татар фольклористикасы тарихында тирән эз калдырган энциклопедист галимнәрнең берсе. Татар фольклористикасының аерым фән буларак оешуы XIX гасырның икенче яртысы һәм Каюм Насыйри исеме белән бәйләнгән... Ул, татар гуманитар фәннәрендә беренчеләрдән булып, халык иҗаты әсәрләренә, аерым жанрларга, казан татарлары мифологиясенә багышланган күләмле хезмәтләр яза... [ Урманче, 2005, с. 22]. Әлеге хезмәтләрдә татар фольклористикасында беренче тапкыр мифологик персонажларны төркемләү (су астында торучы әкәмәтләр, җир өстендә яшәүче әкәмәтләр) омтылышы ясала, елан һәм аның белән бәйле Ак елан, Аждаһа, Юха елан кебек персонажларның генезисы, функцияләре билгеләнә, татар халкының ышанулар системасында «ия»ле авыруларның үзенчәлекләре тасвирлана.

Күрәсең, дөнья күргән хезмәтләр нигезендә XX гасыр башында Я.Д. Коблов казан татарлары мифологиясенә багышланган бер мәкаләсен һәм аерым китабын рус телендә бастырып чыгара [Коблов, 1910]. Эчтәлеге белән бу хезмәт Каюм Насыйринең «Поверья и обряды казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их

суннитского магометанства» мәкаләсенә якын. Я.Д. Кобловның классификациясе дә шуңа охшаш, әмма ул җир өстендә яшәүче персонажларның урыннарын тәгаенләштереп, өйдә яшәүче затлар, кырда, урманда яшәүче затлар кебек төркемнәргә аера. Әлеге хезмәттә татар мифологиясенең ислам мәдәнияте һәм тәңречелек тәгълиматы синкретизмына нигезләнгән булуы хакындагы фикер бүгенге фән күзлегеннән караганда да актуальлеген югалтмый. 1913 елда Я.Д. Коблов хезмәтенең мифологик персонажлар турындагы өлеше, татарчага тәрҗемә ителеп, «Аң» журналында «Татар хорафаты» исемле мәкаләдә «Былтыр» дигән имза астында Х. Бәдигый һәм Г. Рәхим тарафыннан бастырыла.

Татар халкының мифологик мирасын барлауда Г. Рәхимнең эшчәнлеге аерым игътибарга лаек. Күпсанлы мәкаләләрендә, басылып чыккан хезмәтләрендә галим «фольклор дип бөтен халык ышануларын, мифологиясен, хорафатларын, йолаларын, имләүләрен, әфсеннәрен, мәкальләрен, әйтемнәрен, табышмакларын, әкиятләрен, риваятьләрен, баһадир поэмаларын, сагаларын, йола һәм тарихи җырларын аңлый» [Рәхим, с. 50], аларны җыю һәм өйрәнү юнәлешләрен барлый, лекцияләрендә татар халкының мифологик системасына бәйле кызыклы күзәтүләр ясый.

XX гасырның 20 нче елларында «Татарстанны өйрәнү җәмгыяте» оешканнан соң, җәмгыять әгъзалары тарафыннан җыелган материаллар «Вестник Научного общества татароведения» дигән журналда басыла башлый. 1939 елда Казанда Тел, әдәбият һәм тарих институты оештырылгач, татарлар яшәгән төрле төбәкләргә күпсанлы фольклор, диалектологик һәм археографик экспедицияләргә чыгу эше җанланып китә. Экспедицияләр нәтиҗәсендә алып кайтылган тел һәм фольклор материаллары белән бергә татар халкының мифологик ышануларын чагылдырган мәгълүмат та фольклор җыентыкларында һәм диалектологик материалларда даими басылып бара [Халык иҗаты, 1940; Татар халык иҗаты, 1957; Материалы, 1990]. Күпьеллык экспедицияләр нәтиҗәсендә тупланган бай материал Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләренә татар халык иҗатының күптомлы җыелмасын әзерләү мөмкинлеге тудыра.

1976–1993 елларда халык иҗаты бүлеге татар фольклорының иң матур үрнәкләреннән тупланган 12 томлык җыелма бастырып чыгара. «Татар халык иҗаты» сериясенең риваятьләр белән легендаларга багышланган томында мифологик хикәятләргә махсус бүлек бирелә, кереш мәкаләдә мифологик хикәятләр жанры турында да җитди фикерләр әйтелә [Татар халык иҗаты, 1987], «Йола һәм уен җырлары» дип аталган томда исә татар халкының йола иҗаты белән аерылгысыз бәйләнештә кулланган шигъри сөйләм һәм көйләм әсәрләре туплап тәкъдим ителә, кереш мәкаләдә ырымнар, келәүләр кебек магик нигезле жанрлар фәнни яктан анализлана [Татар халык иҗаты, 1980].

XX гасырның җитмешенче елларыннан татар халык иҗатының прозаик жанрларын, йолаларын һәм йола шигъриятен өйрәнү киң

колач алса, үткән гасырның ахырыннан башлап, татар мифологиясен бүгенге фән югарылыгында өйрәнү буенча мөһим адымнар ясала [Бакиров, 2012; Закирова, 2017; Исхаков, 2014; Кариева, 2000; Касимов, 2004; Корусенко, 2013; Мәхмүтов, 2008; Миңнуллин, 2003; Мөхәммәтҗанова, 2018; Мухаметзянова, 2018; Садекова, 2001; Урманчеев, 1994; Урманчеев, 2007, 2009, 2011; Яхин, 2000 һ.б.] игътибар юнәлтү зарури. Тирән һәм киң эчтәлекле бу хезмәтләр төрки-татар мифологиясен өйрәнү өчен бай конкрет материал бирә, шул исәптән чыганакларны барлау юлында да нигезле таяныч булып тора. Диалектология, этнография, археографиянең аерым юнәлешләре буенча да татар халкының рухи хәзинәсенә һәм аның фәнни кыйммәтенә кагылышлы хезмәтләр һәм текстлар XX гасыр ахырыннан башлап, бер-бер артлы басыла башладылар. Бу уңайдан Ф.Ю. Юсупов, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, М. Әхмәтҗанов китапларын күрсәтеп үтәргә мөмкин [Әхмәтҗанов, 2012; Баязитова, 2018 һ.б.; Рамазанова, 1996; Юсупов, 2006; Сибирские татары, 2017 һ.б.]. Татар халкының төрле этнографик төркемнәренең тарихын, тел үзенчәлекләрен һәм халык авыз иҗатын өйрәнгән диалектологлар рухи мәдәниятнең аерылгысыз бер өлеше булган мифологик ышанулар системасын да читтә калдырмыйлар. Традицион мәдәниятнең бу юнәлешендә тупланган материаллар татар филологиясе өчен генә түгел, ә гомумән тюркология фәне өчен кыйммәтле хәзинә булып тора.

Озак еллар дәвамында формалашкан традицияләрне истә тотып, XXI гасырда да Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге, Казан (Идел буе) федераль университеты, Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе һ.б. оешмалар кыр эзләнүләрен дәвам итә. Аннан тыш татар халкының традицион мәдәниятенә кагылышлы мәгълүматлар Россиянең башка төбәкләрендә эшләп килә торган оешмаларның архивларында да саклана (Томск дәүләт университетының В.М. Флоринский исемендәге Археология һәм этнография музее, Омск дәүләт университетының Ф.М. Достоевский исемендәге Археология һәм этнография музее, Чувашия дәүләт гуманитар фәннәр институтының фәнни архивы, Башкортстан дәүләт университеты татар бүлегенең фольклор фонды һ.б.). Татарстан районнарына һәм татарлар компактлы яшәгән төбәкләргә оештырылган комплекслы фәнни экспедицияләр материалларыел да Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан чыгарыла торган «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә, югарыда телгә алынган оешмаларда әзерләнгән фәнни җыентыкларда өлешчә дөнья күреп бара, алар арасында татар мифологиясенә караган мәгълүматларны туплап биргәннәре дә [Башкортстан татарлары, 2018; Булатова, 2012; Закирова, 2015; Закирова 2016; Мифологические верования, 2016; Мөхәммәтҗанова, 2017; Ямалтдинов, 2015; Ямалтдинов, 2017 һ.б.] шактый.

Күргәнебезчә, татар халкының борынгы төрки мифологиядән башлангыч алган мифологик күзаллауларын һәм ышануларын җыю,

бастырып чыгару һәм өйрәнүнең күп гасырлык тарихы бар. Бу өлкәдә эшләнгән эшләр, фәнни тикшеренүләр байтак булса да, мифологик мәгълүмат туплаган текстларның һәм язма ядкярләрнең төрле җирдә чәчелеп ятуы, әлеге юнәлештә эзләнүләр алып барган кешеләр өчен авырлык тудыра. Югарыда телгә алынган борынгы һәм Урта гасырларга караган язма чыганаклардан, XVIII–XX йөз башы хезмәтләреннән, XX гасыр дәвамында дөнья күргән фольклор җыентыкларыннан, татар теленең төрле диалектларына мөнәсәбәтле тел, халык иҗаты материалларыннан торган китаплардан, фәнни монографияләрдән, мәкаләләрдән һәм төрле архивлардан алынган мәгълүматны бер системага салып фәнни җәмагатьчелеккә тәкъдим итү бүгенге фән таләпләренең берсе булып тора.

**Әдәбият**


Balint G. Kazani-tatar nyelvtanulmanyok. I. Fuzet. Kazani-tatar szove gek. Budapest, 1875.

Бакиров М.Х. Татарский фольклор: монография. Казань: Ихлас, 2012. 399 с.

Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төз., кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррире Ә.М. Сөләйманов. Уфа: Китап, 2018. 344 б.

Баязитова Ф.С. Халык традицияләре лексикасы. Мифологик персонажлар, ышанулар (җирле сөйләшләр һәм фольклор текстлары яссылыгында). Казан: Изд-во «Мәгариф-Вакыт», 2018. 816 б.

Бичурин Н.Я. [Иакинф]. Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. М.-Л. АН СССР, Институт этнографии им. Миклухо-Маклая. 1950. Т. 1. – 382 с.; Т. 2. – 335 с.

Булатова М. Асыл сүзләр халкым телендә // Милли-мәдәни мирасыбыз: Мари Эл татарлары. Бәрәңге. Казан, 2012. Б. 149–176.

Витевский В.Н. Нагайбаки, их песни, сказки и загадки // Оренбургский листок. 1878. 9 апреля. № 14-19.

Лоссиевский М.В.Из суеверий и легенд мусульман Оренбургского края // Оренбургский листок. 1878. 9 июля. № 28.

Гмыря Л.Б. Религиозные представления населения Прикаспийского Дагестана в IV-VIIвв. (По данным письменных источников). Махачкала: Изд-во «Наука ДНЦ», 2009. 540 с.

Гумилев Л.Н. История народа хунну. М.: Институт Ди-Дик, 1998. Кн.2. 496 с.

Дәүләтшин Г.М. Төрки-татар рухи мәдәнияте. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1999. .

Әхмәтҗанов М. Татар халкының борынгы ырым-арбаулары һәм төрле фалнамәләре. Казан, 2012. 271 б.

Закирова И. Мәңгелеккә аккан сулар бар // Милли-мәдәни мирасыбыз: омск өлкәсе татарлары. Казан, 2015. Б. 240–266.

Закирова И.Г. Болгар чоры халык иҗаты. Казан, 2003. 144 б.

Закирова И.Г. Әүвәл башлап ни бетте. Казан: ТӘһСИ, 2017. 152 б.

Ислам. Белешмә-сүзлек / Төз. З. Шәфигый. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 191 б.

Исхаков Р.Р. Очерки истории традиционной культуры и религиозности татар-кряшен (XIX – начало XX вв.): монография. Казань: Изд-во «Центр инновационных технологий», 2014. 332 с.

Кариева Л.А. Татарская мифология в историко-сравнительном и типологическом аспекте: дис. ... канд. филол. наук: 10.01.09. Казань, 1999. 159 с.

Касимов Р.Н. Очерки религиозно-мифологических представлений чепецких татар. Монография. Ижевск, УИИЯЛ УРО РАН, 2013. 156 с.

Катанов Н.Ф. Народные способы лечения у башкир и крещеных татар Белебеевского уезда Уфимскойгубернии // Известия общества археологии, истории и этнографии при Казанском императорском университете. 1900. Т. 16. Вып. 1. С. 1–14.

Кляшторный С.Г. Древнетюркская мифология: к постановке проблемы // Письменные памятники и проблемы истории культуры народов Востока: тезисы докладов. Ч. 2. М., 1979. С. 91–95.

Кляшторный С.Г. Древнетюркская цивилизация: диахронические связи и синхронические аспекты // СТ. 1987. № 3. С. 58–62.

Коблов Я.Д. Мифология казанских татар // Известия общества археологии, истории и этнографии при Казанском императорском университете. 1910. Т. 26. Вып. 5. 49 с.

Корусенко М.А., Ожередов Ю.Я., Ярзуткина А.А. Мифология сибирских татар в символах образов и вещей (опыты прочтения): Труды Музея археологии и этнографии Сибири Томского государственного университета. СПб.: Петербургское Востоковедение, 2013. Т. V. 256 с.

Материалы по татарской диалектологии: сб. ст. / АН СССР, Казан. фил., Ин-т яз., лит. и истории им. Г. Ибрагимова. Казань: ИЯЛИ, 1990. 130 с.

Мелетинский Е.М. Поэтика мифа. Москва: Наука, 1976. 407 с.

Мәхмүтов Х.Ш. Борынгылар әйткән сүзләр (VIII–XVIII йөз төрки-татар ядкярләрендә афоризмнар). Казан: Фикер, 2002. 255 с.

Мәхмүтов Х.Ш. Гыйбарәләр тарихыннан сәхифәләр: этимологик эзләнүләр. Казан, 2008. 462 б.

Миңнуллин К.М. Һәр чорның үз җыры. Казан: Мәгариф, 2003. 400 б.

Мифологические верования татар (по экспедиционным записям конца XX – начала XXI вв.) / Авт. вст. статьи Л.Х. Давлетшина, сост. Л.Х. Давлетшина, Ф.Х. Завгарова. Казань: Ихлас, 2016. 199 б.

Мовсес Каланкатуаци. История агван Мойсея Каганкатваци, пис. X в. / пер. К. Патканьян. СПб.: Тип. Академии наук, 1861. XVI. 376 с.

Мөхәммәтҗанова Л.Х. Дөнья цивилизациясендә татар дастаннары. Казан: ТӘһСИ, 2018. 220 б.

Мөхәммәтҗанова Л.Х. Тән азыгы – икмәк, җан азыгы – хикмәт // Миллимәдәни мирасыбыз: Мамадыш. Казан, 2017. Б. 189–240.

Мухаметзянова Л.Х. Древние письменные источники о мифах татар Поволжья // Найдаковские чтения – 4. Тюрко-монгольский мир. Гуманитарные исследования: сб. науч. статей. Улан-Удэ: БНЦ СО РАН, 2018. С. 144–147.

Потанин Г.Н. У вотяков Елабужского уезда // ИОАИЭ. Том № 3. 1884. С. 189–255.

Рамазанова Д.Б. К истории формирования говора пермских татар. Казань: ИЯЛИ, 1996. 236 б.

Рәхим Г. Сайланма әсәрләр / төз. М.И. Ибраһимов, А.М. Гайнетдинов. Казан: Ихлас, 2018. 560 б.

Садекова А.Х. Идеология ислама и татарское народное творчество. Казань: Иман, 2001. 260 с.

Сибирские татары. Из сокровищницы духовной культуры. Хикаяты, Риваяты. Мифы / авт.-сост. Ф.Ю. Юсупов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2017. 893 с.

Софийский И.М. Заговоры и заклинания крещеных татар Казанского края // Изв. по Казанской епархии. 1878. № 2. 18 с.

Татар халык иҗаты / төз. Х. Ярми, А. Шамов, Г. Бәширов, Х. Госман. Казан: Таткнигоиздат, 1957. 524 б.

Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары / төз., кереш мәкалә язучы, искәрмәләр әзерләүче И.Н. Надиров. Казан, 1980. 320 б.

Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / төз., кереш мәкалә язучы, искәрмәләр әзерләүче С.М. Гыйләҗетдинов. Казан, 1987. 368 б.

Урманчеев Ф.И. Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2002. 335 б.

Урманче Ф. Татар халык иҗаты. Казан: Мәгариф, 2005. 383 б.

Урманчеев Ф.И. Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек : өч томда Казан: Мәгариф: 1 т. (А–Г). 2008. 303 б.; 2 т. (Д–С). 2009. 343 б.; 3 т. (С–Я). 2011. 195 с.

Урманчеев Ф.И. По следам белого волка: ранние этнокультурные связи тюрко-татарских племен. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1994. 125 с.

Халык иҗаты / төз. Х. Ярми һәм А. Әхмәт. Казан: Татгосиздат, 1940. 270 б.

Юсупов Ф.Ю. Сафакүл татарлары: тарих, тел, халык иҗаты. Казан, 2006. 607 б.

Ямалтдинов И.И. Татар ул кайда да балкып яши // Милли-мәдәни мирасыбыз: Самара өлкәсе татарлары. Казан, 2015. Б. 111–164.

Ямалтдинов И.И. Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX века. Собирание, публикация и научное изучение фольклора. Казань: ИЯЛИ, 2016. 184 с.

Ямалтдинов И.И. Чиләбе өлкәсе татарлары фольклоры // Милли-мәдәни мирасыбыз: Чиләбе өлкәсе татарлары. Казан, 2017. Б. 145–224.

Яхин Ф.Н. Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Казан: ТДГИ, 2000. 268 б.

*Работа выполнена в рамках мероприятия 3.5.4 Государственной программы «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014–2020 год.*

***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 398

***И.К. Фазлетдинов***

# ФОЛЬКЛОРЧЫ ГАЛИМ РИФ МӨХӘММӘТҖАНОВНЫҢ ФӘННИ ҺӘМ ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

Данная статья приурочена к 80-летию со дня рождения видного татарского ученого-фольклориста, педагога и общественного деятеля Р.М. Мухаметзянова (1939–1996), занимавшегося более 40 лет преподавательской работой на кафедре татарской филологии Башкирского государственного университета (г. Уфа) и посвятившего всю свою жизнь исследованию фольклорных памятников татарского населения, проживающего на территории Республики Башкортостан.

В статье подвергнуты комплексному анализу основные научные труды исследователя, его публицистическая и литературоведческая деятельность.

**Ключевые слова:** ученый, обрядовый фольклор, татары Башкортостана, свадебные обряды, календарная поэзия, литература, татарское народное творчество.

This article is dedicated to the 80th anniversary of the prominent Tatar folklorist scientist R.M. Mukhametzyanov (1939-1996), who devoted his whole life to the study of the folklore monuments of the Tatar population living in the Republic of Bashkortostan.

The author considers the personality of R.M. Mukhametzyanov from three angles: as a scientist, collector and researcher of national folklore; a teacher who has been teaching for more than 40 years at the Department of Tatar Philology of Bashkir State University (Ufa); a public figure who played a huge role in the formation of the Tatar national movement on the territory of Bashkortostan in the 80s of the twentieth century.

The article thoroughly analyzes the main scientific works of the researcher, his journalistic and literary activities.

**Keywords:** scientist, ritual folklore, Tatars of Bashkortostan, wedding ceremonies, calendar poetry, literature, Tatar folk art.

*Күренекле фольклорчы-галим, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Риф ага Мөхәммәтҗановның исеме татар фольклористикасы тарихына, халкыбыз күңеленә алтын хәрефләр белән язылган. Аның хезмәтләре бүген дә меңнәрчә студентлар, халык авыз иҗаты белән кызыксынучылар тарафыннан җентекләп өйрәнелә, ә димәк, галим дә яши...*

*Риф Мирхәбибулла улының исеме, гыйльми язмалары, китаплары Башкортстанда яшәүче татарлар өчен аеруча газиз һәм якын, чөнки галим бар гомерен туган як халкының рухи мирасын барлау һәм тикшерүгә, аны саклап калуга, тирә-якта популярлаштыруга багышлады. Ул туган җиреннән, туган халкыннан беркайчан да аерылмады, аны кайгы-шатлыклары белән яшәде: татар еласа – елады, көлсә – көлде.*

Риф Мирхәбибулла улы Мөхәммәтҗанов 1939 елның 2 июлендә Башкортстандагы Ярмәкәй районының ямьле Ык елгасы куенына яшеренеп утырган Аксак авылында дөньяга килә. (Бу авыл 1960 еллардагы кечкенә авылларны берләштерү кампаниясе вакытында юкка чыгарыла. – *И.Ф.*) Яшьтән үк моңлы, җыр-шигырьгә мөкиббән малай булып үсә. Үзе дә каләм тибрәтә башлый. Туган авылында сигезьеллык мәктәптә белем алгач, 1957 елда Ярмәкәй районының Иске Турай урта мәктәбен көмеш медаль белән тәмамлый. Әдәбиятка, туган телгә булган мәхәббәте аны Башкорт дәүләт университетына алып килә [Энциклопедия, 2010, с. 117]. Шунысы кызык: Риф Мөхәммәтҗанов бер ел буена филология факультетының башкорт-рус бүлегендә укырга мәҗбүр була. Моның сәбәбен аның бертуган энесе, күренекле татар драматургы Ризван Хәмид түбәндәгечә тасвирлый.

«... Имтихан алучылар «собеседование» уздырганда – медале булгач, экзамен тотасы юк абыйның – абруйлы фольклорчы-галим Кирәй Мәргән килеп керә һәм Рифнеӊ кулында нииндидер калын «амбар кенәгәсе» күреп, кызыксынып актара башлый. «Нәмәкәй был?» – дип сорый башкорт галиме. «Әти агроном минем, ул гомер буе табигать күренешләрен көндәлеккә теркәп барды, хәтеренә төшкән йолаларны, төрле җыруларны да җыя ул, мин үзем дә кайберләрен өстәп куйгалыйм», – дип җаваплый Риф абый, ояла-ояла гына. «Нимәгә ҡыҙараһың быңа, егетем, изге нәмәдән оялмайҙар. Мин һине үҙ бүлегемә алам, ҡустым», – димәсенме атаклы фольклорчы [Хәмид, 2014, б. 23]!

Шунысын да өстик: киләчәктә филология фәннәре докторы, Башкортстанның халык шагыйре, Салават Юлаев исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Язучылар берлеге рәисе дәрәҗәләренә ирешәчәк Равил Бикбаев нәкъ шул елда Башкорт дәүләт университеты филология факультетының татар-рус бүлегенә укырга кергән була. Ягъни, кызыклы парадокс килеп чыга: башкорт егете – татар бүлегендә, татар егете башкорт бүлегендә белем ала. Беренче курс тәмамлангач, 1958 елда, бу «хата» төзәтелә – алар уку урыннары белән «алмашалар» һәм Риф ага 1962 елда БДУның татар-рус бүлеген тәмамлый. Шулай булса да, ул 1962–1966 еллар дәвамында башкорт телендә нәшер ителүче «Совет Башҡортостаны» республика гәзитендә әдәби хезмәткәр вазифасын башкара, күпсанлы очерклар, мәкаләләр яза [Энциклопедия, 2010, с. 117].

1966 елда сәләтле белгеч БДУның татар филологиясе кафедрасына эшкә чакырыла. Аңа «Татар халык иҗаты», «Татар әдәбияты тарихы» фәннәре, махсус курслар буенча лекцияләр уку, студентларның гыйльми эшләренә җитәкчелек итү бурычы йөкләтелә. Риф ага яңа эшкә күңел биреп тотына һәм тиз арада хезмәттәшләре арасында зур абруй казана.

Риф Мөхәммәтҗановның фән өлкәсендәге иң зур казанышы – БДУның татар филологиясе кафедрасы каршында фольклор фонды оештыруыдыр, мөгаен. Ул – Башкортстан татарларының халык авыз иҗатын системалы рәвештә җыю һәм өйрәнү эшен башлап җибәргән

беренче галим. 1967 елдан алып ул республиканың татарлар күпләп яшәгән районнарына утызга якын фольклор экспедициясе оештыра, 150 дән артык авылны урап чыга. Билгеле, әлеге сәяхәтләрдә катнашкан студентлар өчен бу, беренче чиратта, һичнәрсә белән алыштыргысыз аралашу мәктәбе була.

Әлеге экспедицияләрдә җыелган фольклор материаллары тиз арада фәнни әйләнешкә кереп китә. Мәсәлән, 1976–1988, 1993 елларда Казанда дөнья күргән «Татар халык иҗаты» унөчтомлыгының һәр китабында Риф Мирхәбибулла улы тарафыннан да тупланган халык авыз иҗаты үрнәкләре урын ала. Аның җитәкчелегендәге фольклор экспедицияләре вакытында җыеп алынып, БДУның татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы фондларында саклanучы ул материаллар безнең тарафтан электрон форматка күчерелде. Халыкның энҗе-мәрҗәннәре юкка чыкмасын, җилгә очмасын өчен кирәк бу гамәл.

Риф ага Мөхәммәтҗановның фидакяр эшчәнлеге нәтиҗәсендә җыелган фольклор материаллары гомуми җыентыкларда урнаштырылып кына калмый, яшь тикшеренүченең аларга карата фәнни күзәтүләре, тикшеренүләре монографик хезмәт булып формалаша. 1973 елда ул БДУдагы беренче «танышы», филология фәннәре докторы, профессор Әхнәф Кирәев (әдәби тәхәллүсе – Кирәй Мәргән. – *И.Ф.*) җитәкчелегендә «Башкортстан Ык буе татарларының йола поэзиясе» темасына кандидатлык диссертациясен яклый. Анда кулланылган материалның күплеген, эзләнүләрнең күп тармаклы булуын хезмәтнең күләме үк күрсәтеп тора. Кандидатлык диссертацияләренең уртача күләме 150–170 биттән артмаска тиеш дигән күрсәтмә булса да, аның хезмәте 228 бит тәшкил итә [Мухаметзянов, 1973]! Тикшеренүнең янә бер бик әһәмиятле ягын да истә тотарга кирәк: ул Татарстаннан читтә яшәүче татар халкының, аерым алганда, Башкортстанда яшәүче татарларның, милли фольклорын, аның төбәк үзенчәлекләрен, биредә яшәүче башка халыкларның авыз-тел тел иҗаты белән бәйләнешен чагыштырма планда, комплекслы һәм системалы рәвештә тикшергән беренче гыйльми хезмәт булып тора. Шуны да өстик, Башкортстанда яшәүче татарларның милли фольклорын фәнни тикшерү юнәлешендәге икенче кандидатлык диссертациясе безнең тарафтан язылды һәм легенда, риваять жанрларын тикшерүгә багышланды [Фазлутдинов И.К., 2005].

Риф Мирхәбибулла улының әлеге хезмәтләре киләчәктә студентлар өчен дәреслекләр, уку кулланмалары булып формалашты. Аның 1979, 1982 елларда дөнья күргән «Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: туй поэзиясе» һәм «Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: календарь поэзия» дип аталган хезмәтләре бүген дә студентлар, халык авыз иҗаты белән кызыксынучылар өчен әһәмиятле чыганаклар булып кала [Мөхәммәтҗанов, 1977; 1982]. Үз хезмәтләрендә галим Башкортстанда яшәүче татар халкының йола поэзиясен ике төргә бүлеп тикшереп, календарь һәм туй поэзиясенең жанр-

лар буенча ул чор өчен өр-яңа бүленешен тәкъдим итә, аларны Казан ягы татарлары фольклоры белән тарихи-чагыштырма аспектта анализлап, уртак һәм аермалы якларын билгели, шул ук вакытта, Башкортстанда яшәүче татарларның һәм тел, һәм мәдәният, һәм фольклор ягыннан гомумтатар халкының аерылгысыз өлешен тәшкил итүен ассызыклый. Бер үк вакытта ул уртак географик һәм рухи җирлектә гомер кичерүче башкорт, урыс, мордва, мари, чуваш һ.б. халыклар фольклоры белән параллельләр үткәрә, төрле халыкларның авыз-тел иҗатында үзара бәйләнешләрнең чагылышын тикшерә.

Мәсәлән, Башкортстан Ык буе татарларының туй йолаларына багышланган китабында ул урындагы туйны 20 ваграк йолаларга таркатып анализлый. Болар исәбенә яучылау (кодалау), ярәшү (аклашу, вәгъдәләшү, килешү), туй алды, кыз чәкчәге, кияү катламасы, ак келәт (кыз өе, ак өй), кыз мунчасы, туй көне, никах, кияү каршылау, яр-яр, кияү коймагы, күренеш (кияү күрсәтү, очрашу), кыз озату, килен төшерү, беренче иртә, су юлы күрсәтү, бүләк баглау (әйбер, туй өстәле), корбан ашы (корбан көн, олы туй, үзәк туй, мәҗлес көн), туй арты (кияү кайтармасы, шәл салдыру туе, кода төшерү) кебек ритуаллар керә.

Белүебезчә, йолалар һәрвакыт дуалистик характерда була, ягъни аларда гамәл-хәрәкәт һәрвакыт сүз компоненты белән берегеп килә, катлаулы синтез хасил итә. Бер-берсеннән тыш алар яши алмый, асыл мәгънәләрен югалта. Галим шушы үзенчәлекне тотып алып, һәр ритуалны аңа гына хас фольклор жанрлары белән бәйләнештә, комплекста тикшерә. Мәсәлән, яучының поэтик репертуарының нигезен тәшкил иткән самак җырларын ул профилактик магиягә хас булган яшерен тел, читләтеп әйтү күренешләре белән бәйләп карый; шул рәвешле әлеге йоланың, ә димәк, халкыбызның да, борынгылыгын ачып сала.

Риф Мөхәммәтҗановның татар халкы репертуарында киң таралган кыз елату җырлары-сыктауларга карата күзәтүләре аеруча кызыклы. Ул әлеге типтагы әсәрләрне бер жанр кысаларында гына карамый. Мәсәлән, галим кияүгә чыгасы кызның туй алдындагы төндә әтисе йоклаган бүлмәнең тәрәзә төбенә килеп, акча сорап җырлаган җырларын таңкучатлар дип атый. Ата кеше, җырны ишеткәч, аңа акча бирергә тиеш, чөнки мәҗүси ышанулар буенча, сатып кияүгә бирелгән кызның җаны өрәккә әверелеп, ата кешедән үч алырга мөмкин. [Мөхәммәтҗанов, 1977, б. 52–53]. Шулай итеп, биредә дә заманга хас йола борынгы мифологик күзаллаулар эзен саклый.

Киленне каршылаган каенананың поэтик репертуары да бертөрле түгел. Мондый әсәрләр һәр очракта да дидактик характерын саклый, ләкин функциональ вазыйфалары, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан галим аларны «арбау», «бит ачу», «бата», «кияү ябу» кебек төркемчәләргә бүлә һәм һәркайсының үзенә генә хас табигатен ачып сала [Мухаметзянов, 1989, с. 34–37]. Кыскасы, аның туй поэзиясе өлкәсендәге хезмәтләрен, һич икеләнмичә, татар фольклор фәненең иң кыйммәтле хәзинәләре исемлегенә кертергә мөмкин.

1982 елда дөнья күргән «Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: календарь поэзия» китабы да үзенең гыйльми тирәнлеге, шул ук вакытта биредәге һәр тезисның, һәр фикернең җирле материалга нигезләнүе белән игътибарны җәлеп итә. Биредә галим татар халкының ел фасыллары алмашынуына, хуҗалык эшләренә бәйле йолаларын өч циклга аерып тикшерә [Мөхәммәтҗанов, 1982, б. 4–64]. Әлеге хезмәтендә галим татар календарь йолаларының генезисын -эзлекле рәвештә күзаллый, аларның борынгы магия, мифология белән аерылгысыз рәвештә барлыкка килеп, заманында гамәли вазифа үтәүләрен, ягъни югары көчләр ярдәмендә, уңышның муллыгын, дөньяның иминлеген тәэмин итүләрен күрсәтә. Гасырлар үтү белән, календарь поэзия башкарган гамәли вазифа арткы планга күчә бара, алга аның сүз сәнгатенең бер өлкәсе буларак үтәгән эстетик функциясе чыга. Риф Мөхәммәтҗанов үзенең хезмәтендә бу процессны диахроник аспекттан чыгып карап, конкрет әсәрләр мисалында бик җентекле итеп ачып сала [Мөхәммәтҗанов, 1982, б. 65–72 ].

Башкортстан татарларының йола поэзиясен тикшерү аның гыйльми эшчәнлегенең бер тармагы булса, икенчесен әдәбиятта фольклор традицияләренең күчемлелеген анализлау тәшкил итте. Әллә үзе дә шигырьләр язганга, ул поэзияне аеруча якын күрде. Классик әдипләребез Һади Такташ, Фатих Кәрим, Башкортстандагы татар шигърияттен әйдәп баручы Салават Рәхмәтулла иҗатына аның тарафыннан фольклорчы күзлегеннән җентекле анализ ясалды [Мөхәммәтҗанов, 1990]. Фольклордан килгән меңьеллык традицияләрнең күчемлелеген тикшерү аша, галим халкыбызның яшәү менталитетын, рухиятен ачуга иреште.

Галимнең рус телендә нәшер ителгән «Специфика татарских фольклорных жанров» дип аталган китабын аның кырык елга якын сузылган гыйльми эзләнүләренең логик нәтиҗәсе итеп карарга кирәк [Мухаметзянов, 1989]. Биредә Риф Мирхәбибулла улы үзенең гомерлек гыйльми тикшерену предметы булган йола поэзиясе белән генә чикләнеп калмыйча, милли фольклорыбызга колачлы караш ташлый.

Китап ике бүлектән тора. «Йола поэзиясе һәм лирика» дип аталган беренче бүлектә туй һәм календарь йолаларының генезисы, аларның халык авыз иҗатының лирик төренә караган жанрлары белән бәйләнеше тикшерелә; рекрут һәм солдат җырлары (назлар) җентекле анализлана; туй поэзиясендәге үгет-нәсыйхәт җырларын бата, арбау, тулгау, картлар сүзе, вәгазь һ.б жанрларга классификацияләү принциплары тәкъдим ителә [Мухаметзянов, 1989, с. 6–44].

«Фольклор һәм әдәбият» дип исемләнгән икенче бүлектә исә галим, фән тарихында беренчеләрдән булып, ярымфольклор характердагы сөйләк жанрын Башкортстанның көнбатышында яшәүче татарларның тарихи хәтерендә әлегә кадәр сакланып килгән легендар комдив Чапаев турындагы халык хикәяләре мисалында анализлый, шулардан чыгып, сөйләк жанрына гыйльми билгеләмә бирү омтылышын ясый. Бәетләрнең, тарихи җырларның, балалар фоль-

клоры әсәрләренең язма әдәбиятка йогынтысын, традицияләр көчемлелеген тикшерү әлеге бүлекнең асылын билгели [Мухаметзянов, 1989, с. 45–74]. Бу хезмәт әлегә кадәр «Татар халык иҗаты» курсын уку-укыту процессында әһәмиятле чыганак булып кала.

Гомумән алганда, Риф Мөхәммәтҗанов үзенең кыска гына тормышында дүрт монографик хезмәт һәм уку кулланмасы, 100 дән артык фәнни мәкалә язып һәм бастырып калдыра [Энциклопедия, 2010, с. 117]. Ә экспедицияләр вакытында аның тарафыннан җыеп тупланган фольклор материалларының зур өлеше әлегә кадәр оста тикшеренүче кулын көтә.

**Әдәбият**

*Мөхәммәтҗанов Р.М.* Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: календарь поэзия / фәнни редакторы Т.Н. Галиуллин. Уфа: БДУ нәшрияты, 1982. 72 б.

*Мөхәммәтҗанов Р.М.* Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: туй поэзиясе. Уфа: БДУ нәшрияты, 1977. 72 б.

*Мөхәммәтҗанов Р.М.* Йола поэзиясе // Татар теле, әдәбияты һәм аларны укыту методикасы мәсьәләләре. Уфа: БДУ нәшрияты, 1971. Б. 30-42.

*Мөхәммәтҗанов Р.М.* Хәзерге поэзиядә традицион фольклор образларының үсеше: Һ. Такташ иҗаты материалында // Татар филологиясе мәсьәләләре (әдәби әсәрдә поэтика): вузара җыентык. Уфа: БДУ басмасы, 1990. Б. 57–67.

*Мухаметзянов Р.М.* Обрядовая поэзия приикских татар Башкирии: дис. ... канд. филол. наук: 10.01.09. Уфа, 1973. 228 с. https://search.rsl.ru/ru/record/01009856164

*Мухаметзянов Р.М.* Специфика татарских фольклорных жанров: учебное пособие / Р.М. Мухаметзянов. Уфа: Издательство БашГУ, 1989. 84 с.

Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары / томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләр әзерләүче И.Н. Надиров; фәнни редакторы Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 320 б.

*Фазлетдинов Илдус.* Юксыну // Тулпар. 2009. № 4. С. 30–31.

*Фазлутдинов И.К.* Топонимические предания и легенды татар Башкортостана: исторические основы и идейно-эстетические функции: дис. ... канд. филол. наук : 10.01.09. Уфа, 2005. 263 с.

Энциклопедия. Ермекеевский район. Республика Башкортостан: А–Я / Т.И. Аминев (рук.) и др.; редкол.: Т.И. Аминев (отв. ред.) и др.. Уфа : Уфимский полиграфический комбинат, 2010. 199 с.

***Фазлетдинов Илдус Камил улы,*** *филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе*
*һәм мәдәнияте кафедрасы доценты (Уфа);*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*халык иҗаты бүлегенең гыйльми хезмәткәре (Казан).*

УДК 373.4+821.512.145

*Д.М. Абдуллина,*
*Г.Н. Мөхәрләмова*

# ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ШӘХЕСКӘ БӘЙЛЕ УНИВЕРСАЛЬ УКУ ГАМӘЛЛӘРЕН ФОРМАЛАШТЫРУ

В статье рассматривается проблема формирования личностных универсальных учебных действий на уроках родной литературы. Преподавание этого учебного предмета должно осуществляться на основе духовно-личностного подхода, который утверждает приоритет духовной жизни человека и возможность возрождения нравственности средствами художественной литературы. Формирование личностных УУГ в этом случае происходит в плане нравственно-этической ориентации учащегося.

**Ключевые слова:** личностные универсальные учебные действия, федеральные государственные образовательные стандарты, уроки родной литературы, воспитание нравственности.

The article deals with the problem of formation of personal universal educational actions at the lessons of native literature. The teaching of this subject should be carried out on the basis of a spiritual and personal approach, which affirms the priority of the spiritual life of a person and the possibility of reviving morality by means of fiction. The formation of personal universal educational actions in this case comes in terms of moral and ethical orientation of the student.

**Keywords:** personal universal educational actions, Federal state educational standards, native literature lessons, moral education.

Бүгенге җәмгыятьтә хөкем сөргән тәртипләр, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре һәркемне бик нык уйланырга мәҗбүр итә. Җәмгыятьтә 90 нчы елларда башланган үзгәрешләр гомумкешелек кыйммәтләренең дәрәҗәсе төшү һәм әхлакый бушлык барлыкка килү кебек рухи проблемаларны китереп чыгарды. Җәмгыятьтә глобальләшү тенденциясенең көчәюе милли-мәдәни, милли-тарихи үзенчәлекләрнең юкка чыгуына, аларның әһәмиятләре югалуга китерә. Алар белән бергә кешелеклелек кыйммәтләре, иман, рухи кыйбла кебек аеруча мөһим мәсьәләләр дә артка чигенә, укучыны шәхес буларак тәрбияләүнең нигезе какшый. Шуңа күрә дә хәзерге көндә әдәбият дәресләрендә милли тәрбия бирүнең, шәхескә этник әхлакый-эстетик кыйммәтләр яссылыгында җәмгыятьтә үз урынын билгеләү юлын күрсәтүнең, гасырлар буе тупланган милли рухи тәҗрибәне мөмкин кадәр тулырак тапшыруның әһәмияте арта. Шәхси – милли – гражданлык – гомумкешелек кыйммәтләре кебек бер чылбырга тезелеп барган кыйммәтләр системасы гына укучыны туган иленең патриоты, туган җирен яратучы, төрле милләтләргә һәм халыкларга хөрмәт белән карауччы шәхес итеп тәрбияләүгә юнәлеш бирә ала.

Интернет тәэсирендә укучыларда клип-фикерләү барлыкка килә. Бу нәрсәне аңлата соң? Мондый төр фикерләү вакытында бала аңында әйләнә-тирә турында мәгълүмат үзара бәйләнмәгән, бер-берсеннән аерылган фактлар (кадрлар) җыелмасы буларак кабул ителә. Нәтиҗәдә, мәгълүматны тоташ, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре аша аңлап кабул итү, анализ ясау мөмкинлеге чикләнә. Шуның нәтиҗәсендә, укучылар укылган текстны авыр аңлыйлар. Әдәби әсәрнең темасына һәм төп идеясенә дә авырлык белән генә төшенәләр, әсәрне өстән генә кабул итәләр, тирәндә яткан мәгънәне, подтекстны күрергә сәләтле булмыйлар.

Бүген балаларның көне-төне компьютер һәм телевизор каршында утырулары беркемгә дә сер түгел. Бүгенге укучыларның күбесе күп вакытын телетапшырулар, видео карауга, музыка тыңлауга, компьютерда уйнауга, социаль челтәрләрдә дуслары белән аралашуга багышлый. Яшьләр яңа технологияләрдә бик җиңел ориентлашалар, башкаларның бу өлкәдә хәбәрдар булмаулары аларда ризасызлык тудыра. Шул ук вакытта аларның яңа информацион технологияләр куллануга мөнәсәбәтләре прагматик характерда гына. Алар әзер информацияне чагыштыру, дөреслеген тикшерү кирәклеген бөтенләй уйламыйлар, күчереп кенә алырга күнегәләр. Күп очракта бу мәгълүмат алар тарафыннан иясез итеп кабул ителә, тапкан информацияләрнең авторлары булга гомумән игътибар бирелми. Әдәби әсәрләр дә аларның аңында авторсыз гына, әсәрнең язылу вакытыннан бәйсез рәвештә кабул ителә, шул сәбәпле анализның хронологик аспекты арткы планга күчә. Шуңа күрә, әдәбият дәресләрендә текстны укып аңлау, анализлау талп ителгәндә, алар моңа әзер булмыйлар, бу исә уку-укыту процессын да тоткарлый.

Индивидуаль прагматиклык укучылар үзаңында бик тиз урнаша. Укучылар бары тик алдагы тормышларында үзләренә кирәк булырга мөмкин дип уйлаган фәннәрне генә «өйрәнергә» телиләр.

Күп кенә яшүсмерләр традицияләргә һәм кыйммәтләргә ышанмауларын ачыктан-ачык белдерәләр. Алар әхлакый нормаларның мөһимлеген тиешле югарылыкта аңламыйлар, аларны үтәү мәҗбүри дип санамыйлар.

Мәгариф турындагы яңа законда тәрбия бирү – шәхесне үстерүгә, гаилә, җәмгыять һәм ил күләмендә иҗтимагый-мәдәни, рухи-әхлакый кыйммәтләр һәм җәмгыятьтә кабул ителгән кагыйдә һәм нормалар нигезендә укучыларның үзбилгеләнүе һәм социальләшүе өчен шартлар тудыруга юнәлтелгән эшчәнлек буларак бәяләнә.

Тәрбия эше – ул билгеле бер сыйныфтан, дәрестән тыш эш, яки сыйныф җитәкчесенең эше дип кенә уйлау дөрес түгел. Ул – беренче чиратта, бала алдына кереп баскан һәр укытучының вазифасы. Дәрестә тәрбия эше алып бару уку-укыту процессына билгеле бер дәрәҗәдә комачау итә, дигән фикерләр дә очрый. Моның белән һич тә килешеп булмый.

Тел дәресләрендә дә, әдәбият дәресләрендә дә аеруча укучыларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү күп очракта әдәби текстларны куллану

аша алып барыла. Зур тәэсир көченә ия булган матур әдәбият укучыларның рухи аңын формалаштыруда, кешенең бу дөньяда торткан урыны һәм аның роле, яшәү мәгънәсе турында күзаллау тудырырга ярдәм итә, югары хисләр тәрбияли.

Чыннан да, кеше төрле фәннәрдән тиешле белемнәргә ия булып та, тормыш өчен кирәкле әдәп-әхлак кагыйдәләрен белмәсә, хис-тойгылардан азат, кешелеклелек сыйфатларыннан мәхрүм булса, башкалар белән мөнәсәбәтләр урнаштыра белмәсә, җәмгыять манкортлар һәм кеше сыйфатындагы роботлар җирлегенә әйләнер иде.

Әдәбият, сәнгатьнең бер төре буларак, кешенең җанына үтеп керә, хисләрен кузгата. Аның төп сурәтләү объекты да – кеше, аның рухи дөньясы, яшәеше һәм шуның белән бәйле мәсьәләләр. Шул яктан ул укучыга башка бер фән дә бирә алмаган дөрес яшәү һәм уңышка ирешү өчен башкаларның эчке дөньясын, рухи хәләтен, кис-кичерешләрен, холыкларын һәм кәефләрен аңлау һәм алар белән мөнәсәбәт урнаштыру өчен кирәкле белемнәрне дә бирә. Ә тормышта әңгәмәдәшеңнең холкын, кәефен, аның синнән нәрсә көткәнен аңламый торып, вакытсыз һәм урынсыз сүз башлаудан да олы хата юк. Димәк, Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләп иткән заманча югарылыктагы, һәрьяклап үскән, көндәшлеккә сәләтле шәхес тәрбияләү бурычын, иң элек, әдәбият дәресләрендә тормышка ашырыла. Шәхескә юнәлтелгән универсаль уку гамәлләрен билгеләгәндә, без менә шул бурычны ачык күзалларга тиеш булабыз.

Федераль дәүләт белем бирү стандартларындагы укучы шәхесен һәм фикерен хөрмәт итү һәм аңа сак мөнәсәбәт дигәндә, нигәдер, укучы әйткән һәр фикер «әйе», «дөрес» сүзләре белән генә бәяләнергә тиеш дип аңлау калыплашып килә. Юк, укучы әйткән һәр фикер дөрес, кире кагылмаслык була алмый. Моның өчен аның белеме дә, тәҗрибәсе дә җитми. Укучы, үз фикере ялгыш булудан куркып, дәшми калмаска гына тиеш. Укытучыны, башкаларны тыңлаганнан соң, аның дөрес нәтиҗәгә килә белүе һәм бу нәтиҗәне кем беләндер килешеп кенә түгел, ә нәкъ менә үзе аңлап ясавы зарур. Бу урында укытучы баланың күңеле төшмәслек, аны уйланырга мәҗбүр итәрлек, дөреслеккә якын килә алырлык итеп этәргеч бирә. Билгеле бер ситуациягә нәтиҗә ясаганда, үз-үзеңне тотуның уртак кагыйдәләренә, әхлак кануннарына, үзара мөнәсәбәтләрдәге этикет һ.б.га нигезләнеп эш йөртергә кирәк. Әйтик, М. Фәйзинең «Галиябану» әсәрендә Исмәгыйльне үз горурлыгын саклый, үз теләгәненә ирешү өчен көрәшә дип, уңай яктан бәяләүче табылганда, укытучы берничек тә бу фикер белән ризалаша алмый бит. Үз максатыңа ирешү өчен башкаларга явызлык эшләмәскә тиешлекне аңлату кирәк була.

Бүгенге көндә әдәбиятка (бигрәк тә яшьләрдә) игътибарның бик нык кимүе беркемгә дә сер түгел. Дөньяны танып белүгә юнәлдерелгән, тормыш дәреслеге булган әдәбият бүгенге көндә игътибар үзәгеннән төшә. Шуның нәтиҗәсендә җәмгыятьнең рухи яктан таркалуы, традицион кыйммәтләрнең югалуы күзәтелә.

Прагматиклык, карьера ясый белү, бизнес структураларына уңышлы гына кереп китә белү төп кыйммәтләргә әверелә. Шуңа күрә, хәзерге яшьләрдә, моның өчен классик әдәбиятның кирәге шул кадәр генә, чөнки аның кыйблалары хәзерге тормыш кыйммәтләреннән нык аерыла, дигән фикер яши. Әмма бу ялгыш фикер. Әдәбият искерми, югалмый торган кыйммәтләргә ия. Дәреслеккә кергән әсәрләр җиде иләктән үткәреп сайланган, аларның һәркайсыннан искиткеч зур тәрбияви чыганак табарга була. Бу укытучының әзерлекле, эзләнүчән, иҗади булуын гына таләп итә. Кеше үзендә тупларга тиешле киң күңеллелек (яхшылык), мәрхәмәтлелек, кешелеклелек, намуслылык, гаделлек, тугрылык, тәрбиялелек, җаваплылык, эш сөючәнлек, башкаларга хөрмәт кебек әхлакый сыйфатларны тәрбияләүдә аларның әһәмияте искиткеч зур.

Әдәби әсәр – ул автор белән укучы арасында үзенчәлекле бер күпер кебек. Язучының фикеренә төшенеп, текстның проблемалы эчтәлеген ачыклап, укучы үзенең танып белү колачын киңәйтә.

Әдәбият дәресендә тәрбияләүнең бердәнбер методы булып сүз, лекция, әхлакый әңгәмәләр генә тормый. Бу дәресләрдә гамәли юнәлеше булган методларны да кулланырга кирәк, чөнки әхлакый категорияләр белән таныштыру тормыш белән үрелеп, «тормыш дәреслеге» буенча алып барылырга тиеш. Бу, үз чиратында, рухи камилеккә омтылышны арттыра. Укучылар ниндидер абстракт төшенчәләр хакында гына түгел, чынбарлык турында да сүз барганлыгына төшенә. Уйлана, чагыштыра, үзен шул ситуация эчендә тоеп карый һәм тиешле нәтиҗәләргә килә. Ул нәтиҗәләр бала күңелендә гомерлеккә уелып кала.

Дәрестә кулланыла торган тәрбияләү алымнары укучыларны дәрестә өйрәнелә торган әсәргә дә тирәнрәк үтеп керергә, үзаң, үзбәя, шәхси бәя булдырырга ярдәм итәргә тиеш.

Боларга түбәндәгеләр керә:

• эпиграф белән эш – бөек шәхеснең өйрәнелә торган проблемаларга багышланган афоризмына яки шигыренә төшенү;

• акыл штурмы – тормыштагы, әдәбияттагы, публицистикадагы бик тә билгеле булган, шул ук вакытта күңелгә үтеп керердәй, образлы, ачык фактлар турында уйлану;

• укучыларның үз тормышына әхлакый идеяләрне күчереп кую (биредә мораль сайлау турында уйланырга, карар кабул итәргә, үзләренең позицияләрен исбатларга тәкъдим ителә);

• классик язучылар хәл итәргә алынган әхлакый мәсьәләләрне бүгенге көндә җәмгыятьтә кабул ителгән үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән чагыштыру: кешенең үз-үзен тоту нормаларына таләпләр үзгәргәнме, әллә тормыш үз үзгәрешләрен кертәме?

Стандарт булмаган дәресләрне кулланышка кертү (дәрес-концертлар, дәрес-диспут, дәрес-уйлану, дәрес-дискуссия, дәрес-уен (әдәби уен) һ.б.), шулай ук информация-коммуникация технологияләрен, укучыларның эшчәнлеген бәяләгәндә үзбәя алымын куллану

мөстәкыйльлекне үстерә, хаталарны күрә, төзәтә белергә өйрәтә. Укучылар мәгълүматны сайлап, тәнкыйди караш аша үткәреп кабул итәргә кирәклеген дә, аны куллануның хокукый якларын да аңлыйлар. Мөстәкыйль һәм коллективта аналитик эшчәнлек алып барырга өйрәнәләр.

Шәхескә бәйле универсаль уку гамәлләре, иң элек, балага үзен танырга, бәяләргә өйрәтергә тиеш.Ул үзенең көчле һәм көчсез якларын, нәрсәләрне белү-белмәвен дөрес бәяли һәм үз үсешенең максатларын билгели алганда гына үстерелешле хәрәкәт итәчәк. Баланың үз шәхесен бәяләве аның бурычларын һәм хокукларын аңлавы белән дә бәйле. Җәмгыятебездә бала хокукларын яклау бер генә яклы тәкъдим ителмәскә тиеш. Хокуклар һәрвакыт бурычлар белән керешеп яши. Бала ата-ана, гаилә, мәктәп, җәмгыять алдында нинди бурычлары булуын кече яштән үк танырга һәм аны намус белән үтәргә дә тиеш.

Әхлаклылык тәрбияләү, укучының шәхесара мөнәсәбәтләрдә ориентлашуын формалаштыру, беренче чиратта, бүгенге көндә яңа ФДББС таләп иткән дүрт универсаль уку гамәленең берсенә – шәхескә бәйлесенә нигезләнә.

Стандарт «социаль һәм әхлакый яктан билгеләнгән кешенең тышкы һәм эчке сыйфатлары» шәхескә бәйле универсаль уку гамәлләре дип санала [Поташник, Левит, с. 33]. Алар укучыны рухи яктан тәрбияли, ягъни ул баланың тормыш кыйммәтләрен, әхлакый һәм мораль нормаларны аңлавына һәм кабул итүенә, гамәлләрне кабул ителгән тәртип нормалары белән чагыштыруына, әйләнә-тирәсендәге барлык нәрсәгә шәхси караш формалаштыруына, үзара мөнәсәбәтләрне көйли белүенә юнәлтелгән. Икенче төрле әйткәндә, шәхескә бәйле универсаль уку гамәлләре хисләр, фикерләр, кыйммәтләр дөньясында мөстәкыйль рәвештә дөрес сайлый белү (үз кыйбласын билдыру) һәм шуның өчен (шул юнәлештә кылган гамәлләре өчен) җаваплы була белүне аңлата.

Мәктәптә әдәбият укытуның төп бурычларының берсе булып укучыларга әхлакый тәрбия бирү һәм аларның иҗтимагый (гражданлык) үзаңын формалаштыру тора. Бу түбәндәгеләрдә чагылыш таба:

– шәхеснең гармоник үсеше максатыннан дөньяны эстетик кабул итүнең формалашуы;

– башка кешеләр белән диалог алып бара һәм үзара аңлаша белү;

– әхлакый хисләр, яхшы мөнәсәбәт һәм үз гамәлләреңә җаваплылык;

– уңай герой үрнәге нигезендә укучының үз карашлары формалашу;

– шәхси сайлауны (үз кыйбласын табуны) тәэмин итә торган әхлакый ориентлашу;

– татар халкының тарихы, мәдәниятенә хөрмәт формалашу;

– үз иленең мәдәни мирасына карата горурлык һәм хөрмәт хисләре туу;

– формалашкан шәхси кыйммәтләр нигезендә әдәби геройларның гамәлләрен, әдәби әсәрне бәяләргә өйрәнү;

– үз белемнәре һәм тәҗрибәсе нигезендә әхлакый мәсьәләләрне хәл итүгә сәләт, дөрес шәхси үзбилгеләнеш өчен шартлар формалашу;

– әдәби әсәрне өйрәнү аша шәхеснең гражданлык тәңгәллеге нигезләре формалашу, әдәби герой образлары нигезендә шәхси кыйммәтләр тәрбияләнү.

Моннан тыш укыту процессында формалаша торган шәхескә бәйле универсаль уку гамәлләре турында да онытмаска кирәк. Боларга түбәндәгеләр керә:

– укуга җаваплы караш, белем алуга һәм танып белүгә мотивация нигезендә үзүсешкә һәм белем алуга сәләт һәм әзерлек формалашу;

– укуга, индивидуаль һәм коллектив иҗади эшчәнлеккә, үзлегеннән камилләшүгә тотрыклы мотивация формалашу;

– фән һәм җәмгыять үсешенең хәзерге дәрәҗәсенә туры килә торган һәм аның социаль, мәдәни, тел, рухи яктан төрлелеге дә исәпкә алынган хәлдә дөньяга тулаем караш формалашу;

– белем алуда, иҗтимагый файдалы хезмәттә, уку-тикшеренүдә, иҗади эшчәнлектә, яшьтәшләре, өлкәннәр һәм кечерәк яшьтәге иптәшләре белән аралашуда һәм хезмәттәшлектә коммуникатив компетентлылык формалашу;

– тикшеренү эше гамәлләре һәм үздиагностика алымнары формалашу;

– үзанализ, үзконтроль, үзбәя гамәлләре формалашу.

Әдәби әсәрләр белән танышу барышында укучылар иң кирәкле әхлакый төшенчәләрне үзләштерә. Биредә укучыларның гражданлык һәм әхлакый-кыйммәти позицияләре формалаша, шуңа күрә баланың игътибарын геройларның эш-гамәлләренә һәм анда чагылыш тапкан әхлакый кыйммәтләргә юнәлтергә кирәк. Укучыларны уңай үрнәк белән тәрбияләү еш кулланыла торган гадәти алымнардан санала. Шул ук вакытта икенче якны да онытмаска кирәк. Мәсәлән, К. Насыйриның «Кырык бакча»сындагы хикәя геройларының берсе:

– Әдәпкә кайдан өйрәндең? – дигән сорауга:

– Әдәпсезләрдән, – дип, җавап бирә. Димәк, тәрбия бирүдә бу алым да бик отышлы. Әсәрне тормыш белән бәйләгәндә, яшәештән мисаллар китергәндә, уңай үрнәк кенә түгел, тискәре гамәлләрне дә мисалга китереп, аларның начар икәнлеген аңлату да отышлы. Әдәби геройның да, тормышта кешеләрнең дә кискен рәвештә я уңай, я тискәре типларга гына бүленмәгәнлеген күздә тотканда, бу алымның әһәмияте тагын да арта төшә. Анализ шул юнәлештә барганда, укучы нәрсә яхшы, нәрсә начар икәнлеген тизрәк төшенә. Кемнең, кайда хата яки ялгыш җибәрүен таный, ул ялгышның нәтиҗәләрен күрә. Беренче карашка бик зур күренмәгән ялгыш, кечкенә бер гамәл, уйланылмый әйтелгән бер сүз кешенең язмышын хәл итәргә мөмкин икәнлеген аңлый.

Укучыларның актив эшчәнлеге тирә-якны иҗтимагый яктан танып белүгә сәләтне әдәби тексттагы конкрет вакыйгаларга бәя бирү аша үстерә.

Әдәбият – яшь буынның рухи табигатен һәм әхлакый ориентирларны формалаштыручы төп уку дисциплиналарыннан санала, чөнки «әдәби әсәрләр кеше тормышында әхлак законнарының урынын ачыклау, әхлакый караш булдыру, кешенең үз-үзен тотышынтәртибен, аерым характер сыйфатларын ачып бирү сәләтенә ия» [Заһидуллина, б. 8]. Ул укучының эмоциональ, интеллектуаль һәм эстетик үсешендә, аның дөньяны аңлавын һәм милли үзаңын формалаштыруда мөһим урынны алып тора, чөнки моннан башка милләтнең рухи үсешен гомумән күзаллап булмый.

Укучыларда шәхескә бәйле универсаль уку гамәлләрен формалаштыруда билгеле бер алымнарны куллану уңай нәтиҗә бирә.

Әсәрнең эчтәлегенә салынган әхлакый кыйммәтләрне укучы күңеленә тәэсир итәрлек, аның хисләрен кузгатып, шул хисләрне үз күңелләре аша кичерергә этәрерлек итеп аңлату отышлы санала. Әйтик, М. Җәлилнең «Соңгы җыр» шигырен өйрәнү барышында укучыларга түбәндәге сорауларны бирү аларның эмоциональ халәтен билгеләп, лирик геройның нинди хисләр кичерүләрен аңлауга ярдәм итә.

– Лирик герой кайда?

– Әсәр нәрсәгә нигезләнә? Ни өчен автор капма-каршылыкның нәкъ менә шушы формасын сайлаган? Ул нинди роль уйный?

– Беренче дүртьюллыкны тиешле интонация белән укырга тырышыгыз. Сез аны нинди хис белән укырсыз?

– Икенче дүртьюллыкта кемгә кем каршы куела? Шагыйрь ни өчен кош образын сайлап алган? Кош нәрсә символы ул? Үзегезне лирик герой итеп күз алдына китерегез. Бу юлларны ничек укыр идегез?

– Өченче дүртьюллыкта лирик герой үзен чәчәккә капма-каршы куя. Бу вакытта ул нинди хисләр кичерә?

– Шигырь ахырында автор нәрсәгә ышана? Шигырьнең соңгы юллары нинди хисне белдерә? Аларны тиешле интонация белән укыгыз.

Әлеге сораулар һәм биремнәр нигезендә укучылар лирик геройның авыр халәтен төшенүгә ирешәләр.

Укучылар сугышның кеше язмышына ни рәвешле тәэсир итүен, аның хаксызлыгын, гаделсезлеген, зур фаҗига булуын аңлыйлар; кешелеккә ябырылган нинди куркыныч афәт булуын төшенү белән бергә, әхлакый тәрбия бирү проблемасын чишүдә тискәре сыйфатларны танырга өйрәнәләр, моны киләчәктә булдырмау юллары турында фикерләшәләр.

Шулай итеп, уку-укыту барышында хис даирәсен тәрбияләп, аның әхлагына тәэсир итеп була.

Кешенең хисләрен, фикерләрен тою сәләтен үстермичә, баланы әхлакый, эмоциональ-эстетик яктан тәрбияләү мөмкин түгел. Аны кечкенә яшьтән үк кешедәге шатлык, кайгы, күңел төшү кебек хисләрне аера белергә һәм шул хисләргә үз фикерләре, эш-гамәлләре белән җавап бирергә өйрәтергә кирәк. Әдәби әсәрләрне укыганда укучылар теге яки бу әдәби герой нинди хисләр кичерүен аңлап, аңа

теләктәшлек күрсәтергә өйрәнәләр. Баланың яшь үзенчәлекләренә туры китереп сайланган әсәрләр уңышка ирешүнең төп шарты булып тора. Аерым әсәрләрне өйрәнгән вакытта, шәхескә бәйле универсаль уку гамәлләрен билгеләгәндә, шәхес формалаштыруга ярдәм итә алырлык, бер яки берничә идея алгы планга чыгарыла.

Предмет укытучысы һәрвакыт шуны истә тотарга тиеш: иң әһәмиятлесе – без укыта торган фән түгел, ә без тәрбияли торган бала шәхесе. Шуңа күрә һәр укытучы шәхескә бәйле универсаль уку гамәлләрен формалаштыру эшендә бала шәхесенә ярдәм итү өчен, түбәндәгеләрне исәпкә алырга тиеш:

– Укучыга рухи таләпләрен, сәләтләрен, киләчәккә үсеш мөмкинлекләрен һәм чикләрен ачыклый торган шәхси концепцияләрен төзергә һәм үзенең тормышын иҗат итү җаваплылыгын аңларга ярдәм итү;

– шәхесне гомумкешелек һәм милли байлык булып саналган мәдәни кыйммәтләр белән бәйләнешкә кертү, аларга аның үз мөнәсәбәтен барлыкка китерү;

– гомумкешелек тарафыннан кабул ителгән гуманлы әхлакый нормаларны (яхшылык, шәфкатьлелек, кешеләрне аңлый һәм хәленә керә белү һ.б.) һәм шәхеснең әһәмиятле күрсәткече булган зыялылыкны (интеллигентлылыкны) үстерү;

– шәхеснең интеллектуаль-әхлакый ирегең, үз-үзенә һәм башкаларга дөрес бәя бирүен, тәртибен, эшчәнлеген үзлегеннән көйләү сәләтен үстерү;

– гомумкешелек һәм этник кыйммәтләр бердәмлегендә ватанпәрвәрлек хисләрен яңарту, ил кануннарына һәм шәхеснең гражданлык хокукларына хөрмәт, Ватанның абруен, данын һәм байлыгын сакларга омтылыш тәрбияләү;

– илнең матди фондын һәм рухи потенциалын, димәк, шәхеснең дә үсеш мөмкинлекләрен тәэмин итүче иҗтимагый һәм шәхси әһәмияткә ия ихтыяҗ һәм фактор буларак хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру;

– сәламәт тормыш рәвеше турында урнашкан тәртипләрне һәм карашларны үстерү.

Әдәбият дәресләрендә укытучы шул максатларны күздә тотып эшен оештыра, аңа ирешү чараларын, алымнарын сайлый. Һәр дәресенең нинди мөмкинлеккә ия булуын укытучы төгәл итеп үзе генә билгели ала.

Укытучыдан олы хезмәт, зур тырышлык таләп итә торган рухи-әхлакый тәрбия нәтиҗәләре, беренче чиратта, балаларның үз-үзен тотышларында, үзара мөнәсәбәтләрендә, иҗади эшләүләрендә, тормышка карашлары үзгәрүдә, мораль яктан үсүләрдә чагылыш таба. Чөнки яхшы гамәлләр эшләүгә теләге, әхлакый сафлык, рухи байлык балалар күңелендә мәңгегә урнаша һәм аларда якты хисләр уята.

Шулай итеп, шәхескә бәйле универсаль уку гамәлләрен формалаштыру рухи-әхлакый тәрбия бирү буенча җентекле, тирән эш

нәтиҗәсе булып тора. Моның өчен билге куеп булмый. Бу билгене тормыш үзе куячак.

### Әдәбият

Воспитательный процесс: изучение эффективности. Методические рекомендации. М.: ТЦ «Сфера», 2001.

*Заһидуллина Д.Ф.* Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. Яңадан эшләнгән һәм тулыландырылган икенче басма. Казан: Мәгариф, 2004. 368 б.

*Крылова О.Н.* Муштавинская И.В. Новая дидактика современного урока в условиях введения ФГОС ООО: методическое пособие. СПб.: КАРО, 2015. 144 с.

*Поташник М.М., Левит М.В.* Как помочь учителю в освоении ФГОС. Методическое пособие. – М.: Педагогическое общество России, 2015. 320 с.

*Хуҗиәхмәтов Ә.Н.* Тәрбия – мәңгелек фәлсәфә: Югары һәм махсус урта уку йортлары өчен педагогикадан уку ярдәмлеге. Казан: Мәгариф, 2001.

***Абдуллина Диләрия Марат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Мөхәрләмова Гөлназ Нурфат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге мөдире*

УДК 37(470.41)

***И.С. Насипов***

## БАШКОРТСТАНДА ТАТАРИСТИКА ҮЗӘКЛӘРЕ

В статье определяется роль кафедр татарской филологии вузов Республики Башкортостан в удовлетворении национально-культурных запросов татарского населения республики. Эти кафедры являются не только научно-методическими структурами по подготовке учителей татарского языка и литературы, филологов широкого профиля для гуманитарных отраслей, но одновременно являются научными центрами по изучению татарского языка, литературы и культуры. Преподаватели этих кафедр ведут научно-исследовательскую деятельность по широкому спектру проблем татароведения, в том числе связанных с удовлетворением национально-культурных запросов татарского населения в регионе.

**Ключевые слова:** вузы Башкортостана, татары Башкортостана, кафедра, татарский язык, татарская литература, татарская культура.

The article defines the role of the departments of Tatar philology of universities of the Republic of Bashkortostan in meeting the national and cultural needs of the Tatar population of the republic. These departments are not only the scientific and methodical structures in the teachers training of Tatar language and literature, multi-skilled scholars of language for humanities, so at the same time they are research centers of Tatar language, literature and culture learning. The professors of these departments hold the scientific and research activities in sphere of the Tatar Studies problems, including the satisfaction of national and cultural request of Tatar population in the region.

**Keywords:** The universities of Bashkortostan, the Bashkortostan Tatars, Department, Tatar language, Tatar literature, Tatar culture.

Башкортостанда татаристика үзәкләре – республикада яшәүче татарларның матди һәм рухи дөньясын киң даирәдә фәнни өйрәнү белән шөгыльләнүче үзәкләр булып югары уку йортларында эшләп килүче татар филологиясе кафедралары тора. Чөнки татар мохите белән фәнни нигездә кызыксынучы башка махсус оешмалар булмады, һәм алар бүген дә юк. Бу кафедраларда эшләүче белгечләр нигездә татар теле, әдәбияты һәм мәдәнияте проблемалары белән шөгыльләнсәләр дә, күп очракта бу яктан алар республика кысалары белән генә чикләнмәсәдер, җирле татарларның этно-мәдәни торышын фәнни барлауда да төп эшне башкардылар. Дөрес, бу кафедралар иң элек үз фазифаларын үтәделәр: алар республиканың мәгариф оешмалары өчен татар теле һәм әдәбияты укытучылары, татарча чыккан газета-журналлар өчен журналистлар әзерләделәр. Бу уку йортларының татар бүлекләрен тәмамлаган белгечләр, татар халкының теле, әдәбияты һәм мәдәнияте белән бәйле өлкәләрдә генә түгел, ә тормышның барлык сфераларында хезмәт иттеләр.

Республика татарларының мәдәни тарихын барлаганда, беренче чиратта Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе һәм

мәдәнияте кафедрасы эшчәнлегенә тукталу зарур. Чөнки бу уку йортындагы кафедра XX гасырның туксанынчы еллары башына кадәр татар филологиясе һәм мәдәнияте буенча бердәнбер уку-укыту һәм фәнни-методик үзәк булып торды. Һәм бүген дә ул бу вазифасын уңышлы башкара.

Башкорт дәүләт университетының филология факультеты «татар теле һәм әдәбияты» белгечлегенә үзенең беренче студентларын 1950 елда кабул итә. Аның беренче укытучылары турында сөйләгәндә, Ә.З. Нигъмәтуллинны искә алмый мөмкин түгел. Ул Бөек Ватан сугышында катнаша, укытучылык итә. 1949 елда Казан дәүләт университетын тәмамлап, аспирантурада укый, филология фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсен ала. 1954 елда ул Тубыл дәүләт педагогия инситутыннан Уфага – Башкорт дәүләт университетына татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып кайта. Монда 1994 елга чаклы хезмәт куя, филология фәннәре докторы була, профессор дәрәҗәсенә күтәрелә.

Башкорт дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты кафедрасы 1958 елда ачыла. Аның беренче мөдире итеп филология фәннәре кандидаты, доцент Г.Х. Әхәтов билгеләнә һәм ул кафедра белән 27 ел уңышлы җитәкчелек итә. Зур оештыру сәләтенә ия яшь галим кафедра эшчәнлегенең үсеш юнәлешләрен дөрес билгели һәм аны тиешле әзерлекле кадрлар белән тәэмин итү эшенә керешә. Ул тиз арада куелган максатларга ирешә һәм кафедра университетның башка кафедралары арасында үзенең урынын ала.

Г.Х. Әхәтов яңа урында 1951–1958 елларда Тубыл дәүләт педагогия институтында татар теле һәм әдәбияты кафедрасы оештыру һәм аның эшен җайга салу өлкәсендә туплаган бай тәҗрибәсен оста файдалана. Иң беренче чиратта ул кафедрага Казан дәүләт университетында белем алган, аннан соң үзе белән бергә Тубылда эшләгән филология фәннәре кандидаты, доцент Ф.М. Хатиповны чакырып китерә. (Ул Уфада 1959–1972 елларда хезмәт итә). Ул.

Казан югары уку йортларында һәм фәнни учреждениеләрендә Г.Х. Әхәтовка Уфадагы кадрларга таянып эш итәргә киңәш бирәләр. Кафедра мөдире Казанда белем алган сәләтле белгечләрдән «Кызыл таң» газетасы хезмәткәрләре С.Ш. Поварисовны һәм Б.С. Сәлимгәрәеваны эшкә чакыра. Алар икесе дә Казан дәүләт педагогия институтын кызыл дипломга тәмамлаганнар, икесенә дә аспирантурада калырга тәкъдим иткәннәр, ләкин төрле сәбәпләр аркасында туган якларына әйләнеп кайтканнар. С.Ш. Поварисов Бөек Ватан сугышында катнашкан, мәктәптә укытучы, директор булып эшләгән. Ул «Кызыл таң»нан кафедрага укытучы булып килә һәм гомеренең соңгы көннәренә чаклы студентларга белем бирә (1960–2016). Ассистенттан филология фәннәре докторы, профессор дәрәҗәсенә кадәр үсә. Б.С. Сәлимгәрәева да кафедрада ассистенттан филология фәннәре кадидаты, доцент дәрәҗәсенә чаклы хезмәт юлы уза (1962–2000).

«Кызыл таң» газетасы соңрак та татар теле һәм әдәбияты кафедрасын кадрлар белән тәэмин итеп тора: Ү.И. Гыймадиев (1968–1987)

һәм Р.Г. Сибагатов (1970–2005) кафедрага шулай ук әлеге газета редакциясеннән киләләр. Алар да филология фәннәре докторлары, профессорлар булалар, кафедра мөдире вазифаларын да башкаралар.

Г.Х. Әхәтов берничә белгечне Казаннан да чакыртып китерүгә ирешә. Филология фәннәре кандидатлары К.С. Дәүләтшин (1972–2013) профессор һәм С.Г. Хафизов (1974–2002) доцент вазифаларында уңышлы укытучылык итәләр. Аларның Уфага килүе Казан югары уку йортлары һәм фәнни учреждениеләре белән элемтәне тагын да ныгыта, иҗади багланышлар җанланып китә. Мөдир буларак Г.Х. Әхәтов үзе дә кафедраны фәнни-методик яктан үстерүгә зур көч сала. Монда ул бигрәк тә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Казан дәүләт университеты һәм Казан дәүләт педагогия институтының татар филологиясе кафедралары белән тыгыз хезмәттәшлектә була. Ул галим буларак та, кафедра җитәкчесе буларак та зур абруй казана. Шуңа күрә кафедра укытучыларының диссертацияләрен әзерләүдә һәм яклауда, аларның гыйльми үсешендә Казан галимнәре бик теләп катнаша.

Г.Х. Әхәтов үз шәкертләре арасыннан яшь галимнәр әзерләүгә дә зур игътибар бирә, бу киләчәктә кафедраның төп үсеш стратегиясендә чагыла. Аның тарафыннан еллар дәвамында булдырылган күркәм традицияләрне аннан соңгы кафедра мөдирләре дә саклый һәм үстерә. Моңа нисбәтән Ү.И. Гыймадиев (1981–1987), Р.Г. Сибагатов (1988–2005) һәм Р.Г. Миннеәхмәтов (2005–2010) эшчәнлекләрен искә алу урынлы. Бүген бу традицияләрне филология фәннәре докторы, профессор А.Г. Шәйхулов уңышлы дәвам итә. XX гасырның сиксәненче елларына чаклы кафедрада филология фәннәре кандидатлары, доцентлар Ә.Х. Фатихов, З.З. Заһидуллина, Р.Х. Мөхәммәтҗанов кебек танылган белгечләр эшли. Аларның педагогик осталыгын укучылары бүген дә һәрдаим искә алып тора.

Бу ярты гасырны үз эченә алган чорда Башкорт дәүләт университеты татар бүлеген тәмамлаган, татар теле һәм әдәбияты кафедрасы (2010 елдан – татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы) фатихасы белән фән өлкәсенә юл алган шәкертләре бик күп: фән докторлары О.К. Вәлитов, Р.Т. Насыйбуллин, И.М. Низамов, Ф.Х. Галиев, Р.Ф. Исламов, И.С. Насипов, фән кандидатлары Х.Х. Локманова, Л.Г. Хәбибов, Р.Р. Идрисов, М.С. Шәрипов, Л.Р. Сәгыйдуллина, Ф.Т. Бухарова, Ф.К. Фәтхетдинов, И.Ф. Гыйззәтуллина-Зарипова, Г.У. Кәлимуллина, И.С. Мансуров, И.К. Фазлетдинов, Н.У. Хәлиуллина, Л.У. Бикмаева, Д.Д. Булатова, Д.М. Хәйруллина, Л.А. Гаитова, А.Ә. Ногманова, Р.М. Миргалиев, Д.З. Мәхмүтшина, Ф.А. Гафурова, Ф.А. Абдуллина һ.б. [Актуальные, 2014, с. 14–18; Проблемы..., с. 275–282].

Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы татар тел белеме үсешенә зур өлеш кертә. Мәсәлән, Г.Х. Әхәтов татар диалектологиясе һәм лексикологиясе өлкәсендә җитди фәнни тикшеренүләр алып бара, татар диалектологиясе мәктәбенең иң күренекле вәкиле, аны үстерүче һәм татар фразеологиясе

мәктәбенә нигез салучы буларак таныла. Башкортстан татарларының җирле сөйләшләрен өйрәнүдә аның эшчәнлеге зур игътибарга лаек. Аның җитәкчелегендә Р.Ф. Нуртдинов Танып елгасы буенда таралган татар җирле сөйләшләре үзенчәлекләре буенча кандидатлык диссертациясе әзерли, монография бастырып чыгара. Л.Г. Хәбибов татар теленең антонимнары системасын тикшерә, кандидатлык диссертациясе яклый, күпсанлы монографияләр, уку әсбаплары һәм сүзлекләр бастыра, үзе дә фән кандидатлары әзерли (А.Ә. Ногманова, Р.Н. Гәрәев), профессор дәрәҗәсендә югары уку йортларында укыта. Г.Х. Әхәтовның нәтиҗәле эшчәнлеге 1981 елда республикадан күченеп киткәнгә кадәр дәвам итә.

Күренекле тел белгече филология фәннәре докторы, профессор Р.Г. Сибагатов татар синтаксисының теоретик һәм гамәли мәсьәләләрен фәнни тикшерүгә, аның көнүзәк проблемаларын ачыклауга зур өлеш кертә, үз фәнни мәктәбен булдыра. Ул тел белемендә үтә дә катлаулы проблема булган предикативлык һәм модальлек мәсьәләләрен татар теле материалында гомуми тел һәм фәлсәфи аспектларда тасвирлый. Галимнең синтаксис буенча хезмәтләренең нәтиҗәләре төрки телләрнең синтаксик төзелешен өйрәнү өчен дә нигез булды, алар чын мәгънәсендә гомуми синтаксис фәне казанышлары санала. Җирле татарларының тел үзенчәлекләре буенча саллы хезмәтләре бүген дә актуальлеген югалтмый, Башкортстан татарларының милли-мәдәни мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүгә аларзур өлеш кертә. Аның шәкертләре Р.Г. Миңнеәхмәтов, И.Ф. Гыйззәтуллина-Зарипова, Г.У. Кәлимуллина кандидатлык диссертацияләрендә һәм монографияләрендә татар синтаксисының башка катлаулы мәсьәләренә ачыклык кертәләр.

Танылган телче, филология фәннәре докторы, профессор С.Ш. Поварисов татар стилистикасын фәнни тикшерүгә, аның көнүзәк проблемаларын ачыклау белән шөгыльләнә, үз фәнни мәктәбен булдыра. Ул татар стилистикасы формалашуның зур бер чорын татар халкының мәшһүр улы Галимҗан Ибраһимовның иҗат серләрен ачыклау аша тасвирлый. Академик М.З. Зәкиев җитәкчелегендә язылган кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре дә, татар стилистикасы буенча күпсанлы хезмәтләре дә күренекле әдипнең иҗат осталыгын өйрәнү белән бәйле. Галим стилистиканы татар тел белемендә мөстәкыйль лингвистик тармак итеп үстерү юнәлешендә дә күп эшли. Аның теоретик, шул ук вакытта гамәли әһәмияткә ия фәнни хезмәтләре татар стилистикасының казанышлары булып тора. Бу хезмәтләрнең нәтиҗәләре төрки телләр стилистикасын өйрәнү өчен дә нигез булды, гомумтөрки стилистик мөмкинлекләрне ачыклауга зур йогынты ясады. Аның дистәдән артык аспирантлары мәктәпләрдә, урта һәм югары йортларында укыталар, фән белән шөгыльләнәләр. Аның җитәкчелегендә Р.Р. Гәрәева, Р.М. Миргалиев, Г.З. Габбасова, А.Ф. Камалова, З.С. Кәримова кандидатлык диссертацияләре якладылар, монографияләр һәм күпсанлы уку-укыту

әсбаплары бастырдылар [Актуальные…, 2014, с. 14–18; Актуальные..., 2016, с. 6–9; Кафедра..., с. 60–62].

А.Г. Шәйхулов – филология фәннәре докторы, күренекле тюрколог, хәзерге тел белемендә алтаистика һәм чагыштырма-тарихи теле белеме өлкәсендә иң актив эшчәнлек алып баручы галим. Мөхтәрәм гыйлемдар башкорт һәм татар халыкларының ономастиконын тасвирлауга да зур игътибар бирә. Ләкин аның фәнни эшчәнлегенең иң мөһим юнәлешләре – сүз ясалышы, лексикология һәм лексикография. Ул Идел-Урал буе кыпчак телләреннән башкорт һәм татар телләренең бер тамырлы нигезләре структурасын һәм идеографик парадигматикасын төрки, монгол, фин-угор телләре материалы белән тарихи-чагыштырма планда немец галимнәре Р. Халлинг һәм В. Вартбург тәкъдим иткән идеографик принципларга таянып эшкәртә, аларны системалаштыруда бу синоптик төркемнәрне камилләштереп, дүрт зур лексик-семантик төркемдә – Галәм (Вселенная), Кеше (Человек), Җәмгыять (Общество) һәм Танып белү (Познание) – анализлауны тәкъдим итә. Татар теле диалектларының бай лексик материалын идеографик тасвирлый.

А.Г. Шәйхуловның озак еллар алып барган тикшеренүләренең төп нәтиҗәләре «Бер тамырлы нигезләрнең сүзлек-тезаурус тәҗрибәсе (структур һәм идеографик парадигматика)» хезмәтендә урын ала. Китапта автор Урал-Идел буе кыпчак телләреннән башкорт һәм татар телләрендә бер тамырлы нигезләрнең фоносемантик структур үзенчәлекләрен тасвирлый һәм аларның парадигматикасын ареаль, төркиара һәм гомумтөрки лексика континуумында бирә. Хезмәттә тезаурус төрендәге сүзлек контекстында лексик системаларның когнитив сферадагы синопсисы һәм таксономиясе беренче тапкыр теоретик һәм методологик аспектларда характерлана. Бу сүзлек көнчыгышны өйрәнүчеләргә һәм тюркологларга тәгаенләнгән; шулай ук, ул югары уку йортлары дәреслекләрендә һәм академик грамматикаларда тарихи фонетика, фонология һәм сүз ясалышы өлкәләрен тасвирлау өчен кыйммәтле чыганак булып тора. Бу сүзлек-тезаурус хәзерге төрки лексикографиянең казанышы буларак билгеләнә [Насипов, 2016, с. 195–200].

А.Г. Шәйхуловның шәкертләре югары мәктәптә укыталар, фән белән шөгыльләнәләр. Аның җитәкчелегендә яисә катнашлыгында И.С. Насипов – докторлык, Н.У. Хәлиуллина, Л.Ү. Бикмаева, Л.А. Гаитова кандидатлык диссертацияләрен уңышлы якладылар.

Татар әдәбияты тарихын һәм аны укыту методикасын, төбәк татар әдәбиятын өйрәнүдә дә кафедраның казанышлары зур. Бу яктан әдәбиятчы галимнәр Ү.И. Гыймадиев, Ә.З. Нигъмәтуллин, К.С. Дәүләтшин, С.Г. Хафизов, М.С. Шәрипов, Р.Р. Идрисов һ.б.ның эшчәнлеген билгеләп үтәргә кирәк. Фольклорчы галимнәр Р.М. Мөхәмәтҗанов һәм И.Ф. Фазлетдиновларның Башкортстан татарларының халык авыз иҗатын өйрәнү буенча эшчәнлеге аерым игътибарга лаек.

Бүген М.Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университетының Филологик белем бирү һәм мәдәниятара багланышлар

институтындагы татар теле һәм әдәбияты кафедрасы Башкортстанда татаристика үзәкләре арасында иң актив эшчәнлек алып баручы булып санала. 1990 елда университетның филология факультетында татар теле һәм әдәбияты укытучыларын әзерли башлыйлар, ә татар теле һәм әдәбияты кафедрасы 1991 елда ачыла. Аның беренче мөдире итеп филология фәннәре кандидаты, доцент Л.Г. Хәбибов сайлана. Соңрак кафедра белән филология фәннәре кандидаты, профессор С.Г. Сафуанов (1996–2001), филология фәннәре кандидатлары, доцентлар С.Г. Хафизов (2002–2005) һәм Ф.А. Гафурова (2005–2012) җитәкчелек итәләр. Бүген кафедра мөдире вазифасын филология фәннәре докторы, профессор И.С. Насипов башкара. Кафедра беренче көннәрдән үк Г. Ибрагимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан дәүләт педагогика университеты һәм Казан дәүләт университеты белән актив хезмәттәшлектә яши. Казан (Идел буе) федераль университеты оешкач, бу уку йорты белән үзара элемтәләр тагын да ныгып китә.

2012 елда кафедра үсешендә яңа бер адым ясала – кафедра каршында Башкортстан Республикасының полиэтник киңлегендә туган (татар) теле, әдәбияты һәм мәдәнияте яшәешен һәм үсешен өйрәнү фәнни-тикшерену лабораториясе ачылды. Лабраториянең төп максаты – республикада яшәүче татарларның рухи мәдәниятен һәм этнокультур үсешен полимәдәни киңлектә киң яссылыкта фәнни өйрәнү. Дөрес, куелган бурычларның барысына да тиешле дәрәҗәдә ирешеп булмаса да, лаборатория үзенең эшен туктатмый. Мәсәлән, анда Башкортстан мәктәпләре өчен татар теленнән уку кулланмалары һәм укытучыларга татар телен укыту буенча методик әсбаплар төзеп бастырыла. Милли мәктәпләрнең 1–9 сыйныфлары өчен татар теленнән уку кулланмалары һәм укытучыларга татар телен укыту буенча методик әсәбаплар, үрнәк программалар нәшер ителде инде. Бүген рус мәктәпләрендәге 1–9 сыйныфлар өчен татар теленнән уку кулланмалары төзү эше бара. Бу эшне вуз галимнәре белән берлектә республика мәктәпләрендә иҗади эшләүче тәҗрибәле татар теле һәм әдәбияты укытучылары башкара.

2016 елда кафедра каршында Казан (Идел буе) федераль университеты Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара бәйләнешлар институтының Габдулла Тукай исемендәге милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе Каюм Насыйри институтының белем бирү һәм мәдәният үзәге ачылды. Бу үзәкне Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы кыйммәтле заманча техник онлайн-элемтә чаралары белән җиһазлады. Мондый үзәкләр Астана, Бишкәк, Екатеринбург, Петербург һәм Мәскәү шәһәрләрендә ачылган иде. Каюм Насыйри институты үзәкләренең төп максаты – Россиядә һәм чит илләрдә татар һәм рус телләрен популярлаштыру, тарату һәм аларны өйрәнүне оештыру. Максатка ярашлы рәвештә, Каюм Насыйри институтының белем бирү һәм мәдәният үзәге Уфада даими рәвештә теләге булган һәр кешегә татар теленә өйрәтү дәресләре бирә, төрле фәнни-методик чаралар уздыруда катнаша, КФУның күре-

некле професорлары М. Акмулла исемендәге БДПУ студентларына онлайн-лекцияләр укый. Ике уку йортында оештырылган чараларны онлайн халәттә күзәтеп бару мөмкинлеге бар. 2017–2019 елларда кафедра «Телләргә өйрәтү методикасын камилләштерү: алдынгы тәҗрибә уртаклашу мәйданы» халыкара фәнни-методик онлайн семинарларда катнашты. Семинарларны КФУ белән берлектә Л.Н. Гумилев исемендәге Евразия милли университеты (Астана, Казакъстан) һәм Эгей университеты (Төркия) оештырганнар иде.

Казан (Идел буе) федераль университеты һәм аның Алабуга институты татар филологиясе кафедралары һәм М. Акмулла исемендәге БДПУның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы даими рәвештә уку-укыту һәм фәнни-методик тәҗрибә белән уртаклашып торалар, фәнни-гамәли конференцияләрдә, гыйльми форумнарда катнашалар. Бигрәк тә М. Акмулла исемендәге БДПУның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы укытучыларының гыйльми дәрәҗәләрен күтәрүдә аларның катнашы зур [Актуальные..., 2016, с. 6–9; Насипов, 2016, с. 179–185]. Бу яктан Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты да зур ярдәм күрсәтә. Мәсәлән, кафедра укытучылары И.С. Насипов, Ф.А. Гафурова, А.Ә. Ногманова төрле елларда институтта фәнни әзерлек узып, докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре якладылар. Институт җитәкчелеге һәм галимнәре ярдәме белән кафедра фәнни-гамәли конференцияләр уздыра [Актуальные..., 2016, с. 6–9]. Институт кафедраның уку-укыту процессын тиешле гыйльми әдәбият, фәнни-методик әсбаплар, белешмәләр һәм сүзлекләр белән тәэмин итүдә дә зур ярдәм күрсәтә.

Кафедра галимнәренең тикшеренүләре татар лексикологиясе, лингвокультурологиясе, стилистикасы һәм тел бәйләнешләре, шулай ук татар әдәбияты тарихы, төбәк татар әдәбияты мәсьәләләрен өйрәнүгә багышланган. Татар теленең сүз тамырларын гомумтюркологик аспектта тикшерү аерым игътибарга лаек. Кафедра Башкортстан мәктәпләре өчен дәреслекләр һәм методик әсбаплар төзеп бастыру, укыту-методик тәэмин итү үзәге булып та санала.

Башкортстанда татаристика үзәге буларак эшләп килүче кафедраларның өченчесе – Башкорт дәүләт университетының Стәрлетамак филиалы башкорт һәм төрки филологиясе факультетының татар һәм чуваш филологиясе кафедрасы. Бу кафедра 1997 елда Стәрлетамак дәүләт педагогия институтының филология факультетында татар-рус (1993 елдан ачылган) һәм чуваш-рус (1994 елда ачылган) бүлекләрендә туган тел укытучылары әзерләүдә уку-укыту һәм гыйльми-методик эшне оештыру максатында ачыла. Кафедрага 1997–2012 елларда И.С. Насипов җитәкчелек итә, бүген мөдир вазифасын И.С. Мансуров башкара. Кафедра татар филологиясе буенча педагогларны Башкортстандагы белгечләреннән туплау юлын сайлаcа да, аларның гыйльми дәрәҗәләрен үстерүдә һәм уку-укыту процессын уку-методик әсбаплар белән тәэмин итүдә беренче көннәрдән үк Татарстан Республикасы фәнни учреждениеләре һәм югары уку йортлары мөмкинлегенә

таянып эш итә. Кафедра укытучылары кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен Г. Ибрагимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты һәм Башкорт дәүләт университеты гыйльми советларында якладылар, әмма аларга Казан дәүләт педагогика университеты һәм Казан дәүләт университеты галимнәренең дә ярдәме зур булды. Мәсәлән, Ф.Т. Бухарова (2002) һәм И.С. Мансуров (2005) диссертацияләренең фәнни юнәлешләрен билгеләүдә КДУ профессоры Х.Ю. Миннегулов катнаша, аның урынлы киңәшләре үз нәтиҗәләрен бирә. И.С. Насиповның кандидатлык (1994) һәм докторлык (2010) диссертацияләренә оппонентлар буларак КДУ профессорлары В.Х. Хаков һәм А.Ә. Әмирова, Казан дәүләт педагогика университеты профессоры К.З. Зиннәтуллина чыгыш ясыйлар. Рецензияләүче төп оешмалар буларак Алабуга дәүләт педагогика университеты һәм Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты катнаша. Н.Ә. Мөкимованың кандидатлык диссертациясен рецензияләүче төп оешма да – КФУның Алабуга институты [Кафедра..., 2008; Насипов, 2016].

Кафедра татар филологиясен үстерүгә зур өлеш кертә. Аның галимнәренең тикшеренүләре татар лексикологиясе, лингвокультурологиясе, стилистикасы һәм тел бәйләнышлары, шулай ук борынгы татар әдәбияты, чит илдә татар әдәбияты һәм төбәк татар әдәбияты мәсьәләләрен өйрәнүгә багышланган.

Башкортстанда татаристика үзәге буларак эшләп килгән кафедраларның дүртенчесе – Башкорт дәүләт университетының Бөре филиалы филология һәм мәдәниятара багланышлар факультетының башкорт, татар һәм мари филологиясе кафедрасы. Бу кафедра 1998 елда филология факультетында рус-мари (1993 елдан ачылган), рус-татар (1995 елдан ачылган) һәм рус-башкорт (1996 елда ачылган) бүлекләрендә туган тел укытучылары әзерләү максатында оештырыла. Башта ул төрки һәм фин-угор филологиясе кафедрасы дип атала. Бу кафедрага башлап филология фәннәре докторы Р.Г. Әхмәтҗанов җитәкчелек итә (1998–2001). Аннан соң филология фәннәре кандидатлары, доцентлар В.В. Ганиев (2001–2005) һәм С.И. Апсаттаров (2005–2009) мөдир була. 2009 елда кафедра, башкорт филологиясе кафедрасы белән берләшеп, башкорт, татар һәм мари филологиясе кафедрасы дип атала башлый. Мөдир итеп филология фәннәре кандидаты, доцент А.А. Фаткуллин сайлана (2009–2014). 2014 елдан ул факультеттагы бердәнбер филология кафедрасына кушыла. Бу вакыттан башлап, кызганычка каршы, татар һәм мари бүлекләре студентлар кабул итүне туктаттылар.

Бөредә кафедрада эшләүче татар филологиясе укытучыларының фәнни дәрәҗәсен үстерүгә Казан (Идел буе) федераль университеты зур өлеш кертә. Д.М. Хәйруллина (2005) һәм Ф.В. Юнысова (2010) кандидатлык диссертацияләрен КФУның филология һәм сәнгать институтының диссертацион советында яклыйлар. Татар бүлегенең эшчәнлеген фәнни-методик тәэмин итүгә КФУ профессоры, педагогия фәннәре докторы Ф.Ф. Харисов зур көч салды.

Шулай итеп, Башкортстан Республикасында югары уку йотларында татаристика үзәкләре булып татар филологиясе кафедралары тора, ә аларны үстерүдә Татарстан Республикасы фәнни учреждениеләре һәм югары уку йортлары зур роль уйный.

**Әдәбият**

Актуальные проблемы современной татарской филологии: Сборник статей Всероссийской научно-практической конференции (г. Уфа, 12 декабря 2014 г.) / отв.ред. И.Ф. Зарипова. Уфа: РИЦ БашГУ, 2014. 420 с.

Актуальные проблемы изучения и преподавания татарской филологии: материалы всероссийской научно-практической конференции, посвященной 25-летию кафедры татарского языка и литературы (г.Уфа, 21 октября 2016 г.) / отв. ред. И.С. Насипов, зам. отв. ред. Н.У. Халиуллина. Уфа: Изд-во БГПУ, 2016. С. 6–9.

Кафедра татарской и чувашской филологии: Очерк истории / сост. И.С. Насипов, И.С. Мансуров. Стерлитамак: Стерлитамак. гос. пед. академия им. Зайнаб Биишевой, 2008. 177 с.

*Насипов И.С.* Роль национальных отделений вузов в этносоциальном образовательном пространстве // Этносоциальное образовательное пространство в современном мире. Материалы международной научно-практической конференции, посвященной 50-летию Стерлитамакской государственной педагогической академии и 65-летию кафедры педагогики (Республика Башкортостан, г. Стерлитамак, 15 мая 2005 г.). Стерлитамак: СГПА, 2005. С. 275–278.

*Насипов И.С.* Кафедра татарского языка и литературы – ведущий научно-педагогический центр по татарской филологии в Республики Башкортостан // Система непрерывного образования: школа – педколледж – вуз: Материалы XVI Региональной научно-практической кеонференции, посвященной юбилеям научных школ Института филологического образования и межкультурных коммуникаций. Уфа: Изд-во БГПУ, 2016. С. 179–185.

*Насипов И.С.* Роль Казанского университета в развитии центров татаристики в Башкортостане // Мировая тюркология и Казанский университет: материалы Международной научно-практической конференции (Казань, 26–28 апреля 2018 г.) / Научн.ред. Р.Р. Замалетдинов. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2018. С. 275–282.

Проблемы изучения и преподавания тюркской филологии: преемственность поколений: Материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 80-летию академика М.З.Закиева и 10-летию кафедры татарской и чувашской филологии, Россия, Республика Башкортостан, г. Стерлитамак, 18–20 сентября 2008 г. / отв.ред. М.В. Зайнуллин. Стерлитамак: СГПА, 2008. 380 с.

***Насипов Илшат Сәхиятулла улы,***
*М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университеты*
*Филологик белем бирү һәм мәдәниятара багланышлар институтының*
*татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире*
*nasipov2004@rambler.ru*

УДК 371.387

*Н.В. Герасимова*

# ТАТАРСТАН РАЙОННАРЫ МУЗЕЙЛАРЫНЫҢ СӘНГАТЬ ТУПЛАМАЛАРЫН БУЛДЫРУДА КОЛЛЕКЦИОНЕРЛАРНЫҢ РОЛЕ
## (Чистай һәм Тәтеш туган якны өйрәнү музейлары үрнәгендә)

В статье раскрывается прогрессивная роль частного коллекционирования в формировании художественных собраний районных музеев Татарстана, созданных в 1919–1920-м годах.

**Ключевые слова:** музейное строительство, собирательская деятельность, национализация, государственные закупки произведений искусства, Отдел по делам музеев и охраны памятников искусства, старины и природы, Народный комиссариат просвещения ТАССР.

This article reveals the progressive role of private collecting in the formation of art collections of regional museums of Tatarstan, created in 1919–1920's.

**Keywords:** museum construction, collecting activities, nationalization, government procurement of works of art, Department of affairs of the museums and protection of monuments of art, old times and nature National education commissariat of TASSR.

1917 елдан соң совет Россиясенең музей сәясәте тулысынча дәүләт карамагына күчә. Шул вакыттан музей төзелешенең бурычлары һәм хокукый күрсәтмәләре эшләнә. Шул исәптән, яңа төр музейлар булдыру максатыннан сәнгать коллекцияләре формалаштыру эше дә бердәм үзәктән координацияләнә. Тасвирый сәнгать өлкәсендә РСФСР Мәгариф халык комиссариатының Сынлы сәнгать бүлеге алдынгы рәссамнар һәм сәнгать белгечләре белән берлектә бөтен ил буенча рәсем сәнгате музейлары челтәрен төзү концепциясен эшли. Әлеге музейлар борынгы рус икона язу сәнгатеннән алып авангард әсәрләргә кадәр илебездәге сынлы сәнгать (кайбер вариантларда – дөнья сәнгате) үсеше тарихын күрсәтергә тиеш булдылар, бу – элек провинция музейларына кагылмаган хәзерге заман Россия сәнгате әсәрләре коллекцияләрен формалаштыруга бер сәбәп булды. Бу процесслар 1920 елларда музей эше актив үсеп киткән Казан губернасында да (ТАССР да) бара, Казандагы эшләп килгән музейларның сәнгать коллекцияләре киңәя, өяз шәһәрләрендә сәнгать бүлекләре булган яңа музейлар челтәре төзелә: Козьмодемьянск, Чистай, Тәтеш, Алабуга һәм башка шәһәрләрдә. Ул заманда музейларның сәнгать коллекцияләрен формалаштыруда мөһим чыганакларның берсен шәхси тупламалар тәшкил итә. Аларны я хуҗаларыннан сатып алалар, я национализациялиләр. Музей сәнгать коллекцияләрен булдыру процессында А.Ф. Мантель һәм Е.Д. Мясников тупламалары аеруча зур роль уйный.

Александр Фердинандович Мантель (1880–1935) – рәссам, күргәзмәләр оештыручы, сәнгать белгече, нәшир, Россиядә сәнгать истәлекләрен һәм борынгылыкны яклау һәм саклау, архитектор-рәссамнар җәмгыятьләре әгъзасы булган. Аның коллекционер буларак эшчәнлеге 1900 еллар ахыры – 1910 елларда киң җәелә һәм «Сәнгать дөньясы» («Мир искусства») берләшмәсе осталарының иҗатын җыюга багышлана. Е.П. Ключевский бәяләвенчә: «Казанның эре династияләре сәнгать тупламалары фонында А.Ф. Мантель коллекциясе заманча сәнгать процессына йөз тотуы, коллекция җыю предметына (күбесенчә кече формалы графика), әсәрләрнең гомуми сәнгать дәрәҗәсенең стилистик кыйммәте белән аерылып тора» [Ключевская, с. 126]. А.Ф. Мантель коллекциясен формалаштыру һәм аның язмышы мәсьәләләренә багышланган хезмәтләр шактый. Арада иң тулысы О.Л. Улемнова мәкаләсе [Улемнова, 2019].

Революция чорында тупламаны саклап калып булмаячагын аңлап (1917–1918 еллар чигендә имениены талаганда коллекциянең бер өлеше юкка чыга) [Улемнова, 2013], А.Ф. Мантель 1919 елда ук Казан губерна музееның «Сәнгать дөньясы» берләшмәсе рәссамнарының әсәрләрен сатып алу тәкъдименә риза була. Бу турыда мәгълүматлар «Казан губерна музееның нәкыш һәм гамәли сәнгать бүлеге буенча 1919 елның 1 февраленнән алып 1920 елның 1 гыйнварына кадәрге чорга кыскача хисап»та саклаңган [ТР ДА, Ф. Р-2021, Оп. 1, 7 с.б., б. 14]. Музей А.Ф. Мантельдән Н.К. Рерих, И.Я. Билибин, Б.М. Кустодиев, А.Ф. Гауша, П.И. Львов, А.Н. Бенуа, Д.И. Митрохин, Б.И. Анфельд һ.б.ның 4 нәкыш һәм 17 графикасын сатып алган. Бу – музейда әлеге төркем рәссамнары әсәрләре коллекциясенең формалаша башлавы турында сөйли.

О.Л. Улемнованың тикшеренүләре нәтиҗәсендә [Улемнова, 2019, с. 392–396] А.Ф. Мантель коллекциясендәге әсәрләрнең тагын ике музей фондларын тулыландыру өчен сатып алынуы ачыкланды. Әйтик, 1919 елда Мантель ТатНаркомпрос каршындагы музейлар һәм борынгы һәйкәлләрне саклау эшләре буенча губерна бүлеге агенты була һәм Тәтештә туган як музее төзү процессына актив кушыла (ТР ДА, Ф.Р-3682, Оп.1, 2078 с.б., б.). Музейлар эшләре бүлеге шушы музей өчен Мантель коллекциясенең бер өлешен сатып алырга мөмкинлек таба [Вишневский, с. 79]. О.Л. Улемнова сүзләренә караганда, «1919 елда Тәтеш музееның сәнгать бүлеге составында А.Ф. Мантель коллекциясеннән», А.Ф. Гауш, Б.М. Кустодиев, Е.Е. Лансер, Г.К. Лукомский, П.И. Львов, Д.И. Митрохин, Г.И. Нарбут, А.П. Остроумова-Лебедева, Н.К. Рерих кебек рәссамнарның «23 әсәре тәкъдим ителә, шуларның бишесе – нәкыш, унҗидесе – графика һәм бер гравюра» [Улемнова, 2019, с. 395]. Губерна бүлеге хезмәткәре П.Е Корнилов, Тәтеш музееның сәнгать коллекциясен сыйфатлап, әлеге әсәрләрнең тупланманың төзек һәм системалы өлешен тәшкил итүен билгеләп үтә, аларның Сәнгать дөньясы төркеме иҗатын характерлавын ассызыклый [Корнилов, с. 20].

Коллекциясен А.Ф. Мантель тупламасы әсәрләре белән тулыландырган соңгы музей – 1919 елның 7 сентябрендә ачылган Козьмодемьянск туган якны өйрәнү музее. «Козьмодемьянск туган якны өйрәнү музееның эше турында хисапта (1919 елның 7 сентябреннән алып 1920 елның 4 февраленә кадәр)», Тәтештә А.Ф. Мантельга музейга тапшырган әсәрләре өчен 40 мең сум акча түләнүен хәбәр итә [10, с. 17]. О.Л. Улемнова ачыклаганча, музей өчен 13 әсәр сатып алынган: Ю.С. Жуковский, С.Ф. Колесникова, А.Н. Шильдер, А.М. Кокорев һәм Г.К. Лукомский, Д.И. Митрохина, Г.И. Нарбута һәм М.Я. Чемберс-Билибина картиналары, алар хәзерге заман сәнгате коллекциясенең нигезен тәшкил итә.

Безне кызыксындырган коллекционерларның икенчесе – Ефим Дмитриевич Мясников – галимнәр игътибарыннан читтә калган шәхес. Чистай музей-тыюлыгы фондларында аның 1867 елда тууы, Чистайда 2 нче гильдия сәүдәгәр булуы, мануфактура сәүдәсе, икмәк сатып алу белән шөгыльләнүе, Чистайда берничә йорт тотуы, сәүдә эшләре буенча Мәскәүдә яшәве турында мәгълүмат саклanган [Чистай шәһәре тарихы музее (ТР ДБМУ «Чистай дәүләт тарих-архитектура һәм әдәби музей-тыюлыгы» документаль фонды)]. Күрәсең, Мясников Чистай шәһәре Иҗтимагый җыелышы әгъзасы булган. Сәүдәгәрнең бу җыелышта 1905 елның 17 октябрь Манифесты уңаеннан ясалган чыгышының текстын үз эченә алган (Казанда басылган) брошюра сакланган (4). Бу аның Чистайны ихлас яратуын һәм шәһәр үсеше өчен кулыннан килгәннең барысын да эшләргә тырышуын дәлилли. Бу Чистайда сәнгать музеен ачарга омтылуда да чагылыш таба. Е.Д. Мясников куелган максатны гамәлгә ашыруда барган юлыннан тайпылмый: Казан музей хәбәрчесе журналы 1920 елда «гражданин Мясниковның, Мәскәүдә яшәгәндә дә, ел саен Мәскәү рәссамнары күргәзмәләрендә булачак Чистай музее өчен картиналар сатып алуын хәбәр итә. Шул рәвешле ул яңа рус рәссамнары картиналарының кыйммәтле җыелмасын булдыра» [Хроника, б. 75). Архив документларыннан күренгәнчә, коллекциянең бер өлеше революциягә кадәр үк сәүдәгәрнең Чистайдагы йортына күчерелгән, революциядән соң музейлар эшләре буенча Казан бүлегеннән охранный грамота алган. Ихтимал, ул тупланманың бу өлешен картина галереясына әйләндерү шарты белән бирелгән (ТР ДА ф. Р-3682, оп. 1, 491 с.б., б. 128 об.]. Бу җыелышның язмышы үкенечле булып чыга. Инде 1923 елда ук Казан музейлар эшләре бүлеге, коллекциянең Чистайдагы төрле учреждениеләренә тапшырылуы турындагы имеш-мимешләрне таратуны таләп итә, яки аны нинди учреждениеләргә бүлеп бирүләре хакында хәбәр итүләрен сорый. Без бу сорауга җавап таба алмадык. Коллекциянең шактый өлеше югалган, икенче өлеше Чистай туган якны өйрәнү музеена тапшырылган. Моны музей турындагы Доклад язмасы да раслый: «Чистай сәүдәгәрләренең элек конфискацияләнгән картиналары (башлыча сәүдәгәр Мясников коллекциясеннән) җирле хакимият тарафыннан музейга тапшырылды» (Чистай му-

зей-тыюлыгының документаль фонды). Әмма 1929 елда Казан музей бүлеге Д. Бурлюкның «Пейзаж с домом» картинасын Чистай музеендагы Мясников тупламасыннан Татар республикасының үзәк музеена тапшыруны таләп итә. Алар моны Үзәкнең Мясников коллекциясен тулаем Татар республикасының Үзәк музеенда урнаштырырга карар итүе белән аңлаталар [ТР ДА ф. Р-3682, оп.1, 1539 с.б., б.123].

Коллекциянең шактый өлеше сәүдәгәрнең Мәскәүдәге йортында сакланган һәм дәүләт тарафыннан национализацияләнгән яки сатып алынган булса кирәк, әмма элеккеге хуҗаның теләген искә алып, 70 картина Дәүләт музей фонды аша Татар республикасы үзәк музеена һәм Чистай шәһәренең туган якны өйрәнү музеена тапшырылган (ТР ДА ф. Р-3682, оп. 1, 14 с.б., б. 1–2]. Өстәвенә тапшыру актында нинди картиналарның кайсы музейга билгеләнүе дә күрсәтелә. Әлеге факт Бөтенроссия музейлар эшләре буенча коллегия хезмәткәрләренең абруен күтәрә: алар хәтта сәнгать коллекцияләрен национализацияләү сәясәте үткәрелгәндә дә дә, тупланмаларның язмышына мөнәсәбәттә, элеккеге хуҗаларның теләкләрен исәпкә алып эш иткәннәр.

1920 елда Дәүләт музейлар фонды, әлеге исемлектән чыгып, Чистай шәһәренең туган якны өйрәнү музеена хәзерге заман сәнгатенә караган 60 картина тапшырган. Алар арасында И.И. Машковның «Чәчәкләр вазада» («Цветы в вазе»), «Натюрморт. Чәчәкләр» («Натюрморт. Цветы») һәм «Диңгез яры» («Берег моря»); П.П. Кончаловскийның «Бака гөлләре» («Бегонии»); В.В. Рождественскийның «Трактир савыт-сабасы» («Трактирная посуда»), «Пейзаж»; Р.Р. Фалькның «Кызылдан киенгән кыз» («Девушка в красном»); Н.В. Мещеринның «Кышкы айлы төн» («Зимня лунная ночь») һәм «Аланлык» («Поляна»); В.А. Гальвичның «Алла Анасы серафималар белән» («Богоматерь с серафимами») кебек эшләре аерылып тора [13, д. 14, л. 1–2]. Әмма, күрәсең, Чистай музеенда коллекцияләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү мөмкинлеге булмаганга күрә, әлеге әсәрләрне ТРҮМга тапшыру турында карар кабул ителә, анда алар хәзерге заман сәнгатенең туып кына килүче коллекциясен тулыландырырга ярдәм итә, аны «Зәңгәр роза» («Голубая роза»), «Бубен валеты» («Бубновый валет»), «Ишәк койрыгы» («Ослиный хвост») кебек сәнгать берләшмәләре әсәрләре белән баета.

Шулай итеп, хәзерге заман ватаныбыз сәнгатенең төп үсеш юнәлешләрен чагылдырган әлеге коллекцияләр ТАССРның түбәндәге музейларына башлангыч бирә: Казанда ТРҮМ, Тәтеш, Чистай һәм Козьмодемьянск (1920 елдан Мари АССР составында) туган якны өйрәнү музейлары. Кызганычка каршы, 1920–1930 еллардагы музей коллекцияләрен төрлечә үзгәртеп корулар нәтиҗәсендә күп кенә әсәрләр юкка чыга. Сакланганнары башта – Татарстан АССР Үзәк музеена, ә Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать музее ачылганнан соң, аның фондларына тапшырыла һәм музей тупламаларының иң кыйммәтле һәм кирәкле өлешләренең берсен тәшкил итә.

**Әдәбият**

*Вишневский Б.* По музеям казанского края // Казанский музейный вестник. 1920. № 7–8. С. 67–82.

*Ключевская Е.П.* А.Ф. Мантель и его коллекция (забытые страницы истории художественной жизни Казани начала XX века) // Музей в системе ценностей евразийской культуры. Материалы Всероссийской научной конференции 25–28 сентября 2000 г. Казань: Школа, 2000. С. 123–126.

*Корнилов П.Е.* Художественное собрание Тетюшского музея (Краткий обзор) // Записки Тетюшского музея. 1927. № 1. С. 19–20.

*Мясников Е.Д.* Речь, произнесенная в общественном собрании 21 ноября 1905 г.» Г. Чистополь. По поводу Манифеста 17 октября 1905 года. Казань: Типо-лит. В.М. Ключникова, 1905. 24 с.

*Улемнова О.Л* Художественная коллекция А.Ф. Мантеля в музеях Поволжья: опыт реконструкции // Обсерватория культуры. 2019. № 16 (4). С. 386-405. https://doi.org/10.25281/2072-3156-2019-16-4-386-405

*Улемнова О.Л.* Александр Мантель – «бескорыстный пропагандист чистого искусства» // «Мир искусства». Живопись. Рисунок, Гравюра. Скульптура. Издания. К 115-летию объединения. Каталог выставки. Казань: Заман, 2013. С. 30–49.

7. Хроника // Казанский музейный вестник. 1920. № 3–4. С. 75.

***Герасимова Наталья В.,***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 7.07

***Р.Р. Солтанова***

# ХАКЫЙКАТЬ ҺӘМ ТОРМЫШ ШИГЪРИЯТЕ: РӘССАМ ЗӨФӘР ГИМАЕВ ПОРТРЕТЫНА ШТРИХЛАР

В статье показана эволюция творчества живописца, народного художника Республики Татарстан, заслуженного художника Российской Федерации Зуфара Фаатовича Гимаева, выявлены стилистические особенности изобразительного языка в контексте развития искусства Татарстана в советский и постсоветский периоды.

**Ключевые слова:** живопись, портрет, тематическая картина, национальное своеобразие.

The article shows the evolution of the work of the painter, people's artist of the Republic of Tatarstan, Honored Artist of the Russian Federation Zufar Faatovich Gimaev, reveals the stylistic features of the visual language in the context of the development of Tatarstan art in the Soviet and post-Soviet periods.

**Keywords:** painting, portrait, thematic picture, national identity.

Зөфәр Гимаев һичшиксез бәхетле йолдызлык астында туган: чын рәссамнарга гына хас зирәк акыл, сизгер күңел, тумыштан бирелгән сәләт, намусы кушканча эшләү, үзеңнең рухи-әхлакый бурычыңны аңлау – болар барысы да аның сәнгатенең куәсе. Сәнгатьне талантлы, көчле, үзенчәлекле шәхесләр тудыра. Бу – күптән билгеле хакыйкать. Республикабызның мәдәни тормышында рәссам Зөфәр Гимаев нәкъ менә шундыйлардан санала. Кемнәр аны яхшы белә, рәссамның кеше хәленә керә белүчән, иҗатка башы-аягы белән чумып, сәнгатьнең киләчәген ихлас кайгыртып, аның өчен борчылып яшәүче кеше икәнен тирән аңлый. Тагын шуңа ару-талуны белмичә эшләвен, уй-ниятләренең масштаблылыгын һәм шуларны үҗәтлек белән гамәлгә ашыруын да өстәсәң, рәссамның портреты тагы да ачыграк төсмер ала.

Бала вакытта Зөфәр еш авырый, чирләшкә булып үсә. Күпчелек малайлар кебек, аның зур абыйсы бокс белән мавыга, ә ул йога белән шөгыльләнә башлый, китаптан укып өйрәнеп, көченнән килгән күнегүләрне ясый. Аннан акробатикага кереп китә. Казан сәнгать мәктәбенең III курсында укыганда (1969), акробатика буенча Россия чемпионы була. Зөфәр ирекле күнегүләрне аеруча ярата, чөнки аларны башкарганда, тән-гәүдә сыгылмалыгы аша, кешенең эчке халәтен, хис-тойгыларын күрсәтеп була. Ә пантомима белән шөгыльләнү гади генә ым, ишарә, тән хәрәкәтендә кешенең эчке дөньясындагы тирән кичерешләрнең бихисап төсмерләрен күрергә өйрәтә. Рәссам фикеренчә, нәкъ менә спорт белән шөгыльләнү аңарда ихтыяр көче, максатка ирешүчәнлек, башлаган эшне ахырына җиткерү кебек сыйфатлар тәрбияли дә.

Ул һәрвакыт, теләсә-нинди шартларда да намуслы, принципиаль, иптәшлек хисе бик көчле кеше булып кала. Бик күп эшли, күргәзмәләрдә катнаша, ирешелгәнгә канәгатьләнеп, ярты юлда туктап калуны белми. Гимаев иҗатында һәрчак эзләнү рухын тоясың. Мин автор һәм аның шигъри темпераментлы нәкыше арасында тере бәйләнеш күрәм. Гимаев колоритка, яктылык-һава мохитен бирүгә зур игътибар бирә. Аның картиналарында һәрвакыт хисси эчке мәгънә яшеренгән, аны беренче караштан ук күреп тә, аңлап та булмый. Бу серле йозакны ачу сәләте бөтен кешегә дә бирелмәгән...

Аны сәнгатьтә билгеле бер мәктәп вәкиле, аерым агым яисә юнәлеш тарафдары дип тә булмый. «Иҗат – тормышның күчермәсе дә, фоторәсем дә түгел», – дип кабатларга ярата рәссам. – Теләсә-кайсы классик – минем остазым. Н. Фешинны, Б. Урманчены, И. Шишкинны яратам. Миңа төрле юнәлешләрдә иҗат итүче рәссамнар – импрессионистлар да, постимпрессионистлар да, экспрессионистлар да якын. Ниндидер бер юнәлеш түгел, ә сәнгать булган бөтен нәрсә үз».

Иҗат белән шөгыльләнә башлаганда ук ул уңышка ирешүнең төп кагыйдәсен үзләштерә – беркайчан беркемне кабатламкаска, сурәтләгәннәреңне күңел, йөрәк аша үткәрергә. Гимаев карашынча, рәссамның бурычы – әйберләр дөньясына, әйләнә-тирә мохиткә, табигатькә җан өрү. Казан сәнгать мәктәбендә укыган чордан ук ул Харис Якуповның сүзләрен мәңгегә хәтерендә калдыра. Башлаган эшне һәрвакыт ахырына җиткерергә, авырлыклар алдында баш имәскә, бер баскыч булса да югары күтәрелергә тырышырга кирәк, дияргә ярата остазы. Ул үзенең укытучыларын тирән хөрмәт белән искә ала. Училищеда, буяуларны курыкмыйча мул кулланып, ачык һәм матур итеп ясарга өйрәткән Р.А. Төхвәтуллин кул астында шөгыльләнергә ярата. Б.И. Майоров картиналарында аны зур колористика культурасы, төрле планда иҗат итәргә яраткан лирик рәссамның бербөтенлеге җәлеп итә. Беренче курста укыганда ук Т.А. Зуева Балтыйк буе, Көнбатыш рәссамнарының казанышлары турында мавыктыргыч итеп сөйләп, алга таба үсү өчен стимул тудыра. Педагогларының киңәшен истә тотып, ул үткәннең бөек осталарыннан бик тырышып өйрәнә, музейларда, күргәзмәләрдә еш була. Ялларда, бер-ике генә көнгә булса да Мәскәүгә, Ленинградка, «Зур Идел» зона күргәзмәләренә барырга тырыша. Зөфәр күп укый, рәссамнар турында китаплар, альбомнар сатып алырга ярата. Студент вакытта ук аны, бәхәсләргә кермичә, дәшми-тынмый гына эшләргә яратканы өчен, философ дип йөрткәннәр аны.

Казан сәнгать училиәесын ул В.И. Ленинның чираттагы юбилее уздырылган1970 елда тәмамлый. Бу теманы студентлар да читләтеп үтә алмый. Гимаевның диплом эше Алафузов заводы эшчеләре чыгышына багышлана («В. Ульянов эшчеләр арасында», 1887). Картинаның нигезенә 1887 елда Казанда профсоюзлар эшчеләрнең хезмәт шартларын яхшыртуны таләп итеп чыкканнан соң булган вакыйгалар ята. Диплом эшендә куелган катлаулы пластика һәм образлар белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү өчен, Гимаев бик зур әзерлек эше алып

бара: берничә тапкыр әтисе янында тәмәке фабрикасында була, үз геройларының образларын эшчеләрдән алып яза. Диплом эше эскизының аклы-каралы фоторәсеме сакланган. Вакыйгаларның эпик киңлеген бирү өчен, рәссам туры почмаклы формат сайлаган. Вакыйгалар кыш башында фабрика бинасы каршындагы мәйданда бара. Еракта Казан кремле күренә. Дулкынланган эшчеләр төркеме калкулыклы урынга басып сөйләүче ораторны тыңлый. Яшь Ульянов та шулар арасында. Персонажларның тышкы кыяфәте, характерлы позалар үтә төгәл һәм дөрес итеп сурәтләнгән...

Яшь рәссамның эзләнү, кызыклы нәтиҗәләргә ирешү омтылышын ничек сакларга, үз фикерен ничек сүндермәскә, хис-тойгыларын – тупасландырмаска?! И.Е. Репин исем. рәсем сәнгате, скульптура һәм архитектура институтында совет заманындагы иң абруйлы осталарның берсе булган Е.Е. Моисеенко үзе аңа профессор А.Д. Зайцевка барырга киңәш итә. Соңгысы берәүне дә кыерсытмый, һәр шәкертенә үз йөзен булдырырга ярдәм итә. Ул Гимаев өчен остаз гына булып калмый, якын дуска да әверелә. Рәссамнар берлегенә керергә рекомендация бирә, җәмәгать эше белән шөгыльләнергә куша. Институтны тәмамлаганнан соң (1980), З. Гимаев идарәнең актив әгъзасына әйләнә: башта – рәис урынбасары, ә 2008 елдан Татарстанның Рәссамнар берлеге рәисе була.

«Репинка»ны тәмамлаганнан соң, Гимаев үзен төрле жанрларда сынап карый. Институтны бергә тәмамлаган яшьтәш рәссамнар (Ф. Якупов, Ш. Шәйдуллин, С. Слесарский) белән чагыштырып, республиканың сәнгать белгечләре рәссам буларак формалашу чорында ук аның сәнгати индивидуальлеген, мөстәкыйль һәм сыгылмалы фикер йөртүен ассызыклап, картиналарында лиризмга, хиссияткә омтылышны билгеләделәр, яктылык-һава мохитен оста тудыруына сокландылар. 1978 елда Яшьләр үзәгенә куелган беренче эшләре турында А. Новицкий болай дип яза: «Ул табигатьне ярата һәм тоя, авыл кешеләрен белә һәм аңлый, әйләнә-тирә дөньяда шигъри җанына хуш килгән моң эзли. Йомшак итеп форма бирү, тоны һәм төсе буенча үзара якын мөнәсәбәтләрне чагылдыру, яктылык-һава мохите булдыру – рәссам күбрәк әлеге чараларга мөрәҗәгать итә. Әмма ул алдан билгеләнгән алымнар белән генә чикләнми. Сюжетка һәм характерга карап, ул башка, үзенә хас булмаган сәнгати чараларны да куллана. Әйтик, «Җамал апа» этюдында без үткен рәсем, алдан уйлап эшләнгән яссылыклы чишелеш, төсләр экспрессиясе белән очрашабыз» [Новицкий, 1978].

1978 елда Мәскәүдә Бөтенсоюз яшьләр күргәзмәсендә «Фәния – дежурда» полотносы күрсәтелә. Анда өстәл артында телефон янында утырган кыз сурәтләнгән. Кызның сөйкемлелеге, картинаның яктылыкка күмелүе, тәрәзәдән күренеп торган авыл пейзажы, өстәлдәге чәчәкләр бәйләме сафлык һәм эчкерсезлек атмосферасы тудыра. Җанлылыгы һәм тәэсирлелеге ягыннан А. Файнберг бу картинаны В.А. Серовның «Персик тоткан кыз»ы белән янәшә куя [Файнберг, 1983, с. 101].

А. Файнберг аның «Иске каһвә кайнаткыч белән натюрморт»ын да (1978), портрет, натюрморт, пейзаждан «үрелгән» тәүге жанр картиналарын да югары бәяли.

«Хат» картинасында (1976) агач ботаклары арасыннан оялчан гына карап торган татар кызы сурәтләнгән. Йөзендә, янып торган кара күзләрендә аның дулкынлануы, каршылыклы хисләре чагыла. Картина яктылык рефлекслары белән сугарылган. Йомшак төсләр гаммасы, пумала белән сак эш итү әсәрнең лирик яңгырашын көчәйтә.

«Күки авылы малайлары» (1978) картинасы, «Автопортрет» кебек үк, җиренә җиткереп эшләнгән. «Мим Фәрид Абдуллин портреты»нда (1978) ул тагын да катгыйлана төшә: анда персонажның психологик характеристикасы аеруча төгәл бирелгән. Рәссам грим салынган Марсель Марсоның тамаша вакытында алынган фоторәсемен һәм артист артындагы диварга эленгән афишаны иллюзионист эффекты белән бирә.

Беренче мәртәбә Казанда «Зур Идел» зона күргәзмәсендә күрсәтелгән «Әбигә хат килде» автобиографик полотносы (1979) шул заманның портрет-картиналары арасында тирәнлеге һәм эмоциональ эчтәлеге белән аерылып тора. Автор гади генә сюжет аша татар авылының тормыш-көнкүреше, гаиләнең ныклы әхлак нигезләре турында сөйли. Анда өлкәннәргә хөрмәт һәм якыннарыңны кайгырту хакимлек итә. Биредә өй эчендәге яктылык-һава мохите дә бик оста бирелгән. Әбине әйләндереп алган кулдан эшләнгән әйберләр (корама юрган, шәмаил, стенага рамга куеп эленгән гаилә фоторәсемнәре, чаршау, келәм һ. б.) җентекләп һәм яратып сурәтләнгән. «Бу картинаны язганда, авылда үткәргән балачагымны искә төшердем. Алты яшемдә бик оста укый идем инде, шуңа күрә укый-яза белмәгән ялгыз карчыклар мине туганнарыннан килгән хатларны укырга чакыралар иде. Хатларын укыйм, ә алар шатлыкларыннан мине конфет белән сыйлыйлар! Шул әбиләрнең гомумиләштерелгән образын тудырдым мин... Хәзер дә авылга кайтырга яратам. Анда буген дә элеккечә үк ялгыз карчыклар күп. Теге әбинең ким дигәндә 7–8 прототибы бар иде... Бу картина өчен мине үз вакытында, хәзерге авыл бөтенләй башка проблемалар белән яши дип, бик нык тәнкыйтьләделәр», – дип сөйли рәссам.

Гимаевның бәхәс куерткан беренче сюжетлы-тематик эшләреннән «Татарстан акробатлары» (1979) картинасын атарга мөмкин. Анда ул студент елларында бергә күнекмәләр ясаган һәм бер командада чыгыш ясаган аерым спортсменнарның үзенчәлекле төркеме портретын иҗат иткән. А. Файнберг фикеренчә, бу композиция Д.Д. Жилинскийның «СССР гимнастлары» дип аталган билгеле полотносын хәтерләтә, «әмма бөтенлек җитмәү, характерларны өстән-өстән генә бирү һәм төсләр сайлау ягыннан аннан калыша» [Файнберг, 1983, с. 102]. Темалар якынлыгына (акробатлар күнекмәләр вакытында), кайбер композицион алымнарның охшашлыгына (өстән сурәтләү) карамастан, Гимаев картинасында һәр спортсмен индивидуаль,

башкалардан аерылып тора[1]. Яшел келәмнең шартлы декоратив фонында аларның кызыл һәм ак киемнән җыйнак, матур фигуралары ассызыкланган. Композиция уртасында үзенең гадәти кара костюмыннан аларның тренеры (Александр Михайлов) дүрт кешедән торган төркемнең («силовая четвёрка», А. Горячев, В. Козырев, К. Хәкимуллин, Р. Фәтхуллин) классик пирамиданы үтәвен күзәтә. Барлык спортсменнар үз күнегүләрен башкарырга әзерләнгәндә, атлетларның берсе (Юрий Дулатов – СССР чемпионы, химия фәннәре кандидаты; аркасына «СССР» дип язылган җыелма команда әгъзасы формасыннан) тренер янында тамашачыларга аркасы белән баскан. Рәссам шул рәвешле команданың иң көчле уенчысын аерып күрсәтә.

1978–1979 елларда рәссам СССР Сәнгать академиясендә Х. Якупов җитәкчелегендә шөгыльләнә һәм материал җыю өчен системалы рәвештә республика авылларына барып йөри. Авыл кешеләренең – колхозчылар, картлар һәм балалар, төрле яшьтәге хатын-кызлар портретлары сериясе, шигърият һәм лиризм белән сугарылган пейзажлар («Әхмәт абый», «Маһинур апа», «Бабай портреты», «Күки авылы малае», «Күкидә кич» һ. б.) – зур тырышлык таләп иткән эшнең нәтиҗәсе менә шулар. Бу картиналарның күбесе республикабыз һәм илебез музейларында һәм галереяларында урын алган.

Гимаев пейзажлар да язарга ярата. Авыл күренешләре бигрәк тә лиризмга һәм якты сагышка күмелгән. Бер күргәзмәдән соң Т. Мамаева аны ничектер «авылчы рәссам» дип атаган иде. Шәһәрдә туып-үскән, һәрвакыт шәһәрдә яшәгән кеше ата-бабаларының җире, авыл кешеләре белән бәйләнешне югалтмаган. Ул үзенең полотноларында ата-бабаларының кече ватанына кайту белән бәйле балалык тойгыларын тирән дулкынлану белән гәүдәләндерә: күл буендагы бөдрә талларны, тирә-яктагы каеннарны, кыр чәчәкләрен. Аларда яңа кардан арчылган җирдәге кояш җылысын, яшел үлән, яңа чапкан печән исен тоясың. Көзге пейзажларда контрастлар өстенлек итә, якты һәм ачык төсләр агач күләгәләренә үрелеп китә, саргайган яфраклар көзге сагышны көчәйтә («Сентябрь», «Октябрь»). Агач кәүсәләрен, ботакларны көзгедәгедәй чагылдырган су өстендәге шадралар сиздерми генә ачык күк йөзенә тоташып, уенчак кояшлы көннең бик тиз үтеп китәсенә ишарәле кебек («Казансуда яз. Казан Кремле», 1997). «Яльчик күле» (1997) картинасында күл өстендәге ачык зәңгәр төсләр караңгы яшел һәм ачык көрән төсләргә күчеп, тылсымлы тынлык һәм сафлык атмосферасы тудыра.

Рәссам хәзерге заманның үтә нык урбанизацияләнгән шәһәрләренә килеп эләккәч, язу манерасы да, картиналарның интонациясе дә үзгәрә: нерв, экспрессия пәйда була. Төрек циклына караган картиналарда бу бигрәк тә ачык чагыла. «Урта диңгез. Анталия янында» (2000) картинасында саргылт-кызыл-шәмәхә яктылык чагылышында

---

[1] Они все – известные в республике мастера и кандидаты в мастера спорта СССР в 1970-е годы: Николай Александров, Равиль Шакиров, Валентин Лобанов, Леонид Козырев, Дамир Усманов, Неля Хатыйпова, Эльвира Мустафина.

бирелгән ачык зәңгәр һәм кара болытлар диңгез стихиясендәге шомлы киеренкелекне гәүдәләндерәләр.

З. Гимаев иҗатының иң көчле ягы – портрет: рәсемнәрдә, натурадан ясалган матур этюдларда, үзенчәлекле итеп оештырылган композицияләрдә (индивидуаль, парлы, төркем портретлары, портрет характеристикасы өстенлек иткән көнкүреш жанрына караган картиналар) урын ала. Күренекле татар мәдәнияте эшлеклеләренең соңгы егерме ел эчендә язылган портретлары куелган даими эшләүче экспозицияләр белән әйдәп баручы татар театрларында (Г. Камал һәм К. Тинчурин исемендәге), Казан федераль университетында танышырга мөмкин. Бүгенге көндә бер генә рәссам да тамашачыга З. Гимаев кебек киң күләмдә, зур залларда тәкъдим ителмәгәндер мөгаен.

Татар мәдәниятенең язучылар, шагыйрьләр, композиторлар, артистлар кебек билгеле затлары рәссамнарны һәрвакыт иҗатка рухландырды. Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты һәркемнең күңелендә гадәти булмаган хисләр уята. Гимаев та аңа битараф кала алмый. Рәссамның әлеге темага беренче эше Г. Тукайның 100 еллыгына багышланган күргәзмәгә куела. Шагыйрь яшәгән заманның рухын, атмосферасын тою өчен, ул аның туган-үскән җирләрендә була, бик күп материал туплый. Әстерхан чорында Тукай өмет һәм киләчәккә ышаныч белән яши, икенче полотнода автор үз көченә нык ышанган шагыйрьне фикердәшләре, прогрессив татар яшьләре вәкилләре янәшәсендә сурәтли («Тукай дуслары арасында»).

Ул мәдәният, фән һәм әдәбият әһелләренең генә түгел, замандашларының, төрле яшьтәге кешеләрнең һәм төрле һөнәр ияләренең портретларын да яза. Геройларының рухи халәтен тәэсирле гәүдәләндерү максатында, ул буяуларны үтә күренмәле юка катлам белән сала, лессировкадан файдалана. Шунлыктан аның күп кенә картиналары эчтән балкый, колориты – йомшак, төсләре – үтә нәфис.

Портретларда ул үз геройларының асылына үтеп керергә омтылып, характерларындагы кечкенә генә нюансларны да игътибарсыз калдырмый. Композициягә хас үзенчәлекләр дә шуны таләп итә. Кагыйдә буларак, ул полотноларны артык детальләр белән тутырмый, ә портрет иясенең кабатланмас үзенчәлеген, рухи халәтен төгәл чагылдырган берәр символ табарга тырыша. Әйтик, кайвакыт ул китап («Н. Исәнбәт портреты»), кулдагы сирень ботагы («С. Садыйкова портреты») булырга мөмкин. С. Сәйдәшев портретында ачык шәмәхә, ачык зәңгәр һәм яшел төсләргә күмелгән сирень куагы илһамланган композиторның тышкы кыяфәтенә, аның зәңгәр күзләренә, ак киеменә бик тә туры килә («Салих Сәйдәшев», 2000). Режиссер Празат Исәнбәт яшь үсентеләр биргән зур, ныклы агач фонында сурәтләнгән – бу шулай ук символик яңгырашка ия. Ә Д. Сиразиев портретында бер кечкенә генә деталь – чиста ак фондагы «елаучы» маска – талантлы режиссерның катлаулы язмышын ачарга ярдәм итә.

2005 елда Мәскәүдә «Татарстан рәссамнары» күргәзмәсендә урын алган «Ак чәчәк. Хәсән Туфан» (2000) портретын Гимаев

дусларының хатирәләренә таянып яза. Рәссам күңелендә ул ак чәчәк белән тиңләшә. Төгәл рәсем һәм метафорик фон геройның эмоциональлеген, югары дәрәҗәдәге интеллектуальлеген, шул ук вакытта үтә гадилеген ачарга булыша. Еракка төбәлгән күз карашы, кулындагы кечкенә генә ак чәчәк портретны төгәлли дә куя.

«Сагыш» (1997) – Бакый Урманчега багышланган иң уңышлы эшләренең берсе. Аның турыдан-туры тамашачының йөрәгенә төбәлгән бер үк вакытта нәзакәтле дә, тирән сагышлы да карашы эчке кичерешләр белән тулы. Ул ак күлмәктән, галстуктан, әмма алъяпкычын да кигән. Биек маңгаендагы тирән буразналары, тузгыган ак чәчләре, бераз алгарак чыккан гәүдәсе, тезләрдә тыныч кына яткан куллары – барысы да аның эш сөючән һәм зыялы кеше булуын күрсәтә. Арттагы караңгы фон һәм оста үзе агачтан кисеп ясаган атаклы зирәк карт сыны иҗатчының катлаулы һәм авыр юл узуын искә төшереп тора.

Хатын-кыз портретлары аерым шигърилек һәм лиризм белән сугарылган. Беренче татар актрисасы С. Гыйззәтуллина-Волжская портреты XX гасыр башы рус реалистик портреты традицияләренә барып тоташа – ирексездән М. Врубель, В. Серов полотноларын хәтергә аласың. Кызыл фонда малахит-яшел төстәге костюм драматизмны көчәйтә. Композициянең вертикаль рәвеше актрисаның үз-үзен күрсәтергә омтылуына, сынаулар һәм авырлыклар алдында баш имәвенә ишарә. Ә Ф. Камалова портретында поза, күз карашы аша, актрисаның гүзәллеге, матур килеш-килбәте белән бергә, зирәк акыл, боерырга яратучан холык, үз-үзенә нык ышанганлык ассызыклана. Рәссам пумаласыннан төшкән әлеге һәм башка портретлар башкалардан аерылып торган шәхесләрне, татар халкының талантлы вәкилләрен буыннар хәтерендә сакларга ярдәм итә. Бу галерея – рәссамның татар мәдәниятенә, портрет кебек катлаулы жанрда Татарстан рәсем сәнгате үсешенә керткән бәяләп бетергесез зур өлеше.

Гимаевның консерватория профессоры Семен Казачков белән яхшы, үзара ышанычка корылган мөнәсәбәтләре, озакка сузылган әңгәмәләр музыкантның нечкә психологик портретын иҗат итәргә, аның холкына хас кайбер сыйфатларның серен ачарга мөмкинлек бирә. «Бах партитурасы өстендә кулларын күтәргән, дулкынланган, музыканың бөеклеге, бәлки, бөтен илаһи дөнья каршында башын игән музыкантны тамашачы әнә шундый итеп күрә» [Лукьянов, 2009, с. 395].

Ул геройларның тышкы кыяфәтләрен генә сурәтләп калмый, бу полотноларда авторның аларга булган мөнәсәбәтен дә тоясың: яратуны, хөрмәт итүне, кызгануны... Кайвакыт моңа нечкә яхшы юмор да килеп кушыла. Бу бигрәк тә балалар портретларында нык тоемлана: рәссам аларны үтә нык яратып яза («Улымның портреты», «Лиана», «Марина» һ. б.).

Аңарда фоторәсемне хәтерләткән портретлар юк, рәссам үзен камера формалары белән генә дә чикләми. Кешенең рухи дөньясын психологик яктан ачуда фон аеруча әһәмиятле роль уйный. Т. Миңнуллин, милли сәнгать турында фикер йөртеп: «Бөрмәле итәк, калфак,

түбәтәйдән миллилек эзлибез, – дигән иде. – Зөфәрдә ул атрибутлар юк. Мин аның эшләрендә аның татар рәссамы, үз халкын якыннан белгән, аның җанын аңлаган рәссам икәнен күрәм» [Миңнуллин, 2001]. «Яшь хуҗабикә» картинасында татар халкының костюмнарны, шулай ук йорт эчен декоратив тукымалар, матур сөлгеләр, чигүләр белән бизәргә яратуын рәссам бик оста тотып алган.

Аның композицияләре гаҗәеп сыгылмалы. Пантомима өлкәсендәге тәҗрибәсе авторга ым-ишарәдә, кыланышта, гәүдә торышында кешенең эчке дөньясын сиземләргә ярдәм итә. Замандашларыбызның портретлары арасында драматург Туфан Миңнуллинның портретлары аерылып тора. Беренче эшендә рәссам бөтен игътибарын геройның йөзенә юнәлдергән: ул күзлек аша, күзләрен бераз кыса төшеп, тамашачыга сынап карый сыман, куе кашларын җыерган, киң маңгаендагы сырлары да киеренке халәтен күрсәтә (1995). Икенче портретта ул тыныч күренә, әмма барыбер тирән акыллы шәхеснең тынгысыз җаны чагылыш таба. Урыны-урыны белән яктылык таплары хәрәкәте ярдәмендә «ярсытылган» тигез фон да шуңа хезмәт итә. Үзенең портретлары турында Т. Миңнуллин болай ди: «Охшаганмы, юкмы миңа төсе-килбәте белән, эш анда түгел, әмма ул мин. “Ни өчен син” дип сорасалар, төгәл җавап бирә алмас идем. Җаны минеке ул сурәтнең. Моның өчен мин Зөфәргә рәхмәтле».

З. Гимаевның күп кенә картиналарын төрле елларда Россия һәм Татарстанның музей һәм галереялары сатып ала. Аның эшләрен чит илләрдә дә бик теләп алалар. Бу – аның иҗатына игътибар зур булуны тагын бер кат раслый. 1993 елда Друо галереясында (Париж) аукционда рәссамның утыздан артык эше – портретлары, пейзажлары, жанр картиналары – сатыла. Ул вакытта бик сирәк иҗат әһеленә генә мондый бәхет елмая.

Үзәк матбугатта, Россия күргәзмәләрендә, «Зур Идел төбәк күргәзмәсендә Зөфәр Гимаевның исеме һәрвакыт илебез рәсем сәнгатенең күренекле осталары арасында телгә алына. Рәссамның полотнолары нәфис музыкаль тональлек һәм үзенчәлекле иҗат манерасы белән игътибарны җәлеп итә. Ул һәрчак тормыш, хәзерге заман сәнгате һәм үзенең «мин»е арасында гармония урнаштыруга ирешә. Рәссамның бәхете дә шунда.

**Әдәбият**

*Новицкий А.* Выставка в Молодёжном центре // Советская Татария. 1978. 30 апреля.

*Файнберг А.* Художники Татарии. Л.: Художник РСФСР, 1983.

*Лукьянов В.Г.* «Сеня, это – ты…». Штрихи к портрету // Семён Казачков: хоровой век. Казань, 2009.

*Миңнуллин Т.* Тагын бер егетебез // Ватаным Татарстан. 2001. 16 январь.

***Солтанова Рауза Рифкат кызы,***
*сәнгать фәннәре докторы,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив гамәли сәнгать бүлеге мөдире*

УДК 681.8

***И. Кадыйров***

# СЕБЕР ТАТАРЛАРЫНЫҢ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

В данной статье речь пойдет о специфике инструментальной культуры, которая является определяющим фактором в научном познании этнического кода всех народов. На сегодняшний день, вести речь о музыкальных инструментах Западной Сибири крайне трудно. С одной стороны в традиционной культуре сибирских татар мы можем отметить влияние Восточной музыкальной культуры. С другой стороны по историческим материалам в инструментальной традиции сибирских татар совершенно не изучены музыкальные инструменты, которые ведут свое начало происхождения и имеют связь шаманской культурой, в частности с народами Алтая, Монголии, Хакасии, Тыва, Калмыкии.

**Ключевые слова:** инструментальная культура, сибирские татары, музыкальные инструменты, традиционная музыкальная культура, этнический код.

This article is focused on the specifics of instrumental culture, which is a determining factor in the research of the ethnic code of all peoples. Today, talking about musical instruments in Western Siberia is extremely difficult. On the one hand, we can note the influence of Eastern musical culture in the traditional culture of Siberian Tatars. On the other hand, according to historical materials, traditional musical instruments of the Siberian Tatars, that have their origin and connection with shamanic culture, in particular with the peoples of Altai, Mongolia, Khakassia, Tyva, Kalmykia, have not been completely studied.

**Keywords:** instrumental culture, Siberian Tatars, musical instruments, traditional musical culture, ethnic code.

*2019 елның декабрь аенда 1968-1977 елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор бүлегендә эшләгән һәм соңгы чорда Институт белән хезмәттәшлеген кабат җанландырып җибәргән күренекле музыка белгече Илгиз Шәфыйк улы Кадыйровка 80 яшь тула. Институтта эшләгән дәвердә галим, дистәгә якын фәнни экспедицияләрдә катнашып, Себер татарларының музыка сәнгате буенча уникаль материал туплый, язып алынган җырларны нотага сала, шушы кабатланмас мирасны халыкка җиткерү юнәлешендә дә зур эш башкара. Себер татарларының музыка уен кораллары, үзенчәлекле музыкаль жанрлары турында күпсанлы фәнни мәкаләләре дөнья күрә, бу теманы халыкара конференцияләрдә дә яктырта. Татар халкының төрле йолалар белән бәйле Себер татарларына гына хас булган «могам» дип аталган көйләрен, дастан-җыру үрнәкләрен дә фәнни әйләнешкә Илгиз Кадыйров кертеп җибәрә.*

Музыка уен кораллары халыкларның этник һәм тарихи-мәдәни уртаклыгын билгели торган истәлекләр булып торалар. Шуңа күрә аларны өйрәнү зур фәнни әһәмияткә ия.

Көнбатыш Себер төбәгенең уен кораллары турында фикер йөртү әлегә шактый кыен. Чөнки алар бөтенләй сакланмаган диярлек һәм алар турында язма мәгълүматлар да юк дәрәҗәсендә. Ләкин бу хәл музыка уен коралларына ярлылык турында сөйләми. Беренчедән, тормыш-көнкүрештә бүген дә курай, кубыз, гармун һәм скрипка уйнау, төңгер кагу яшәсә, икенчедән, әкиятләрдә һәм өлкән буын кешеләре хәтерендә күптөрле уен кораллары булу турында мәгълүматлар очрый.

«Себер татарларының борын-борыннан, бер яктан, Көнчыгыш музыка культурасы тәэсирен һәм бәйләнешен, икенче яктан, төньяк һәм көньяк күршеләренең шаман культурасын үз эченә алган шактый күптөрле музыка кораллары булган» [Ярмухаметов, Ахметова, 1971, с. 51].

1967 елгы фәнни экспедиция вакытында бараба татарларында төңгер дигән бәреп уйнау-кагу коралы табылды[1]. Аның диаметры 28,5 см, биеклеге 7,5 см. Төңгердә, сирәк булса да, әле дә кагалар. Туй-мәҗлесләрдә, биетү өчен, скрипка яки гармунга кушылып төңгер дә яңгырый.

Эшләнеше белән төңгер алтай халыкларында киң таралган шаман коралларын хәтерләтә. Аларда да (шоорлар, кумандиннар, челканнар, тубалар һ.б. ) шаман бубены атамаларының берсе «тунгур» яки «ту- ур»... Һәм ул килеп чыгышы белән монголларныкы дип исәпләнә [Потапов, 1939, с. 86]. Туваларда бу уен коралы – «дүңгүр», ә алтай халыкларында – «түңүр» дип йөртелә.

Төңгерне иләккә охшаган кысага мәче тиресен киереп ясаганнар. Кысаның ян-ягында дүрт урында – икешәр җиз тәңкә. Тире алты җирдән аска тартылып беркетелгән. Уйнаганда җиңел булсын өчен, бармаклар белән тотарга махсус түгәрәк тишек тә бар. Картларның әйтүенә караганда, бу кагып уйнау коралы йола белән бәйле булып, туйларда гына уйналган.

Бу табыш, безнеңчә, кайбер әһәмиятле мәсьәләләрне ачыкларга ярдәм итә алыр иде. Мәсәлән, гарәп илчелеге вәкиле Ибне Фазлан IX гасырда болгарларда кеше күмүне сурәтләп болай язган: «Аның белән бергә кабергә набид һәм (ниндидер) җимеш һәм тунбур урнаштырдылар» [Путешествие..., с. 77]. Шушы уңайдан Мәхмүт Нигъмәтҗанов: «Мөгаен, сүз тикшерелә торган халыкларда булган лютня (тунбур) турында бара», – дип тунбурны кыллы лютняга тиңли [Народная музыка, с. 447]. Әлбәттә, бу нәтиҗә Урта Азия халыкларында киң таралган, чиертеп уйный торган кыллы танбур, тамбур һ.б. булуын күздә тотып ясалгандыр. Югыйсә, әлегә кадәр татар халкында андый исемдәге уен коралы булу-булмавы турында мәгълүматлар очраганы юк кебек.

---

[1] Төңгерне экспедиция әгъзалары Ф. Әхмәтова һәм Р. Гайнановка Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Яргул авылыннан В. Алиев бүләк иткән. Хәзер ул Институтның халык музыкасы кабинетында саклана. Төңгернең копиясе Татарстан АССР Дәүләт музеена куелды.

Шулай булса да, Себер татарлары төңгере белән IX гасыр тунбуры арасында уртаклык юк дип өзеп әйтергә ярамый. Әмма бу уртаклыкны бәлки иң элек көнчыгыштарак яшәгән төрки халыклардан эзләргә кирәктер? Аларның рухи культуралары да янәшә бит. «Билгеле булганча, безнең крайның аборигеннары, угро-финнар белән якынайган төрки һәм аларга якын кабиләләр көнчыгыштан килгәннәр. Күрәсең, бу борынгы төркиләрнең музыкаль традициясе Идел буе болгарлары музыкасы барлыкка килүдә аерым әһәмияткә ия булгандыр. Монгол, корея, тува һәм татар музыкасының зур бердәмлеге очраклы түгел» [Народная музыка, с. 443]. Шулай икән, тунбурның иң борынгы мәҗүси бабаларыбызның көнчыгыштан – Алтай йортыннан алып килгән уен коралы булуы да ихтимал.

Бер мисал китереп үтик. Калмыкларның тире тартып эшләнгән ике яклы барабаннары бар. Ул «кенкерге» дип йөртелә (чагыштыр: кенкер(ге) – төңгер). Әйтелештәге ошашлык очраклы булмаска тиеш. Заманында калмыклар (төркичә «халимәк» аерылган дигәнне аңлата). Себер татарлары белән янәшә яшәгәннәр. (Калмыклар элек ойратлар дип аталганнар). «XVI гасырда ойратларның бер өлеше Джунгариядән төньякка – Россиянең кеше яшәми торган киңлекләренә – Себергә һам Урал аръягына китәләр. Ойратлар шунда Обь, Иртыш һәм Тобол ярлары буйлап үзләренең күчеп йөрү урыннарын җәелдергәннәр» [Тритуз, с. 5]. Һәрхәлдә, күчмә халыклар үзләре белән музыка коралларын да йөрткәннәр.

Тунбурның бәреп уйный торган булуына күп кенә халыкларда бу төр уен кораллары исемнәренең [т], [д], [б] авазларына башлануы дәлил була алыр иде (тыйбл, тумыр, табла, топшур, доол, дойра, дарбука, даулпаз һ.б.).

Тунбурның шул ук бубен булу ихтималын Дворхак та әйткән [Путешествие..., с. 148].

Себер татарларында киң таралган бәреп уйный торган тагын бер музыка уен коралы – тип. Ул хәзер кулланылмый.

Тип төңгер кебек туйларда сугылган. «Кияү типсәү[1]» дигән туй йоласы җырының аталышы, күрәсең, аның белән бәйле [Ярмухаметов, Ахметова, 1971, с. 51].

Фәнни экспедицияләрдә Типнең формасы һәм функциясе турында төрле фикерләр тупланды. Мәсәлән, Омск өлкәсе Ишем-Тамак районы Саургач авылында типнең шул ук бубен икәнлеген хәтерлиләр, шул ук районның Илчебага авылыннан З. Хисмәтуллина типнең формасы белән аш казанына, ягъни литаврага ошаганлыгын һәм балаларны сөннәткә утырткач «тип сугып» аларга бүләкләр җыелуын хәтерли.

Төмән өлкәсе Вагай районы Күләт авылында балаларны сөннәткә утырту туе булган. Ул вакытта да «тип сугып» җыйган акчаны музыкантларга һәм балаларга бүлеп өләшкәннәр. Шунысы кызыклы, туйда

[1] Типсәү – туйда кияү хөрмәтенә җыр җырлау. Кара: [Тумашева, б. 201].

акча җыю эшенә биючеләр дә катнашкан. Биюче берәрсенең алдына килеп биесә, тегесе акча бирергә тиеш булган. Әптелхәмит бабай Ишметов (Вагай районы Үләртеш авылы, 1900 елгы) типнең зур булуын хәтерли. Анда бернинди дә шыңгырдавык (җиз тәңкә) булмаган[1].

Сорау туа: тип литавра формасында булганмы, әллә бубенга ошаганмы? Бу мәсьәләне ачыклау өчен безгә яңадан күрше халыкларның уен коралларына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Формасы, хәтта атамасы белән дә типкә ошаган уен кораллары турында мәгълүматлар шактый. Мәсәлән, элеккеге Томск губернасы Кузнецкий өязе төркиләрендә шаманнарда «тур» дигән уен коралы булганлыгы турында С. Малов язмаларында мәгълүматлар бар [Малов]. Н. Пантусов исә Илий краенда яшәүче таранчиларда литаврага ошаган тебиль – баз дигән уен коралы турында язып калдырган [Таранчинские песни]. Ә менә үзбәк халкының дойрасын хәтерләткән «дап» уйгырларда бубен хезмәтен үти икән. Чечен-ин- гушларда биегәндә киң кулланылган тэп гадәттәге бубен төзелешендә. Дагстанда да тэп бар. Ул агач кысадан тора һәм аның эченә кыңгыраулар һәм металл балдакчыклар эленә. Шул ук Дагстанда кечкенә керамик литавралар – типлипито бар. Грузиннарда ул диплипитом дип йөртелә [Атлас музыкальных..., б. 110, 111, 48].

Санап кителгән мисалларда типкә охшаш уен коралары бубенны хәтерләтә. Себер татарларында да күп очракта ул шул формададыр. Мәсәлән, урам буйлап «кияү типсәп» килгәндә сугылган тип, әлбәттә, бубен кебектер. Югыйсә, аш казаны кадәр зур уен коралын күтәреп җырлап бару уңайсыз булыр иде.

Типнең кайбер төбәкләрдә литаврага ошаган формалары булуы да хактыр. Аларның, бәлкем, монголларда киң таралган литавралар белән бәйләнеше булган. «XIII гасырның атаклы венециан сәяхәтчесе Марко Полоның китабыннан монголларның хәрби походлар яки сугышлар алдыннан күмәк җырлаулар үткәрүе мәгълүм. Ул барабаннар һәм литавралар тавышы астында барган» [Монголия...].

Бараба татарларының тагын бер музыка уен коралы – ятыган булуы турында да фаразлар бар. «Ятыган турында (лежачая арфа) һәм алтмыш кыллы ай тумбра (шестидесятиструнная домбра в виде полумесяца), бәлки икесе дә бер үк нәрсәдер?! Бу турыда без себер татарлары әкиятләреннән генә белдек» [Ярмухаметов, Ахметова, 1971, с. 51].

Ятыганның бараба татарларында яшәү ихтималын ике дәлил куәтли алыр иде. Беренчедән, мондый уен коралы күрше халыкларда киң таралган булса, икенчедән, шушы уен коралына кушылып сөйләнергә мөмкин «Кузы Көрпәч һәм Баянсылу» дастаны бар. Һичшиксез, әле күптән түгел генә бу дастан чичәннәр тарафыннан көйләп әйтелгәндер (күрше казакълар аны шулай әйтәләр дә) [Ерзакович]. Чөнки бүген дә мәшһүр дастанның көйләп әйтелә торган кайбер өзекләре сакланып калган һам алар халык арасында (дастаннан аерылган хәл-

[1] 1971 елгы экспедиция материалларыннан.

дә) мөстәкыйль җыр формасына күчә башлаганнар (җырчылар исә үзләре дастанның эчтәлеген якынча гына беләләр).

Чичәннәр[1] исә Себер татарлары арасында булган. Мәсәлән, Төмән өлкәсе Вагай районы Тугыз авылы сөйләмендә «цицән» – җырга оста, җырга бай кеше. «Әүүәл саманта бәйетләргә цицән булганнар» [Тумашева, б. 219].

Инде ятыганның күрше халыклардагы нөсхәләренә килгәндә, А.В. Андрианов шушындый ук уен коралын барабалардан ерак булмаган минусин татарларында (хакасларда. – *И.К.* ) тапкан. Аның аңлатуынча, «Чатыган – төбе буенча биш-алты бакыр кыл тартылган, әйләндереп салынган озын һәм тар тагарак кебек. «Ансыз бер улус та яшәми. Чатыганның кылларын чиертеп нинди дә булса бер батырның баштан үткәннәре турында речитатив хикәят сөйлиләр» [Андрианов, с. 523; Аджинджал, с. 505].

Шулай ук, джатыган һәм кобысның кизил татарларында да булуы мәгълүм [Князь Костров, с. 149]. Д.А. Клеменц язганча, «кизиллар әле дә үзләренең кайчандыр Ишем һәм Тобол буенда яшәгәннәрен хәтерлиләр» [Потапов, с. 89]. Моның булуы бик мөмкин. Чөнки «Себер ханлыгы таркалу җирле халыкның күчеп утыруына сәбәп булган. Себер татарларының төрки телле бер төркеме көнчыгышка күчеп китә, бу турыда XVII гасыр тарихи актларының документларга нигезләнгән хәбәрләре бар» [Потапов, с. 89].

Калмыкларга күз салыйк. Аларда «ятга (ятха) – һәрберсе аерым терәккә беркетелгән металл кыллы гөсләә» [Тритуз, с. 89].

Хакасларның чатханнары турындагы соңгы мәгълүматларга тукталып үтик. «Чатханга кушылып борынгы җырлар һәм былиналар башкарыла. Ул күп кыллы, анда чиертеп уйныйлар. Чатхан агачтан эшләнә һәм төбе өскә әйләндерәп куелган тагаракка охшаган. 7–8 эчәге яки җиз кыллар тагаракның бөтен буена тартыла. Аларның астына сарыкның умыртка сөягеннән эшләнгән күчеп йөри торган терәк куялар. Терәкнең ничек күчеп йөрүенә карап, һәр кыл төрле югарылыкта тавыш бирә. Күчеш вакытында чатханның көйләнеше (настройка) үзгәрә. Бу үзгәреш я төрле ладларда язылган көйләрне, я былиналарны башкарганда сюжет алмашуга карап эшләнә» [Атлас музыкальных…, с. 139].

Чатхан кыллары түбәндәге тавышларга көйләнә:

---

[1] Чичән дип аталган кеше хәзер үзе түгел, хәтта әлеге сүз үзе дә кулланыштан төшеп, авыз иҗатында гына калып бара... Казакъларда шешен, башкортларда сәсән йөри... Чичән сүзе элек сүз остасы дигәнне дә, җыручы-импровизатор дигән мәгънәне дә аңлаткан. Димәк, ул – һәр ике профессияне үзендә бергә җыйган кеше, борынгы халык шагыйре. Чичән җыручы буларак ничек иҗат итә соң? Иң элек ул шигырьне язып та, сөйләп тә чыгармый, аның кулында думбра була, ул шуның кылларында күтәренке, ярым көйле авазлар белән безгә тотрыксыз тезмә чыгарып сөйли... Ул борынгы халык җыр дастаннарының күбесен күңелдән әйтә, аларның шигъри алымнарын, сюжет һәм мотивларының һәр очракта ничек сайланылышын, төзелеш, композициядәге йолаларын алдан белә [Татар халык мәкальләре, б. 63–66].



Бу тавышлар рәтендә пентатоника лады теориясендә кабул ителгән биш төр дә бар. 2–3 нче кыллар арасында – квинта һәм 3–4 кыллар арасында кварта интерваллары булу башкарыла торган эпик әсәрләрдә бу актив интервалларның зур урын тотуын күрсәтә.

Хакасларның күршесе тофаларда хакас чатханына тиңдәш 6 тимер кыллы чаттыган бар. Аны тез башына куеп чиертеп уйныйлар [Атлас музыкальных…, с. 139].

Тувалыларның чадаганы да хакасларныкына охшаш [Атлас музыкальных…, с. 140]. Монда да җиде кыл. Аның тавышлар рәте:



Тезгә куеп уйный торган ятаган формасындагы лирада уйнаучы (Leierspieler) вогул (манси. – *И.К.* ) рәсемен «Вогул һәм остяк көйләре» дигән хезмәттә табарга мөмкин. Шунда ук чирек айга ошаган 9 кыллы арфада уйнаучы (Harpenspie1eг) рәсеме дә бар [Wogulische, p. XXXVIII–XXXIV]. Аларда, сирәгрәк булса да, «аккош» («лебедь») – 9 яки 13 кыллы арфа очрый икән [Народы Сибири, с. 605][1].

«Бу арфа – почмаклы арфа (угловая арфа) тибындагы чиертеп уйный торган күпкыллы уен коралы». Шундый ук төзелешле арфа мансиларда кулланыла [Атлас музыкальных…, с. 146]. Алар тавышы астында, сирәк булса да, былиналар сайлана (мансиларның биш кыллы цитрасы шул ук булса кирәк) [Народы Сибири, с. 605].

Күрше-тирәдәге халыкларның музыка уен коралларына экскурс ясау ятыганның себер, төгәлрәк әйткәндә, бараба татарларында булуына шик калдырмый. Тик, безнеңчә, ятыган һәм «алтмыш кыллы ай тумбра» – икесе ике уен коралы. Шунысы ачык – ятыган тезгә куеп яткырып уйный торган тагарак рәвешендә.

Ә инде чыңнары бары тик әкияттә генә калган «алтмыш кыллы ай тумбра» – (бәлки ул чынлыкта алты гына кыллы булгандыр, әкиятләрдә күпертү еш очрый торган күренеш) ярымай рәвешендә. Димәк,

[1] Хантыларның барабалар белән бәйләнеше турында Л. Лянг болай язган: «Бу нәсел (барабалар. – *И.К.*), ихтимал, үзләренең гадәттәге тору урыннары – Обь елгасы буендагы остяклардан килеп чыкканнар, чөнки ике нәсел да шайтанга табына. Кара: [Катанов, б. 5].

ятыган һәм тумбра формалары, уйналу ысуллары белән бер-берсеннән аерылалар. Бу бер. Икенчедән, ярты айга ошаган тумбраның килеп чыгышы җәя белән бәйләнмәгәнме? Һәрхәлдә, «кыллы музыка коралларының, шул исәптән, арфаның да бау тартылган җәядән килеп чыгышы турында фикер гаять киң таралган» [Садоков, б. 58]. Җәянең исә б. э. к. 5000 еллар тирәсендә неолит чорында Байкал буенда яшәүче кабиләләрдә булганлыгы мәгълүм [Окладников, с. 396–398].

Думбраның (тумбра) тормыш-көнкүрештән төшеп калуына күп тә түгелдер. Мәсәлән, туй йоласы «Күч кырында»1 ул болай искә алына:

Думбраны ла чиртә лә, чиртә
Булдым бакшы2, булдым бакшы.
Ай, күп халыкның арасында
Булдым яхшы, майҗан иман.

Думбра (домбра, думбрах һ.б. ) – казакъ, башкорт, калмык, үзбәк һәм таҗик халыкларында шактый киң таралган музыка коралы. Алар төзелешләре белән бер-берсеннән артык аерылмыйлар – барысы да ике кыллы, ә кыллар кварта итеп көйләнгәннәр (квартовый строй) [Атлас музыкальных…, с. 57, 132, 58, 134, 119, 125].

Шунысы ачык, думбрада, шул исәптән, Себер татарлары думбрасында да, чиертеп уйныйлар. Аның формасы һәм кыллар саны мәсьәләсен, киләчәк эзләнүләрне күздә тотып, ачык килеш калдырабыз. Себер думбрасының төньяк күршеләр – мансиларның тугыз кыл тарткан почмаклы (ә себер татарларында ярымай рәвешле) арфасына да, көньяк күршеләре – казакълардагы мәшһүр ике кыллы думбрага да охшавы мөмкин. Чөнки берничә халыкта төрле рәвештәге уен кораллары бер үк исем белән аталып йөртелү очраклары бар. Мәсәлән, кубыз – казакъларның ике кыллы уен коралы, татарларның авызга кабып өреп уйный торган варганы. Кубос – чувашларның гармуны.

Себер киңлекләрендә курай тавышы да еш яңгыраган. Г. Курманов, И. Сөләйманов, К. Хәбибуллин аны әле дә курадан ясап уйныйлар. Алар әйтүенчә, элегрәк курайны бик күп ясаганнар. Ш. Курманов исә туйларда бик еш курайда уйнаганнарын хәтерли. Тик шунысы бар – курай турында башка этник төркемнәрдә аз хәтерлиләр (мәсәлән, том татарлары һәм калмыкларда). Бу табигый дә. Чөнки курай күбрәк терлекчелек белән шөгыльләнгән күчмә халыкларда була[3].

Курайның аталышы казан татарларында, башкортларда һәм себер татарларында бер үк төрле атала. Башкорт халкында исә курайда уйнау осталыгы профессиональ югарылыкка күтәрелә. Күрәсең,

[1] Җыр Төмән өлкәсе Ялутор районы Исәт авылында 1903 елгы Шәңгәрәев Әхмәттән язып алынды (1970 елгы экспедиция материаллары).

[2] Бакшы-туйларда музыка уйнаучы (хәзер сөйләнми). Кара: [Әхметов, б. 58]. Үзбәкләр дастан башкаручы һәм да думбрачыларны бахши дип йөртәләр. Кара: [Кароматов, с. 37].

[3] «Курай терлек асрап яшәү хаҗәтләреннән килеп чыккан бик борынгы хәбәр бирү (сигнальный) коралы». Кара: [Лебединский, с. 8].

моңа башкортларның үзенчәлекле тормыш-көнкүреш шартлары сәбәп була. «Башкортостан территориясендә күп үсә торган эче куыш үсемлектән уйнаучыларның үзләре тарафыннан ясала торган курай (русча: «дягель», яки «дудник») башкорт халкының бөтен тарихы буена аның милли музыка инструменты булып килгән һәм килә» [Башкорт халк..., б. 11].

Курай Казан татарларында да гаять киң таралыш алган һәм халыкның борынгы милли уен коралы булып санала1. Хәтта бу турыда табышмаклар да бар:

Урманда кистем,
Эчен-бавырын уйдым,
Кабыргасын ике тиштем,
Әби көен ишеттем.
(«Өрәңге курай»)
[Татар халык табышмаклары, б. 388–389].

Иделдән алып Обька кадәр җәелгән зур киңлектә төзелеше һәм аталышы бер булган курай бары тик шушы халыкларда гына сакланганмы?

Монголлар иҗатына күз салыйк. «Илнең көнбатыш районнарында чатыр чәчәкле үсемлектән ясалган вертикаль флейта-цуурда уйнау осталары программ эчтәлекле пьесаларны искитәрлек итеп башкаралар» [Смирнов, б. 241–242] икән.

Кыргызларда, мәсәлән, элек-электән казакъ сыбызгысы һәм башкорт курае белән бер үк типтагы чоор бар. «Чоор» термины Урта Азиядә кыргызларга гына түгел, Себернең көньягындагы кайбер халыкларда да очрый» [Виноградов, с. 10–11]. «Алтай халыкларында башкорт кураена охшаш ләкин ян- ягы тишексез озынча флейта тибындагы шоор бик борынгы уен коралларыннан санала. Анда, нигездә, көтүчеләр уйный. Шоор эче куыш кәүсәле кипкән үсемлектән ясала [Параев, с. 11–12].

Күренә ки, курай – нинди дә булса бер генә халыкның милли хәзинәсе түгел, ә төрки телле халыкларда һәм монголларда киң таралган музыка уен коралы. Безнеңчә, аларның аталышлары да бер-берсенә якын: кур(ай) – цуур(ай) – чоор – ноор. Курай, шул исәптән себер татарлары курае да, иң борынгы уен кораллары рәтенә куелырга тиеш. Беренчедән, атамалары охшаш һәм бер үк сыйфатлы уен коралының кардәш халыкларда таралуы бу халыкларның кайчандыр бергә яшәүләрен дәлилли. Икенчедән, археологларның безнең өчен аеруча

[1] Кара: [Мусин, 1946]. «Курай башкортларда яки татарда гына түгел, шулай ук, үзбәкләрдә, кытайларда, бурят-монголларда, чувашларда бар. Татар, башкорт курайларының һәм эле әйтелеп киткән халыкларның өрел уйнала торган музыка коралларының, һәммәсенең дә дип әйтерлек, рәвешләре, тышкы кыяфәтләре, хәтта авазларының чагылышлары (темпы) бер-берсенә бик охшый, ләкин алар конструкциядә һәм тотып уйнау тәртипләрендә (хватка) бер-берсеннән нык аерыла... Шунлыктан курайны башкорт яки татар халыкларының музыка коралы дип кенә карау ялгыш», – дигән нәтиҗәгә килә И. Мусин.

әһәмиятле бер ачышы бар: б. э. к. iii меңьеллыкның икенче яртысында, II меңьеллыкның башында Байкал күле тирәсендәге халыкларда уйнау өчен махсус тишекләр уелган бер көпшәле сөяк флейталар һәм «Пан флейтасы» булган [Окладников, с. 396–398].

Себер татарларының уен кораллары болар белән генә чикләнми.

Омск өлкәсе Тусказан авылында үзен төп бохаралы дип атаган 80 яшьлек Ш. Курманов «колотушка белән бәреп уйный торган чәмбәрдә булуын хәтерли. Формасы белән түңгергә охшаган. Аңа бозау тиресе тартканнар. Ян ягында боҗралары бар. Муллалар бу уен коралында уйнауны тыйганнар, бары тик балаларны сөннәткә утырткан вакытларда гына уйнарга рөхсәт бирелгән. Бу очракта дин әһелләренең музыканы үз кирәкләрендә файдалануы сизелә. Күрәсең, мәҗүси йолалар белән бәйләнгән бәреп уйнау коралларын юкка чыгару яки тыю мөмкин булмаган[1].

Ш. Курманов икенче бер уен коралы – цимбал турында белә. Билгеле, ул хәзер сакланып калмаган. Цимбал өстәл озынлыгында булып, аңа 50 дән артык кыл тартканнар. Йөзем җимеше яки кызыл агачтан эшләнгән кечкенә таяк белән бәреп уйналган. Әле күптән түгел Чүплекүл авылының Хәйбулла атлы кешесе цимбалда скрипкага кушылып уйнаган.

Бу уен коралы турында башка урыннарда белмиләр диярлек. Бәлкем аны бу якларга үзләрен бохаралылар дип йөртүче үзбәк һәм таҗиклар алып килгәннәрдер. Чөнки үзбәкләрдә килеп чыгышы белән бик борынгы чорга караган цимбал тибындагы бәреп уйный торган кыллы чангта бар.

1975 ел.

**Әдәбият**


Wogulische und Ostjakische Melodien. Helsinki, 1937.

*Аджинджал И.А.* Из этнографии Абхазии. Сухуми, 1969.

*Андрианов А.В.* Айран в жизни минусинских татар // Записки ИРГО по отделению этнографии. XXXIV т., С. 523.

Атлас музыкальных инструментов народов СССР. М. 1963.

Башкорт халк йырзары. Уфа, 1954.

*Виноградов В.* А.В. Затаевич и киргизская народная музыка // А.В. Затаевич. Киргизские инструментальные пьесы и напевы. М., 1971. С. 10–11.

*Ерзакович Б.* Песенная культура казахского народа. Алма-Ата.

*Әхмәтов В.* Тобол-Таман татарлары диалекты // Совет мәктәбе. 1940. № 2–3. Б. 58.

*Кароматов Ф.* О локальных стилях узбекской народной музыки. «Музыка народов Азии и Африки». М., 1969.


[1] Музыка-җырга каршы көрәшүдә Себердәге дин әһелләренең үз араларында бердәмлек булмаган. Мәсәлән, Яүштә авылында (Томск өлкәсендә Чәкә мулла (Җәләлетдин Кучкильдинов) туйларда үзе скрипка уйнап йөргән. Өч малае да төрле музыка коралларында уйный белгәннәр. Мулла лекарьлык иткән, уколлар ясарга хәтта шприцлары булган. (Яүштә авылыннан Маннапова Сәрвәр (1905) һәм Абытай авылыннан Әбелбохаров Якуптан (1898) язып алынган материаллар. 1969 елгы экспедиция).

*Катанов Н.Ф.* Известия Лоренца Лянге 1716 года о Сибири и сибирских инородцах. Тобольск, 1905.

Князь Костров. Кизильские татары. «Москвитянин», М., 1854.

*Лебединский Л.Н.* «Башкирские народные песни и наигрыши». М.: «Музыка», 1965.

*Малов С.* Несколько слов о шаманстве у турецкого населения Кузнецкого уезда Томской губернии // Живая старина. Год 18. Вып. 2–3. 1909. С. 38–41.

Монголия (Улан-Батор). 1970. № 7.

Народная музыка. Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967.

Народы Сибири. М. –Л., 1956.

*Окладников А.П.* Неолит и бронзовый век Прибайкалья // МИА. 1950. № 18. Б. 396–398.

*Параев А.П.* Алтайские народные музыкальные инструменты. Горно-Алтайск, 1963.

*Потапов Л.П.* Этнический состав и происхождение алтайцев. Историко-этнографический очерк. Л.: Наука, 1969. 196 с.

*Потапов Л.П.* К семантике названий шаманских бубнов у народностей Алтая // Советская тюркология. 1970. № 3. Б. 86–93.

Путешествие Ибн Фадлана на Волгу. М.; Л., 1939.

*Садоков Р.Л.* Музыкальная культура древнего Хорезма. М.: Наука, 1970.

*Смирнов Б.* О мелосе монгольской народной песни. «Музыка народов Азии и Африки». М., 1969.

Таранчинские песни. Собраны и переведены Н.Н. Пантусовым. Записки ИРГО по отделении этнографии. XVII том, 1 вып. СПб., 1890.

Татар халык мәкальләре / җыючы һәм төзүче Н. Исәнбәт. 1 т. Казан, 1959. Б. 63–66.

Татар халык табышмаклары / җырчы һәм төзүче Н. Исәнбәт. Казан, 1970.

*Тритуз М.Л.* Музыкальная культура Калмыцкой АССР. «Музыка», М., 1965.

*Тумашева Д.Г.* Көнбатыш Себер татарлары теле.

*Ярмухаметов Х.Х., Ахметова Ф.В.* Некоторые итоги и задачи собирания и изучения фольклора Сибирских татар // Тезисы докладов итоговой научной сессии за 1970 г. Казан, 1971. Б. 51.

***Кадыйров Илгиз,***
*музыка белгече*

УДК 615/32

*Н.С. Кәрәмова*

# ЯҢА ДАРУ ПРЕПАРАТЛАРЫ БУЛДЫРУ ӨЧЕН ПЕРСПЕКТИВ КАНДИДАТЛАР БУЛАРАК ҮСЕМЛЕК ҺӘМ МИКРООРГАНИЗМНАРНЫҢ ИКЕНЧЕЛ МЕТАБОЛИТЛАРЫ

Статья посвящена обзору исследовательских проектов, выполняемых в научной группе под руководством кандидата биологических наук доцента Карамовой Назиры Сунагатовны на кафедре микробиологии Казанского (Приволжского) федерального университета. В работе представлены результаты совместных исследований с учеными университета г. Асьют, Египет по оценке противоопухолевого потенциала экстрактов суккулентных растений на клеточных линиях разных видов опухолей, а также антиоксидантной и антимутагенной активности экстрактов ряда растений. Подчеркивается особая опасность внутрибольничных инфекций и актуальность поиска новых лекарственных средств для лечения заболеваний, вызванных микроорганизмами, устойчивыми к антибиотикам. Данные, полученные при исследовании эндофитных актинобактерий тысчелистника обыкновенного (*Achillea millefolium* L.), произрастающего на территории Республики Татарстан, свидетельствуют о перспективности использования метаболитов эндофитов при разработке новых антимикробных препаратов для терапии внутрибольничных респираторных инфекций.

**Ключевые слова:** онкологические заболевания, цитотоксичность, линии опухолевых клеток, растительные экстракты, антиоксидантная активность, антимутагенность, антибиотикорезистентность, внутрибольничные инфекции, антимикробный потенциал.

The article is devoted to the review of research projects conducted in a scientific group under the leadership of Dr. Nazira Karamova at the Microbiology Department of Kazan (Volga region) Federal University. The paper presents the results of joint research with the scientists of Assiut University, Egypt, to assess the antitumor potential of succulent plant extracts on various tumor cell lines, as well as antioxidant and antimutagenic activity of different plant extracts. A serious health risk of hospital acquired infections and the relevance of the search for new drugs for the treatment of diseases caused by antibiotic-resistant microorganisms are emphasized. Data obtained in the study of endophytic actinobacteria from yarrow (*Achillea millefolium* L.) growing in the Republic of Tatarstan, Russia, indicate the promise of using endophyte metabolites in the development of new antimicrobial agents for the treatment of nosocomial respiratory infections.

**Keywords:** oncological diseases, cytotoxicity, tumor cell lines, plant extracts, antioxidant activity, antimutagenicity, antibiotic resistance, hospital acquired infections, antimicrobial potential.

*«Дәва булмаган үсемлек юк. Үсемлекләр*
*дәвалый алмаган чир юк».*
*Әбү Гали Сина*

Онкология чирләренең кызу темплар белән артуы һәм кешедә төрле авырулар китереп чыгаручы инфекцияләрнең антибиотикларга каршы торучанлыгы үсү бүгенге медицинаның иң мөһим пробле-

малары булып санала. Онкопатология үсеп баручы илләрдә дә, нык үскән илләрдә дә үлем-китемнәрнең төп сәбәпләреннән берсе булып кала: ел саен дөньяда рактан 9 миллионнан артык кеше үлә, бу барлык үлем-китемнәрнең 17% ын тәшкил итә (https://ourworldindata.org/cancer, 2019). Рак авыруының йөздән артык нозологик формасы билгеле, аларның һәрберсе сәбәпләре һәм барлыкка килү шартлары ягыннан аерыла. Бу яман шешкә каршы торуның бер-берсенә охшамаган механизмлы чараларын эзләргә мәҗбүр итә.

XX гасырның 70 еллары уртасы антибиотикларга тотрыклы каршы тора алучан бактерияләрнең тиз үсеше белән билгеләнә (MRSA – *Staphylococcus aureus* – метициллинга бирешми, VRSA – *Staphylococcus aureus* –ванкомицинга тәэсир итми һ.б.). Бу хәл дәвалауга авыр бирешә торган инфекцияләр саны артуга китерә һәм халыкның сәламәтлегенә яный торган җитди куркынычка әверелә. 2018 елда Америка Кушма Штатларында һәм Европада тотрыклы инфекцияләрдән 50000 гә якын кеше үлә, 2050 елга бу сан дөнья күләмендә бер елга 10 млн га җитәргә мөмкин [Zaman *et al.*, 2017]. Шулай итеп, онкологик һәм инфекцион чирләргә каршы яңа дарулар һәм дәвалау ысуллары табу фәнни һәм коммерция ягыннан мөһим төс ала. Әйтергә кирәк, 1981–2002 еллар арасында уйлап табылган даруларның 60% табигый чыганакларны файдаланып эшләнгәннәр [Joseph and Priya, 2010]. Соңгы ун елда үсемлекләрдәге яңа биоактив метаболитларны һәм микроорганизмнарны өйрәнү гаять активлашты, бу химик һәм молекуляр-генетик анализ методларының камилләшүе, биосинтез механизмнарын өйрәнергә һәм бу процессны нәтиҗәле дәвалау чаралары булдыру өчен кулланырга ярдәм итә торган яңа биотехнологияләр, нанотехнологияләр үсү белән аңлатыла.

Кешелек дөньясы бик борынгы заманнардан бирле үсемлекләрне төрле авырулардан дәва буларак куллануга карамастан, хәзерге көнгә безнең планетада үсә торган 300 000 төр үсемлекнең нибары 10% ы гына дәвалау үзенчәлеге ягыннан өйрәнелгән [Iqbal *et al.*, 2017].

Казан федераль университетының микробиология кафедрасында соңгы биш ел дәвамында төрле географик зоналарда үскән үсемлекләрнең яман шешкә каршы егәре өйрәнелә. Бу тикшеренүләр Мисырдагы Асьют шәһәре университеты белән берлектә, Россия фундаменталь тикшеренүләр фондының халыкара гранты кысаларында башланды. Мисырлы коллегалар тарафыннан Мисырның төрле төбәкләрендә үскән һәм *Agavaceae семьялыгына* керә торган биш төрдәге үсемлекнең төрле кисәкләреннән сыгынтылар (экстракт) әзерләнде. Суккулентлардан булган бу үсемлекләр, кызу һәм коры табигать шартларында җитешеп, үзләренә уникаль биоактив метаболитлар тупларга сәләтле дип фараз ителә. Безнең тикшеренүләр күрсәткәнчә, 8 сыгынтының 4 е – 4 төркемчә яман шеш күзәнәкләренең яшәүчәнлеген тоткарлауга сәләтле: кеше үпкәсендәге A549 аденокарциномнары һәм эчәклектәге өч төркемчәне – SW837, HuTu80 һәм Colo320. Әйтергә кирәк, сыгынтыларның эчәклектәге шеш

күзәнәкләренә каршы цитотоксик эффекты югары: онкоюнәлешле күзәнәкләрнең 50% ы бүлбеле полиантес (*Polianthes tuberosa*), җепсыман юкка (*Yucca filamentosa*), гигант фуркрея (*Furcraea gigantea*) *үсемлекләре* сыгынтысын сыек хәлендә (48–100 мкг/мл) файдаланганда ук күзәтелә [Камалова с соавт., 2016; 2019]. Бактериаль *Bacillus pumilus* РНКазасы (биназа) һәм үсемлек сыгынтыларының бергә тәэсир итү өйрәнү нәтиҗәләре аерата кызыклы. Бу ферментның төрле төрләрдәге шешләргә каршы эффекты КФУның микробиология кафедрасында Татарстан Фәннәр академиясе академигы, биология фәннәре докторы, профессор О.Н. Ильинская җитәкчелегендә алып барылган күпсанлы тикшеренүләрдә раслана. Хәзерге вакытта безнең тарафтан *P. tuberosa, Y. filamentosa* яфраклары сыгынтысы һәм биназаның берьюлы тәэсир итүе нәтиҗәсендә күпчелек очракларда синергетик эффект күзәтелү дәлилләнде. Ул эчәклектәге HuTu80 шеш күзәнәкләренә каршы цитотоксик активлыкны, сыгынтылар һәм *Bacillus pumilus* РНКазасы аерым-аерым тәэсир итү белән чагыштырганда, гаять нык арттырырга ярдәм итә. *Agavaceae семьялыгына* кергән үсемлекләрдән алынган сыгынтыларның шешкә каршы тору егәре Я.Н. Камалованың, биология фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсе алу өчен, хәзер яклауга әзерләнә торган диссертациясендә дәлилләнә.

Шеш хасил булу һәм аның үсүе – катлаулы күпбаскычлы процесс. Шуңа да онкопатологияләрне барлыкка китермәүгә, ягъни шеш авырулары профилактикасына игътибар бирү мөһим. Соңгы елларда алып барылган тикшеренүләрдә кеше организмында тайпылышлар (патологик процесслар) башлануның бер әһәмиятле сәбәбе итеп күзәнәкнең зарарлануы (окислительный стресс) – анда ирекле радикалларның чиктән тыш күп туплануы, нәтиҗәдә ДНКга зарар килү һәм мутацияләр, һәм, үз чиратында, гадәти күзәнәкләрнең шеш күзәнәкләренә әйләнүе күрсәтелә. Безнең төркем алып барган тикшеренүләр, үсемлекләрдәге, аерым алганда, Мисырда үскән цилиндрсыман сансевиерия (*Sansevieria cylindrical*), *өчсызыклы* сансевиерия *Sansevieria trifasciata,* бүлбеле полиантес (*Polianthes tuberosa*), башлы тимьян (*Thymus capitatus*) [Karamova *et al.,* 2016], шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә таралган гади канлы үлән (*Chelidonium majus*), үги ана яфрагындагы (*Tussilago farfara*) [Karamova *et al.*, 2011] метаболитларның антиоксидант һәм антимутаген активлыгын дәлилләде.

Соңгы ун елда дәвалау учреждениеләрендә микроорганизмнарның микробларга каршы торучы препаратларга күнеккән госпиталь штаммнары хастаханә эчендәге пациентларга йога торган респиратор инфекцияләр аеруча куркыныч тудыра башлады. Гомумән алганда, медицина учреждениесенә мөрәҗәгать иткән пациентларның 10% ы хастаханә эчендәге инфекцияләрне (ВБИ) йоктыра. Шунысын да әйтергә кирәк, мондый авыруларның ешлыгы үсеп килүче илләрдә, нык үскән илләр белән чагыштырганда, югарырак. Бу күренеш гомумән алганда медицина дәрәҗәсенең түбән булуы һәм ВБИга җитәрлек

игътибар бирелмәү, аны контрольдә тоту өчен тиешле финанслар бүленмәү белән аңлатыла [Danasekaran *et al*., 2014]. Үсеп килүче илләрдә яшәүчеләрнең күпчелеге традицион (халык) медицинасына яхшы мөнәсәбәттә, шуңа күрә фитокушылмалар ярдәмендә препаратлар эшләү мондый илләр өчен перспективалы. Безнең лабораториядә Мисырның Ак диңгез яры буенда үскән башлы тимьян сыгынтысының микробларга, хастаханә эчендәге респиратор инфекцияләргә каршы егәре тикшерелде. Аның нәтиҗәләре Мисырдан килгән аспирант Хәссән Гамал Османның кандидатлык диссертациясендә күрсәтелде, хезмәт исә 2019 елның июнендә уңышлы якланды. Ачыклануынча, башлы тимьян сыгынтысының иң актив фракциясе 12 матдәдән гыйбарәт, аларның 10 ысы микроорганизмнарның хәзерге вакытта антибиотикларга бирешми торган клиник изолятлары үсешенә каршы тора (*Klebsiella pneumoniae*, *Acinetobacter baumannii, Pseudomonas aeruginosa*, *Escherichia coli, Staphylococcus aureus* һ.б.). Шулай итеп, без тикшергән башлы тимьян сыгынтысы микробларга каршы, хастаханә эчендәге респиратор инфекцияләрне дәвалау өчен, яңа препаратлар эшләүдә нәтиҗәле кулланыла ала.

Яңа дәвалау препаратлары булдыру өчен, биоактив кушылмаларның тагын бер чыганагын – эндофит микроорганизмнарны кулланылырга мөмкин. Эндофитлар – микроорганизмнарның үсемлекләрдәге эчке тукымаларда яши торган төре. Безнең организмның микрофлорасы кебек үк, эндофит микрофлора үсемлекләргә гомеостазны тотрыклыландырырга, үсәргә ярдәм итә, аларны фитопатогеннардан саклый. Татарстан Республикасы территориясендә таралган гади меңьяфракны (*Achillea millefolium* L.) өйрәнгәндә, без эндофит микроорганизмнарның 11 изолятын аерып чыгардык [Хассан с соавт., 2017]. Микробларга каршы егәрне микроорганизмнарның клиник изолятына нисбәтле тикшерү *Streptomyces zaomyceticus* GI01 [Karamova *et al*., 2018] дип аталган штаммны күрсәтте. Без бу микроорганизм тарафыннан эшләнә торган метаболитларның хастаханә эчендәге респиратор авыруларны китереп чыгаручыларга каршы тора алуын, димәк, инфекцияләр китереп чыгаручыларга каршы көрәшү өчен, перспективалы кандидатлар булуын ачыкладык.

Йомгаклап, шуны ассызыклыйсы килә: табигый кушылмаларның тәэсир итү механизмын өйрәнү һәм аңлау төрле патологияләрне уңышлы дәвалау өчен фәнни база була ала. Бу юнәлештә төрле белгечләрнең бергәләп эшләве генә уңышка китерергә мөмкин.

## Әдәбият

1. Cancer death rates are falling; five-year survival rates are rising. Our World in Data // https:// https://ourworldindata.org/cancer-death-rates-are-falling-five-year-survival-rates-are-rising, 2019.

2. *Камалова Я.Н.* Цитотоксическое и апоптозиндуцирующее действие экстрактов растений семейства Asparagaceae по отношению к клеткам аденокарциномы легких человека // Я.Н. Камалова, В.А. Штырева, Абдул-Хафиз Иссам, Х.М. Ибрагим Омер, П.В. Зеленихин, Н.С. Карамова, О.Н. Ильинская // Ученые

записки Казанского университета. Сер. Естественные науки. 2016. Т. 158, кн. 3. С. 338–350.

*3. Камалова Я.Н.* Растительное сырье как потенциальный источник противоопухолевых агентов / Я.Н. Камалова, Н.С. Карамова, П.В.Зеленихин, Иссам Абдул-Хафиз, О.Н. Ильинская // Ученые записки Казанского университета. Сер. Естественные науки. 2019 (в печати).

*4. Danasekaran, R.* Prevention of healthcare-associated infections: protecting patients, saving lives / R. Danasekaran, G. Mani, K. Annadurai // Int. J. of Community Medicine and Public Health. 2014. V. 1, N. 1. P. 67–68.

*5. Joseph B.* and *Priya R.M.* Bioactive Compounds from Endophytes and their Potential in Pharmaceutical Effect: A Review / B. Joseph and R.M. Priya // American Journal of Biochemistry and Molecular Biology. 2011. V. 1 (3). P. 291–309.

*6. Iqbal, J.* Plant-derived anticancer agents: A green anticancer approach / J. Iqbal, B.A. Abbasi, T. Mahmood, et al. // As. Pacific J. Tropical Biomedicine. 2017. V. 7, N. 12. P. 1129–1150.

*7. Karamova, N.* Antioxidant and antimutagenic potential of extracts of some *Agavaceae* family plants / N. Karamova, S. Gumerova, G. Hassan, E. Abdul-Hafeez, O. Ibrahim, M. Orabi, O. Ilinskaya // BioNanoScience. 2016. V. 6, no. 4. P. 591–593.

*8. Karamova N.S.* An Investigation of Antigenotoxic Properties of Plant Extracts of *Chelidonium majus* L., L. and *Tussilago farfara* L. / Karamova N.S., Fatykhova D.G., Abdrakhimova Y.R., Il'inskaya O.N. // Russian Journal of Genetics: Applied Research. 2011. Vol. 1, P. 371–378.

*9. Karamova, N.S.* Streptomyces zaomyceticus strain GI01 16S ribosomal RNA gene, partial sequence / N.S. Karamova, G.O. Hassan, I.R. Yagudina and A.M. Mardanova// https://www.ncbi.nlm.nih.gov/nuccore/MK290373.

*10. Хассан Г.О.О.* Антимикробный потенциал эндофитных актинобактерий лекарственных растений / Г.О.О. Хассан, И.Р. Ягудина, Н.С. Карамова // Вестник Оренбургского государственного университета. 2017. № 9 (209). С. 106–110.

*11. Zaman, S.B.* A Review on Antibiotic Resistance: Alarm Bells are Ringing / S.B. Zaman, M.A. Hussain, R. Nye, V. Mehta, K.T. Mamun, N. Hossain // Cureus. 2017. V. 9, N. 6. P. 1–9.

***Кәрамова Нәзира Сөнгать кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының микробиология кафедрасы доценты*

УДК 811.512.145

*Ч.М. Куракова*

# КҮРЕНЕКЛЕ ТАТАР ГАЛИМЕ ГАБДРАХМАН СӘГЪДИНЕҢ ТУУЫНА – 130 ЕЛ

Статья посвящена жизни и научной деятельности известного востоковеда, специалиста в области истории татарской и узбекской литературы, доктора филологических наук Габдрахмана Сагди. Автор статьи рассматривает наследие ученого не только в области литературоведения, но и освещает его общественно-педагогическую деятельность.

**Ключевые слова**: Габрахман Сагди, литературоведение, научная деятельность, ученый, филолог.

The article is devoted to Gabdrahman Sagdi's life and research activity, a famous orientalist, a specialist in the history of Tatar and Uzbek literature, Doctor of Philology. The author of the article not only considers the scholar's legacy in the terms of literary criticism, but also highlights his social and pedagogical activity.

**Keywords:** Gabdrahman Sagdi, literary criticism, research activity, scholar, philologist.

Габдрахман Сәгъди – XX йөз башы татар мәдәни дөньясы үстергән күренекле шәхесләрнең берсе. Тәҗрибәле педагог, киң эрудицияле лингвист, зур әзерлекле методист һәм әдәбият нәзариячесе, принципиаль тәнкыйтьче, эзләнүчән әдәбият тарихчысы, оста лектор, абруйлы җитәкче булып танылган бу галим үзенең бөтен көчен, бар талантын мәгариф, фән һәм мәдәният өлкәсенә хезмәт итүгә багышлый, филология белгечлеге буенча татарлардан беренче профессор һәм беренче фән докторы дигән гыйльми дәрәҗәгә ирешә. Быел киң җәмәгатьчелек әлеге мөхтәрәм затның тууына 130 ел тулуны билгеләп үтә.

Габдрахман Гайнан улы Сәгъдиев (Габдрахман Сәгъди) 1889 елның 27 (14) мартында элеккеге Уфа губернасы Златоуст өязе Морзалар волосте (хәзерге Башкортостан республикасы Салават районы) Таймый авылында (элеккеге атамасы – Атау) рухани гаиләсендә дөньяга килә. Башта үз авылларындагы мәктәптә, 1902 елдан Троиц шәһәрендәге мәшһүр «Рәсүлия» мәдрәсәсендә белем ала. Бирегә гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнә, Көнчыгыш фәлсәфәсе, тарихы белән кызыксына, күп эзләнә, укый. Ул госманлы төрек, гарәп телләрен камил үзләштереп, теләүчеләргә шул фәннәрдән аерым дәресләр бирә башлый. Моның белән, беренчедән, матди ягын ныгытса, икенчедән, сабакташлары арасында дәрәҗәсе күтәрелә, өченчедән, мөгаллимлек эшендә тәҗрибә туплауның беренче адымнары ясала.

1906 елда мәдрәсәне тәмамлаганнан соң, Г. Сәгъди ике ел дәвамында үз өязендәге Таймый һәм Мәчетле авылларының рус-татар

мәктәпләрендә балалар укыта. Шушы елларда үзлегеннән һәм аерым укытучыдан рус телен өйрәнә. Алдынгы карашлы туплаган яшь мөгаллим милли мәдәниятктә, фәнгә хезмәт итәргә омтыла. Моның өчен мәдрәсәдә алган белеме генә җитенкерәмәвен аңлап, укуын рус югары уку йортында дәвам итәргә тели. Әмма фәкыйрьлеге аркасында, бу юлдагы киртәләрне уза алмыйча, бәхет эзләп Төркиягә китәргә мәҗбүр була. Үзлегеннән әзерләнеп, Истанбулдагы Төркия Дәүләт университетына имтихан тота. 1908–1911 елларда шушы уку йортының филология факультетында «төрки-татар әдәбиятлары тарихы» белгечлеге буенча югары филологик белем ала. Биредә гарәп, төрек, фарсы әдәбиятлары, төрек әдәби теле, аның стилистикасы һәм поэтикасы, риторика һ.б. фәннәрне үзләштерә.

1911 елда Төркиядән укуын тәмамлап кайтуга, Г. Сәгъди укытучылык эшен дәвам иттерә. Февраль инкыйлабына кадәр Башкортстан республикасының төрле авыл-шәһәрләрендә, Казакъстанның Актүбә, Алма-Ата, Ыргыз шәһәрләрендә, Екатеринбург өлкәләрендә мөгаллимлек итә, мәктәп мөдире вазифаларын башкара. Мәктәп-мәдрәсәләрдә заманча укытуны тормышка ашыру, милли-мәдәни хәрәкәтнең үзәгендә кайнау, кадими фикерләргә каршы көрәш нәтиҗәсендә, яшь мөгаллим 1913 елдан сәяси күзәтү астына эләгә. Туктаусыз эзәрлекләнеп, яшәү урыннарын еш алыштырырга, качып яшәргә, шундый шартларда гыйльми һәм академик эшчәнлек алып барырга мәҗбүр була. Шулай итеп, бу елларда ул Оренбург, Уфа, Казакъстан, эчке Рәсәй буйлап хәрәкәт итәргә мәҗбүр була.

Октябрь инкыйлабы көннәрендә Г. Сәгъди Бөгелмәдә өч айлык татар-башкорт педагогия курсларында мөгаллимлек итә. Аның инициативасы белән бу курслар өч еллык педагогия курсларына әйләндерелә, нәтиҗәдә Бөгелмә Укытучылар семинариясына нигез салына. Г. Сәгъди башта курсларга, аннары семинарияга җитәкчелек итә. Бер үк вакытта 4 ел дәвамында (1917–1921) татар әдәбияты һәм педагогика, тел һәм әдәбият укыту методикасы фәннәреннән дәресләр алып бара. Бөгелмә чоры Г. Сәгъдине остазлык ягыннан тагын бер баскычка күтәрә, ул инде укытучылар әзерләү эше белән шөгыльләнә башлый. Төп игътибары педагогика («Фәне тәрбия дәресләре» (Педагогика дәресләре)), дидактика («Фәне тәрбия вә тәгълим» (Педагогика һәм дидактика)) һәм методика мәсьәләләренә юнәлтелә.

1921–1925 елларда Г. Сәгъди Урта Азиянең Үзбәкстан республикасында яшәп, төрле югары уку йортларында хезмәт куя. Ташкентта үзбәк (ирләр һәм хатын-кызлар) мәгариф институтларында, Урта Азия дәүләт университетының рабфакларында, Ленин исемендәге хәрби мәктәптә – үзбәк классик әдәбиятыннан, ә төрки-татар мәгариф институтында татар әдәбияты, педагогика, тел һәм әдәбият укыту методикаларыннан лекцияләр укый. Бу дәвердә ул Шәрык әдәбияты, педагогикасы, фәлсәфәсе белән кызыксына, лекция укырлык дәрәҗәдә үзбәк телен үзләштерә.

1925 елның көзендә Г. Сәгъди, Г.Ибраһимов чакыруы буенча, Казанга килә. Монда килгән көннән 1930 елга кадәр Татар Коммунистлар университетында, Педагогия техникумында татар әдәбияты тарихын укыта. 1926 елда Казан Көнчыгыш педагогия институтына доцент булып сайлана. Анда татар теле һәм әдәбияты кафедрасын, шулай ук әдәбият кабинетын оештырып җибәрә.

Г. Сәгъдинең тормыш һәм иҗат юлында Казан чоры (1925–1930) – гыйльми эшчәнлегенең иң нәтиҗәле өлешләреннән берсе. Югары уку йортларында тыгыз график белән эшләве өстенә, ул татарның фәнни һәм иҗтимагый дөньясында да төп көчләрдән санала. Совет язучылары җәмгыятендә, фән эшлеклеләре секциясендә, идарә әгъзасы буларак, бу оешмалар үткәргән чараларда актив катнаша. Әдәби хәрәкәттәге актуаль проблемаларны күтәргән докладлар уку, әдәбият мәсьәләләре турында фикер алышу, диспутлар оештыру да вазифа төсендә йөкләнә. Шулай ук Гыйльми Үзәк каршындагы «Татар педагогия җәмгыяте», «Татарларны өйрәнү җәмгыяте» (Татароведение) белән дә хезмәттәшлек итә.

Казанда эшләгән чорында галим утызлап гыйльми хезмәт яза. Алар арасында иң танылганнары – «Татар әдәбияты тарихы» (1926), «Кешелек дөньясында, тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» (1926), «Татар театр әдәбияты һәм аның үсү тарихы» (1926), «Галимҗан Ибраһимов һәм аның әдәби иҗатлары» (1928), «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» (1930). Галимнең « Символизм турында» (1932) исемле китабы да 1929 елда язып тәмамлана.

Г. Сәгъди – әдәбиятчы галим генә түгел, киңкырлы филолог та. Гыйльми эзләнүләренең башлангыч чорыннан ук ул, әдәбият фәне белән беррәттән, тел гыйлеме мәсьәләләре белән дә кызыксына. «Телебезнең сарыфы» (1913), «Телебезнең нәхүе» (1914), «Үз телебездә мөкәммәл сарыф-нәхү» (1915) һ.б. китаплары мәктәп дәреслекләре рәвешендә дөнья күрә. Лингвистика мәсьәләләрен чишү Г. Сәгъди гыйльми эшчәнлегенең башка чорларында да дәвам иттерелә («Сарыф-нәхү әсаслары» (1925) һ.б.). Галимнең төрки телләр, борынгы төрки язмачылык, язу барлыкка килү турындагы эзләнүләре аерым бер катламны тәшкил итә һәм төрле телләрдә дөнья күрә. Мәсәлән, «Төрек телләренә классификация ясау мәсьәләсе» (1925), «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» (1926); «Принципы изучения и становления законов тюркских языков» (1922), «Из истории письменности» (1923, үзбәк телендә); «Как у людей возник язык?» (1922), «Языки тюркских племен и литература на этих языках» (1923), «Наука о языке и языкознании» (1923–1924, төрекмән телендә). Борынгы гомумтөрки истәлекләрнең теле, үзбәк совет әдәби теле үсеше хакындагы 1950 елларга караган язмалары басылмый кала. Г. Сәгъдинең тел гыйлеме мәсьәләләрен өйрәнеп язылган кандидатлык диссертацияләренә рәсми оппонент итеп билгеләнүе фәнни даирәләрдә аның тел белгече буларак та зур абруй казануы турында сөйли.

1930 елда Г. төпләнеп урнашып, хезмәт юлын Педагогия академиясендә дәвам итә. 1932 елдан гомеренең ахырына кадәр Үзбәкстан республикасының төрле шәһәрләрендәге (Сәмәрканд, Ташкент, Фирганә) күпсанлы югары уку йортларында профессорлык вазифасын башкара. Моннан тыш, Сәмәрканд шәһәрендәге Үзбәк дәүләт фәнни-тикшерену институты аспирантларына да консультацияләр бирә. Шулай итеп, ул инде мөгаллим, профессор гына түгел, чын мәгънәсендә Остазга әверелә.

Вузларда укыту белән беррәттән, Г. Сәгъди СССР Фәннәр Академиясенең Үзбәкстан филиалында, Тел-әдәбият институтларында хезмәттәшлек итә. Фәнни тикшеренүләрен үстереп, бәхәсле әдәби-гыйльми киңәшмәләрдә үзбәк әдәбияты, аның үсеш юллары турында докладлар, матбугат битләрендә мәкаләләр белән чыгыш ясый. Чирек гасырдан артык үзбәк халкына мәгърифәт таратып, үзбәк филологиясе фәнен үстерүгә зур өлеш кертә.

Төркестан чорында Г. Сәгъди эзләнүләренең төп юнәлешен Галишер Нәвои иҗатын өйрәнү билгели. Ул Нәвои мирасын өйрәнү фәнен нигезләүгә, үстерүгә, тармакландыруга күп көч куя. Рус һәм үзбәк телләрендә язылган һәм басылып чыккан тугыз исемдәге 18 хезмәтендә шагыйрь иҗаты төрле яссылыкта тикшерелгән. 1949 елда Г. Сәгъди «Үзбәк классик әдәбияты үсешенең югары этабы буларак Нәвои иҗаты» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. Галимнең шушы юнәлештә 28 исемдәге эзләнүләре кулъязма хәлендә калган.

Г. Сәгъди 1956 елның 6 ноябрендә 67 яшендә каты авырудан вафат була.

Шул рәвешчә, Г. Сәгъдинең тормыш һәм иҗат баскычларын күзәтү аның мөгаллимлек, гыйльми, иҗтимагый эшчәнлегенең күп аспектлы, киңкырлы һәм фундаменталь булуын расларга мөмкинлек бирә. Аның мирасын өйрәнү, хезмәтләрен барлау, халыкка кайтару эше дәвамлы булсын иде.

***Куракова Чулпан Малик кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан дәүләт*
*аграр университетының Икътисад институты доценты*

УДК 821.512.145

***Ф.С. Баязитова***

# ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ЛАТЫЙФ ҖӘЛӘЙНЕҢ ОЛЫ МИРАСЫ (Күренекле тел галиме Латыйф Җәләйнең тормыш юлы һәм фәнни эшчәнлегенә карата)

Доктор филологических наук, профессор Латыф Заляй (Латыйф Җәләй) – выдающийся ученый-языковед, литературный критик и педагог (1894–1966). Он внес огромный вклад в развитие татарского языкознания в нескольких направлениях: диалектологии и истории языка, исторической грамматики, фонетики, культуры речи и др. Его труды являются ценным источником для языковедов и других ученых. Особенно важна заслуга профессора Л. Заляя в формировании и развитии татарской диалектологии как науки.

**Ключевые слова:** история языка, историческая морфология, фонетика, орфоэпия, статьи-рецензии, лексика, словари, научные кадры, диалектология, экспедиции.

Doctor of Philology, Professor Latif Zalyai (Latyif Jyalyai) is an outstanding scholar-linguist, literary critic and teacher (1894-1966). He made a huge contribution to the development of Tatar linguistics in several directions: dialectology and the history of language, historical grammar, phonetics, speech culture, etc. His works are a valuable source for linguists and other scholars. Professor L. Zalyai's merit in the formation and development of Tatar dialectology as a science is of particular importance.

**Keywords:** history of language, historical morphology, phonetics, orthoepy, review articles, vocabulary, dictionaries, scientific personnel, dialectology, expeditions.

Татар теле белеменә зур өлеш керткән өлкән буын галимнәр Җ. Вәлиди, Х. Бәдигый, Г. Сәгъди, М. Корбангалиев, Г. Алпаров, Г. Шәрәф, Г. Ибраһимов, Ш. Рамазанов, В. Хангилдин, Р. Газизов һ.б. арасында профессор Латыйф Җәләй эшчәнлеге үзенә бер аерым урын алып тора.

Латыйф Җәләй 1894 елның 17 ноябрендә хәзерге Ульяновск өлкәсе, Майна районы, Иске Кызыл Су (Тат. Урайкино) авылында туа. Фәнгә Л. Җәләй катлаулы юллар үтеп килә. ул тормышның ачысын-төчесен бик иртә татый башлый. Кышларын мәхәллә мәктәбендә укый. Аны тәмамлаганнан соң, 1906 елда Мәләкәс мәдрәсәсенә укырга керә, ләкин, әтисе үлеп китү сәбәпле, 13 яшеннән Мәләкәс шәһәрендә сезонлы эшче-йөкче булып эшли башлый. Бик авыр шартларда яшәвенә дә карамастан, Латыйф ага, үзенең чиксез тырышлыгы аркасында, заманына күрә ярыйсы гына төпле белем ала. Мәдрәсәне уңышлы тәмамлаганнан соң, 1911 елда ул Самара губернасы Иске Җүрәй авылына мөгаллим-укытучы булып китә.

1914 елның башында ул, дөнья күрү теләге белән, Урта Азиягә юл тота. Ташкентта җәен җиләк-җимеш бакчаларында кара эшче, ә кышын пешекче булып эшли. 1915–1917 елларда солдат хезмәтен-

дә була, Беренче бөтендөнья сугышына җибәрелә. 1917 елның ахырларында Латыйф Җәләй фронттан туган якларына кайта, яңадан укытучылык эшенә керешә, төрле авылларда беренче баскыч мәктәпләрендә укыта һәм үзенең белемен күтәрү өстендә эшли. 1921 елны, алдынгы укытучы сыйфатында, аны Самара шәһәренә күчерәләр. Анда ул 1932 елга кадәр төрле мәктәпләрдә, педагогия техникумында татар теле укытучысы, балалар йорты мөдире, мәктәпләр инспекторы булып эшли. Шул елларда ук уку-укытуның аерым мәсьәләләре буенча китаплар бастыра, фәнни күзәтүләр алып бара, беренче баскыч мәктәпләр өчен кулланмалар төзи.

1932 елда Латыйф Җәләй Самара педагогия институты каршындагы аспирантурага укырга керә, 1933 елны Казан педагогия институтына күчеп, аспирантурада укуын дәвам иттерә һәм 1935 елда аны тәмамлап, шул ук институтның татар теле һәм әдәбияты кафедрасында укытучы булып эшли башлый. Шушы елларда булачак галимнең тел тарихы, диалектларны өйрәнү белән кызыксынуы тагын да көчәя. Казан педагогия институтының татар теле кафедрасында башланып киткән укытучылык эшчәнлеге шушы юнәлештәге фәнни-тикшеренү эшләре белән үрелеп бара. Бу эшне ул Казан дәүләт университетының тел кафедрасына күчкәч тә (1944 ел) дәвам иттерә, тел тарихы, грамматика һәм диалектология курсларын төзеп, шулар буенча студентларга лекцияләр укый.

1939 елда Л. Җәләй, укытучылык эшен дәвам иттергән хәлдә, Татарстан Мәгариф Халык комиссариаты карамагындагы Татарстан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институтында (хәзер Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) эшли башлый, 1956 елдан 1962 елга кадәр тел бүлеге мөдире вазифасын да башкара. Бу елларда аның фәнни-иҗади эшчәнлеге тагын да активлаша.

Галимнең фәнни эшчәнлеге гаять күп тармаклы. 30–50 елларда вакытлы матбугат («Мәгариф», «Совет мәктәбе», «Совет әдәбияты» журналлары, «Кызыл таң», «Кызыл Татарстан», «Социалистик Татарстан», «Совет Татарстаны» газеталары һ.б.) битләрендә һәм төрле җыентыкларда татар тел белеме һәм әдәбиятының актуаль мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре, рецензияләре, укытучыларның сорауларына җаваплары бер-бер артлы басылып торалар. Шулар белән танышып чыгу гына да аның киң колачлы, эрудицияле, өлгер каләмле фән эшлеклесе булуын тулы күзалларга мөмкинлек бирә.

Татар әдәбиятын яхшы белү, аның үткәне һәм хәзергесе белән нык кызыксыну яшь белгечне әдәби тәнкыйть дөньясына алып керә. 30–40 елларда ул шушы өлкәдә җитди эшчәнлек күрсәтә. Татар әдәбиятын үстерүдә, яшь язучыларны тәрбияләүдә кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша, әдәбиятка яңа аяк баскан яшь галимнәрнең беренче адымнарын ныклап күзәтеп бара, аларның телстиль үзенчәлекләрен өйрәнү буенча җитди тикшеренүләре бүген дә актуальлеген югалтмаган. К. Насыйри, Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Ш. Ка-

мал, Г. Бәшир, С. Хәким, К. Нәҗми, Ә. Еники, М. Әмир, А. Расих һәм башка кайбер татар язучыларының иҗатларына карата язылган 60 тан артык мәкалә-рецензия шундыйлардан. Шуның өстенә галим башлангыч мәктәп укытучылары өчен диктантлар җыентыгы, урта мәктәпнең VIII сыйныфы өчен татар әдәбияты буенча дәреслек, әдәбияттан дәреслек-хрестоматияләр, укытучылар өчен төрле методик кулланмалар, программалар төзи.

Танылган башкорт теле белгече, профессор Җ.Г. Киекбаев билгеләгәнчә, «Л. Җәләйнең башка татар телчеләреннән аермасы шунда, ул татар тел гыйлеменә юнәлеш керткән зур галим: нәкъ менә ул татар телен тарихи, чагыштырмалы планда өйрәнүгә нигез салучы».

Чыннан да, Латыйф Җәләй татар тел белеменең ике зур катламын (тел тарихын һәм диалектологияне) күтәреп фән киңлегенә чыгара. Аның тел тарихына багышланган беренче хезмәте «Татар теле тарихының кайбер мәсьәләләре» дип атала. Анда, нигездә, тарихи грамматика проблемалары яктыртыла. Автор бу хезмәтен 1942 елда М.В. Ломоносов исемендәге Мәскәү университетында кандидатлык диссертациясе итеп яклый һәм, татар теле белеме буенча беренчеләрдән булып, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә лаек була.

«Татар теленең фонетикасы буенча материаллар» (1954) дигән тикшеренүендә Л. Җәләй татар теленең фонетик системасындагы төп үзгәрешләрне күзәтеп чыга. Татар әдәби теленең нормалашу процессын өйрәнү, аның әйтелеш нормаларын эшкәртү һәм конкрет системага салу кебек гаять катлаулы, актуаль проблеманы хәл итүдә дә Латыйф Җәләй актив катнаша. «Татар теленең орфоэпик нигезләре» (1953) дигән китабы әнә шул мәсьәләгә багышланган.

Галимнең тел тарихы буенча соңгы һәм иң зур хезмәте «Татар теленең тарихи морфологиясе буенча очерклар» дип исемләнә. Ул хезмәтнең кулъязмасы, басмага әзерләнгән хәлендә, Институт архивында саклана иде. Ниһаять, 2000 елда Институтның тырышлыгы белән бу хезмәт дөнья күрде (китапның редакторы – филология фәннәре кандидаты Ф.С. Фасеев).

Тарихи грамматика белән беррәттән, Латыйф Җәләй татар диалектларын өйрәнү буенча да күп һәм зур эшләр башкара. Мәгълүм булганча, татар диалектлары инде күптән, Октябрь инкыйлабына кадәр үк тикшерелә башлаган. Татар диалектологиясе белән теге яки һу дәрәҗәдә В.В. Радлов, А.Г. Бессонов, Н.Ф. Катанов, С.Е. Малов һәм башка галимнәр шөгыльләнәләр. Ләкин әле татар диалектологиясе системалы тикшерелгән аерым фән югарылыгына күтәрелә алмый.

Октябрь инкыйлабыннан соң татар диалектологиясе белән күренекле тел галиме Җ. Вәлиди кызыксына һәм бу өлкәдә шактый эш башкара. Эстафета Җ. Вәлиди кулыннан Л. Җәләйгә күчә һәм шуннан соң татар диалектлары эзлекле рәвештә бөтен киңлеге һәм тирәнлеге белән өйрәнелә башлый.

Галим диалекталь фактлар өстендә эшләү, халыкның җанлы сөйләү телендәге үзенчәлекләрне җыю, аларны төркемләү бик җитди фәнни эш итеп каралырга тиеш, дигән фикерне алга сөрә. «Халык телендәге диалекталь фактлар тиешенчә өйрәнелмәгәнлектән, әдәби телнең үзенә яраклы материаллары таркау яталар, хәлбуки, халыкның җанлы телен өйрәнү һәм андагы байлыкны туплау шушы телнең фәнни эшләнешен тиешле югарылыкка күтәрергә ярдәм итә. Шулай булгач, гомумән культура фронтында эшләүче кешеләр халкыбызның җанлы телен өйрәнүгә әһәмият бирергә тиешләр», – дип яза Л. Җәләй «Татар диалектологиясе» (Казан, 1947, 127 б.) китабында.

Турыдан-туры Латыйф Җәләй катнашында һәм җитәкчелегендә татарлар яшәгән Идел буе һәм Урал төбәкләренә, җирле сөйләшләрне тикшерү-өйрәнү өчен, күпсанлы экспедицияләр оештырыла. Ул татар теле сөйләшләрен өйрәнүдә диалектология фәнендә сыналган анкета методын да куллана һәм, Татарстан төбәкләренә татар теле әдәбияты укытучыларына анкеталар таратып, алар аша кыйммәтле материаллар туплый, диалектологик экспедицияләрдә яшь тикшеренүчеләрне, студентларны «Диалектологик сораулыклар» белән тәэмин итә, алар белән бергә үзе дә бик күп төбәкләрдә, авылларда була. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1947 елда галимнең «Татар диалектологиясе» дигән монографиясе басылып чыга. Галим бу хезмәтендә татар диалектларының өйрәнелү тарихын, аларның классификациясен бирә һәм диалектларның төп үзенчәлекләрен ача.

Болардан тыш, Латыйф Җәләй катнашлыгында өч кисәктән торган «Диалектологик сүзлек» (1948, 1953, 1958) бастырып чыгарыла. Бу сүзлекләрдә экспедицияләр вакытында тупланган лексик материаллар урын ала.

Татар диалектларын практик өйрәнү Латыйф Җәләйгә татар диалектологиясендә хәзер дә капиталь хезмәт саналган монография язарга мөмкинлек бирә. Татар теленең урта диалекты турындагы әлеге хезмәт соңрак докторлык диссертациясе буларак яклана, һәм галим филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗәгә лаек була.

1956 елда «Татар теле белеме алдындагы бурычлар» исемле мәкаләсендә ул татар теленең диалектологик атласын, тулы диалектологик сүзлек һәм татар теленең аңлатмалы сүзлекләрен, татар теле белеме буенча тулы библиография төзүнең кирәклеген, бу проблемаларның көн тәртибенә басканлыкларын күрсәтеп чыга. Әйтергә кирәк, Латыйф Җәләй инициативасы белән башланган бу зур эшләр күп еллар тел секторының һәм диалектология төркеменең җитәкчесе булган Ләйлә Мәхмүтова, галимнең яраткан шәкертләре Наҗия Борһанова, Гасимә Якупова, инде алардан соңгы буыннв тәшкил иткән бер төркем диалектологлар – Зидә Садыйкова, Леонид Арсланов, Фәрит Юсупов, Дөрия Рамазанова, Тәнзилә Хәйретдинова, Флера Баязитова һ.б. тарафыннан уңышлы дәвам иттерелде.

Бүгенге көндә «Татар теленең диалектологик сүзлеге»нең беренче (1969) һәм икенче (1993), «Татар теленең зур диалектологик сүз-

леге» (2009) китаплары басылып чыкты, «Урта Идел һәм Урал төбәге татар халык сөйләшләре атласы» (1989), төрки халыклар арасында беренчеләрдән булып «Атлас татарских народных говоров» (2015) эшләнеп дөнья күрде, «Татар халык сөйләшләре» (2008, ике китапта), аерым сөйләшләргә, этнографик төркемнәргә багышланган дистәдән артык китаплар, фәнни монографияләр басылып чыкты, диалекталь лексиканың аерым тематик төркемнәре җентекләп өйрәнелә һәм бу өлкәдә дә монографияләр чыгып тора. Латыйф ага хыялланган «Татар теленең өч томлык аңлатмалы сүзлеге», «Татар теле белеменең тулы библиографиясе» дә нәшер ителде.

Тел тарихы һәм диалектология – үзара бик тыгыз бәйләнештә тора торган фәннәр. Латыйф Җәләй тикшеренүләрендә тел белеменең бу ике өлкәсе һәрвакыт игътибар үзәгендә тотыла, бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә карала. Шуның өчен галимнең рухы бүгенге көндә диалектологларның эшләгән эшләренә һәм уңышларына сөенеп, хәер-фатиха биреп торадыр кебек һәм без, хәзерге буын диалектологлары, үзебезне, гәрчә турыдан-туры аның лекцияләрен тыңлап, үзен күрү бәхетенә ирешмәгән булсак та, Латыйф аганың шәкертләре дип саныйбыз, тел белеменең шундый кызыклы, игелекле тармагында эшләвебез белән горурланабыз да.

Латыйф Җәләй фәнни кадрлар хәзерләү юнәлешендә дә зур эшчәнлек күрсәтә. Аның фәнни җитәкчелегендә аспирантура үтеп, диссертация яклаган ике дистәгә якын галим – фән докторлары һәм кандидатлары бүгенге көндә дә уңышлы эшләп киләләр.

Педагог буларак, аның үзенә генә хас бик үзенчәлекле уңай сыйфатын шәкертләре әле дә хәтерлиләр: ул студентларны сәгатьләр буе авызына каратып тыңлата белгән, аның лекцияләре һәрвакыт галимнең үз күзәтүләренә, фәнни тикшеренүләренә нигезләнеп, фактик материалларга бай булуы белән аерылып торган.

Ул үзенең хезмәттәшләре, аралашкан кешеләренә карата киң күңелле, эчкерсез киңәшче, кешеләргә игътибарлы, ярдәмчел, туры сүзле галим булган, гыйльми тәҗрибәсе белән чын күңелдән уртаклаша белгән.

Олы галим, күренекле җәмәгать эшлеклесе Латыйф Җәләй 1966 елның 1 августында вафат була.

Тууына 125 ел тулу уңае белән республикабызның киң җәмәгатьчелеге, тюркология дөньясында танылган, татар теле белемендә аеруча күренекле урын тоткан галим һәм педагог, филология фәннәре докторы, профессор Латыйф ага Җәләйне тирән ихтирам белән искә алалар.

***Баязитова Флера Сәет кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК

***А.М. Ахунов***

## ШӘРКЫЯТКӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

В 2019 году исполнилось 90 лет со дня рождения выдающегося советского и российского ученого-востоковеда, археографа и текстолога, доктора филологических наук, профессора Анаса Бакиевича Халидова (1929–2001). Большая часть его жизни была связана с Ленинградом (позже Санкт-Петербургом). Он руководил Арабским кабинетом им. И.Ю. Крачковского и Сектором Ближнего Востока С.-Петербургского филиала Института востоковедения РАН. Он является автором ряда трудов, посвященных арабской рукописной книге, каталогов рукописей, работ касающихся прошлого татарского народа.

**Ключевые слова:** Халидов А.Б. (1929–2001), археография, арабистика, востоковедение в Российской Федерации.

2019 marked the 90th birth anniversary of the outstanding Soviet and Russian scientist-orientalist, archaeographer and textual scholar, doctor of Philology, Professor Anas Bakievich Khalidov (1929–2001). Most of his life was associated with Leningrad (later Saint Petersburg). He was in charge of the Arab Cabinet I.Y. Krachkovsky and the Middle East Sector of the St. Petersburg branch of the Institute of Oriental studies of the Russian Academy of Sciences. He is the author of a number of works devoted to the Arabic manuscript book, catalogues of manuscripts, works concerning the past of the Tatar people.

**Keywords:** Khalidov A.B. (1929–2001), archaeography, Arabic studies, Oriental studies in the Russian Federation.

Атаклы гарәп белгече, профессор Әнәс Бакый улы Халидовның вафатыннан соң унсигез ел үтте. Ул Казанда 2001 елның декабрендә изге Рамазан аенда дөнья куя. Быел аңа 90 яшь тулган булыр иде...

Бу кешенең язмышы гаҗәп кызыклы. Ул 1929 елның 25 февралендә Татарстан АССРның Буа районының зур булмаган Казма (хәзерге Черки-Кощаково) авылында туган, шунда ук башлангыч белем дә алган. Үзенең тырышлыгы, үҗәтлеге һәм таланты нәтиҗәсендә ул академик фәндә югары үрләр яулый, исеме зур хәрефләрдән язылырга тиешле зур галим, гарәп әдәбияты тарихы буенча күренекле белгеч булып танылa. Ә.Б. Халидов Көнчыгыш Европада шәрык кулъязма традициясе һәм мәдәнияте буенча танылган белгеч була, Россиядә беренче гарәпче санала, аның урыны әле озак вакытлар буш торыр…

Ә.Б. Халидовның шундый биеклекләргә ирешүен яхшырак аңлау өчен, аның гаиләсе тарихына мөрәҗәгать итәргә, биографиясен күзәтергә кирәк. Бабасы Мөхәммәткәр мәдрәсәдә укыта, ә Бакый Халиднең этисе Совет заманында гарәп теле дәреслеге авторы буларак танылa. Бакый Халидовның (1905–1968) язмышы да вакыйгаларга бай. Күп кенә яшьтәшләре кебек ул да башлангыч белемне җирле мәдрәсәдә алган. 1920 еллар ахырында язмыш аны Ленинградка китергән. Анда ул күренекле дин белгече Муса Бигиев (1875–1949) белән очраша.

Бакый аның яраткан укучысына әйләнә, аның җитәкчелегендә гарәп телен өйрәнә. Бигиев чит илгә киткәннән соң, ул да чит илләргә еш чыга башлый. Бу вакытта Бакый Халидов үзенең дуслары – Габдрахман (киләчәктә – Ленинградтагы танылган шәркыятьче Г. Таһирҗанов) һәм Габдулла Таһирҗановлар белән бергә, эш эзләп, башта Бакуга, аннары Ашхабадка китә. Әмма тиздән төпле, системалы белемсез калуларын аңлап, яшьләр югары уку йортына укырга керергә карар кылалар. 1934 елда Габдулла Таһирҗанов – Ташкентка, Габдрахман Ленинградка китә, ә Бакый Халидов Казан дәүләт университеты каршындагы рабфакка укырга керә. Аны тәмамлагач, ул 1941 елның гыйнварында шул ук университетның физика-математика факультетында укый башлый.

Югары белем алгач, Бакый Халидов гаиләсен шәһәргә алырга карар кыла. Шул рәвешле, Әнәс тә Казанга килә һәм 50 нче урта мәктәпнең бишенче сыйныфында укуын дәвам иттерә. Аның сөйләүләренә караганда, уку аңа җиңел бирелмәгән, чөнки рус телен ул әллә ни яхшы белмәгән. Шул ук елны аның әтисен Ташкент обсерваториясенә җибәрәләр. Әнәс Халидов Казанда өч ел берүзе яши. 1941 елда Бакый Халидовны армиягә алалар һәм хәрби тәрҗемәче сыйфатында Иранга җибәрәләр. Сугыш тәмамланганнан соң, 1945 елда Б. Халидов Ташкентка кайта, хәрби округта тәрҗемәче булып эшли һәм бер елдан Ташкент университеты каршында яңа оештырылган көнчыгыш телләре факультетына фарсы, пушту һәм гарәп теле укытучысы итеп билгеләнә. 1952 елда ул пушту теле буенча диссертация яклый. 1953–1958 елларда – Иран-әфган кафедрасы мөдире, ә 1958 елдан гарәп филологиясе кафедрасы мөдире була. Ташкентта ул гомеренең ахырына кадәр яши (1968).

Әнәс Халидов көнчыгыш фәннәрен өйрәнергә карар итә. 1946 елда ул Ленинград дәүләт университетына укырга керә. Аның хыялы тормышка аша: 1951 елда әлеге университетның Көнчыгыш факультеты гарәп бүлеге студенты була. Аны тәмамлагач, сәләтле һәм тырыш укучыны СССР Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының Ленинград бүлеге аспирантурасына укырга чакыралар. Биредә ул 1954 елга кадәр укый һәм 1955 ел башында Мисыр язучысы Таһа Хөсәен иҗаты буенча кандидатлык диссертациясе яклый. Яклаудан соң шунда ук кече фәнни хезмәткәр итеп эшкә алына, классик гарәп әдәбиятын тикшерү белән шөгыльләнә. Алга таба аның бөтен тормышы шушы институттагы эшчәнлеге белән бәйле булачак.

1961 елда аны СССР ФА Көнчыгышны өйрәнү институтының Ленинград бүлеге каршындагы И.Ю. Крачковский исем. Гарәп кабинеты (1978 елдан – Якын Көнчыгыш секторы) мөдире итеп билгелиләр. Ә.Б. Халидов бу секторны 2000 елга кадәр җитәкли. Фәнни-тикшерену эшләреннән тыш, Ә.Б. Халидов Ленинград дәүләт университетының Көнчыгыш факультетында да укыта. Соңрак, махсус курслар белән ул берничә тапкыр Алма-Ата, Казан, Утрехт (Нидерланд) университетларына барачак, ә 2000 елның сентябреннән Казан дәүләт

университетының Көнчыгыш телләре институтының көнчыгыш телләре кафедрасы профессоры булачак.

Дистәгә якын көнчыгыш һәм Европа телләрен яхшы белгәнгә, ул фәнни-тикшеренү максатларында Көнчыгыш һәм Көнбатышның күп кенә илләрен йөреп чыкты. 1966 елдан башлап аны Аденда, Багдадта, Бәйрутта, Дәмәшкта, Каһирәдә, Будапештта, Лондонда, Лейден, Парижда һәм Көнчыгыш һәм Көнбатышның башка шәһәрләрендә узган абруйлы халыкара конференцияләргә чакыралар. Чит илгә чыкканда Ә.Б. Халидов тәрҗемәче хезмәтеннән файдаланмый. Европада ул инглизчә, Гарәп Көнчыгышында гарәпчә докладлар ясый. Дөньякүләм данга ирешүенә карамастан, ул фәнни дәрәҗәләр һәм мактаулы исемнәр алырга ашыкмый. Бары тик 1984 елда гына ул гарәп кулъязмаларын тикшерүгә багышланган «Гарәп кулъязмалары һәм гарәп кулъязма традицияләре» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. Болар барысы да Ә.Б. Халидовның беркайчан да сан артыннан кумавы белән аңлатыла, эштә аның өчен иң мөһиме сыйфат күрсәткечләре.

Әнәс Бакый улы озак еллар Шәрыкны өйрәнү институтының гарәп кулъязмалары фондын тикшерү һәм тасвирлау белән шөгыльләнә. Бу эшне бары тик Ә.Б. Халидов дәрәҗәсендәге белгеч кенә башкара алган. Гарәп кулъязмаларындагы кыенлыклар белән барысы да профессор Халидовка мөрәҗәгать итәләр. Һәм ул беркайчан да беркемнең дә соравын кире какмый.

Ул күпсанлы мәкаләләр һәм китаплар калдырды. Махсуслаштырылган фәнни җыентыкта зур монографиясе яки мәкаләсе булса – димәк, алар барысы да моңарчы күрелмәгәнчә тәфсилләп һәм җентекләп язылган. Галим үзенә ифрат дәрәҗәдә таләпчән булган һәм бернинди дилетантлыкны кичермәгән.

Әнәс Бакый улы үзенең тамырларын беркайчан да онытмады һәм үзен татар милләтенең улы дип санады. Соңгы елларда ул туган ягына аеруча нык тартылды. Һәм ниһаять 1990 еллар башыннан ул Казанга килде һәм Казан дәүләт университетында гарәп телен өйрәнүче студентларга лекцияләр укый башлады.

Соңгы вакытта бер генә зур тарихи конференция дә аның беренчел чыганакларга таянып эшләнгән эчтәлекле чыгышларыннан башка узмады. Гомеренең соңгы елында Ә.Б. Халидов Казанда ныклап төпләнде. Аңа киргәкле бөтен шартлар тудырылган, торак мәсьәләсе дә хәл ителгән иде. Халидовка Коръәнне татар теленә тәрҗемә итү эшен тапшырдылар. Бу титаник эшне ул үләр алдыннан тәмамлады, ләкин төзәтергә өлгермәде.

Әнәс Бакый улы көтмәгәндә арабыздан китте. Ул берәүне дә мәшәкатьләргә теләмәде. Аның соңгы сулышы да телефоннан сөйләшкәндә өзелгән. Соңгы минутына кадәр ул кемгәдер кирәк булды...

***Ахунов Азат Марс улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 792

## ТАТАР ТЕАТРЫ ТИРӘСЕНДӘ

На страницах периодической печати приводились ежегодные отчетные статьи о работе Татарского театра. В наиболее ранних из них анализируются недостатки, сильные и слабые стороны работы сценического персонала, нехватка молодых актеров, спектаклей, расскрывающие жизнь именно татарского народа. При этом делается акцент на то, что театр должен работать на зрителя, на обогощение его культурной жизни, на преображение его моральных качеств. Уже к 1929–1930 гг. в общественно-политическом и художественном плане намечается значительный прогресс в работе театра. Проводится большая работа при выборе репертуара, актёров. Постановка новых оперных спектаклей намного разнообразила репертуар театра и увеличило количество зрителей.

**Ключевые слова:** татарский театр, репертуар, спектакли, труппа, артисты.

The periodical press published annual reporting articles on the work of the Tatar Theater. The earliest of them analyze the shortcomings, strengths and weaknesses of the stage staff, the lack of young actors, performances that reveal the life of the Tatar people. At the same time, emphasis is placed on the fact that the theater should work for the viewer, on the enrichment of his cultural life, on the transformation of his moral qualities. Already by 1929–1930. in socio-political and artistic terms, significant progress is being made in the work of the theater. A lot of work is being done when choosing a repertoire, actors. The staging of new opera performances greatly diversified the repertoire of the theater and increased the number of spectators.

**Keywords:** Tatar theater, repertoire, performances, troupe, artists.

(1924–1925 нче елның кышкы сезоны ябылу уңае белән)

– Сәхнә көчләренең урыс театрларындагы шикелле булмавы.

– Сәхнәгә, театрга кирәкле булган нәрсәләрнең җитешсезлеге.

Театрга баручыларның ике төркем (берсе – укучы, эшче, кызылармеец һәм хезмәткәрләр, ә икенчесе – «Печән базары» халкыннан гыйбарәт) булуы;

Беренче төркем эчендәгеләрнең бюджетлары сай булу өстенә ике төркемнең бер-берсенә капма-каршы теләкдә булулары, «Печән базары»ның театрга бик назланып кына йөрүен, афишадан революция исе килгән көнне театрга килү түгел, хәтта театрның урамына керергә дә куркуы, татар театрының шул ике төркемнең икесен дә кочакларга мәҗбүр булуы, театрның татар арасындан ераклыгы һәм башкалар...

Дәүләт татар театры әнә шундый шартлар эчендә эшләп, үзенең сезонын җырып чыкды.

Сезонның башлануы – 1924 нче елның 17 нче октябрендә шул вакытдан алып, (10 нчы апрельгә)[1] чаклы түбәндәге нәрсәләр уйналган:

«Пайтәхет җәлладлары» (4 мәртәбә), «Сәлим бабай» (3 мәртәбә), «Һиҗрәт» (7 мәртәбә), «Бикәт батыр» (2 мәртәбә), «Һинд

[1] Без монда бәйрәм спектакльләренә кагылмадык (*автор искәрмәсе*).

ихтилялчылары» (2 мәртәбә), «Корольнең сакал кыручысы» (1 мәртәбә), «Ибраһим пәйгамбәрнең васыяте» (2 мәртәбә), «Ашказар» (2 мәртәбә), «Туктамыш хан» (2 мәртәбә), «Сөембикә» (2 мәртәбә), «Янгура» (бер мәртәбә), «Иван Грозныйның үлеме» (2 мәртәбә), «Стенка Разин» (2 мәртәбә), «Салават батыр» (3 мәртәбә), «Сүнгән йолдызлар» (4 мәртәбә), «Бибкәй кыз» (бер мәртәбә), «Казан сөлгесе (4 мәртәбә), «Американ» (4 мәртәбә), «Миллионер кызы Банат» (3 мәртәбә), «Галиябану» (2 мәртәбә), «Аршин мал алан» (2 мәртәбә), «Башмагым» (бер мәртәбә), «Ул булмаса, бу булсын» (2 мәртәбә), «Эшчеләр бистәсе» (2 мәртәбә), «Чәчәкле хатын» (бер мәртәбә), «Асылъяр» (2 мәртәбә), «Сакла, шартламасын» (бер мәртәбә), «Мулла кызы Хәмидә» (бер мәртәбә), «Печән базары» (2 мәртәбә), «Зәңгәр шәл» (бер мәртәбә), «Сихерче хатын» (бер мәртәбә), «Ике нарасый» (бер мәртәбә), «Һинд кызы» (3 мәртәбә), «Хан кызы Турандык» (2 мәртәбә), «Таһир – Зөһрә» (бер мәртәбә), «Малик Ширкән» (3 мәртәбә).

Димәк, Дәүләт татар театры труппасы быелгы кышкы сезон эчендә барлыгы 89 спектакль биргән. Труппа атнасына дүрт спектакль биреп, аның берсен елга аръягы берләшкән бистәләр районында үткәргән. Берләшкән бистәләр районындагы спектакльләрнең саны – 20, Мулланур Вахитов заводы янындагы (Ленин клубында) үткәрелгән спектакльләрнең саны – 2 (бу 22 спектакль югарыдагы 89 эченә керә).

Дәүләт татар театры труппасы берләшкән бистәләр районында эшләгәнлектән, быел андагы труппа бетерелгән һәм аның кайбер кешеләре дәүләт труппасына алынган. Эшчеләр арасындагы спектакльләр дәүләт театрындагына караганда байтак өлеш арзан куелганлар. Шуның өчен дә эшчеләр районындагы спектакльләргә йөрүчеләр шәһәр театрына йөрүчеләргә караганда аз артыграк булган.

Шәһәрдәге арзанлы спектакльләрнең саны – 14, эшче, укучы, кызылармеец шикелле ибдәшләргә кредит ачу, арзанлы билет бирү мәсьәләсенә чибәр генә игътибар ителгән. Шәһәрнең үзендә – 5, эшче районларында 3 тапкыр бөтенләй акчасыз спектакльләр үткәрелгән.

Без Татар дәүләт театры труппасының барлыгы 89 спектакль биргәнлеген югарыда язып үткән идек. Менә бу «89»дан түбәндәге нәтиҗәләрне чыгарабыз:

1. Татар труппасы мөмкин булган чаклы яңа әйберләр бирергә тырышкан, (куелган әсәрләрнең барлыгы 38 төрле булып, шуның 20се бүгенгә чаклы Казан сәхнәсендә уйналмаганлар).

2. Татар труппасы мөмкин булган чаклы революция рухында язылган әсәрләрне табарга тырышкан һәм мондый әсәрләр башка төрдәгеләргә караганда күбрәк кабатланганлар. Мәсәлән, «Һиҗрәт» – 7 мәртәбә, «Асылган» – 6 мәртәбә, «Пайтәхет җәлладлары» 4 мәртәбә уйналганлар.

3. Сезон эчендәге яңа әйберләр 20 исемдә булсалар да, татарның саф үз тормышыннан алынган әсәрләр аз уйналганлар.

4. Быелгы сезонда ханлар, патшалар тормышыннан алынган әсәрләргә күп кенә урын бирелгән.

5. Урысларның «Ревизор»лары, чит телләргә тәрҗемә ителгән «Отелло», «Һамлет» шикелле атаклы нәрсәләр быелгы сезонда уйналмаганлар.

Быелгы сезонда труппаның составы 19 кешелек булган (әлифба тәртибе белән) аларны санап чыгыйк:

Әпсәләмов, Абдюшев (Илдар), Абитов, Вәлишин, Габидов, Ильясов, Камал III, Латыйпов Фәттах, Уральский, Шамил Касыйм, Шамильский (ул ук баш режиссер);

Артистлар:

Арапова, Әюпова, Арская, Ильская, Исмаева, Камская, Кушловская, һәм Хөсәенова.

Болар – труппаның төп хезмәтчеләре. Боларга татар театр техникумы укучылары, тәгълим-тәрбия техникумы шәкертләре һәм хәрби-сәяси мәктәп курсантлары булышлык иткәнләр. Театр техникумында укучыларның эшләре аеруча күзгә бәрелерлек.

Югарыдагы 19 кешенең нинди көчкә хуҗа икәнлекләре бик күпләребезгә билгеле. Аларның эчендә революциядән соң гына калкып чыккан яшь көчләр булган шикелле, унар-унбишәр еллык стажлы – халык каршында нык рәвешдә танылган ибдәшләр дә байтак кына.

Ләкин бу урында ачыкдан-ачык әйтергә кирәк: югарыдагы ибдәшләрнең кирәк яшьләре, кирәк элекдән уйнап килүчеләре булсын, театр сәнгате теориясендән ерак торалар.

Болар арасында үзләренең көндәлек хезмәтләренә багланган берәр төрле мәктәп-курс шикелле уку йортларын үтәргә теләүчеләр сирәк күренә, зур күпчелек өендә дә укымый шикелле, ә инде сәяси белемгә килгәндә монда да бик шәпдән түгел бугай. Общий белемдә дә чатанлау сизелгәли. Бу кимчелекләрне бетерү юлындагы адымлар акрын шикелле. Бу акрынлык уйнаучыларның үзләре өчен дә, шулай ук караучылар өчен дә зарарлы. Масса үсә, массаның теләген төгәлләү өчен сәхнә хезмәтчеләренә дә үсәргә, ә моның өчен ныклабрак кыймылдарга кирәк.

Труппаның составы 19 кешелек дигән идек. Атнасына 4 спектакль бирү өчен, 19 кеше генә аз. 19 белән генә эш итсәк, ашык-пошык (азмаз хәзерлек белән генә) эшләргә туры килә. Кеше җитмәгәнлекдән, кайберәүләр ике рольдә чыгалар. Кайсыбер ибдәшләрне үзе теләмәгән һәм аңар ярамаган рольләрдә чыгаралар. Мондый нәрсәләр караучылар өчен дә, уйнаучылар өчен дә начар һәм килешсез булып чыга. Менә бу нәрсәгә бик нык игътибар итәргә кирәк. Киләсе сезонга 19 ны үрчетергә, чит шәһәрләрдәге яхшы көчләрне Казанга тарту ягын карарга кирәк, чөнки 19 ның барысын бергә җыйнап карасаң, кайбер урынларның китеклеге күзгә бәрелә, көчләрнең барысы да җитешеп бетми.

Билгеле, сезонда артист һәм артисткаларның ничек уйнауларына һәм нинди типлар бирә алуларына журналда урын азга күрә туктый алмыйбыз. Моны театрга йөрүчеләрнең үзләренә калдырабыз.

Билгеле, сезонда 20 исемдә яңа әсәр уйналды дигән идек. Болар арасында үз тормышыбыздан алып язылган «Һиҗрәт», «Печән

базары», «Туктамыш хан» һәм «Сөембикә» шикелле нәрсәләрне уңышлы хезмәтләрдән саныйбыз. Кытыршы урынларын бетергәндә, болардан байтак файдаланып булырдыр.

Татар театры акрынлык белән булса да үсә, ләкин аңа бик күп күтәреләсе бар әле. Ул бүгенге көнне, бер якдан, материалный җитешсезлек белән авырса, икенчедән мәгънәви якдан сырхаулы. Менә бу эчке һәм тышкы якдагы чирләрне бетерү юлында Гыйльми үзәк, главполитпросвет, наркомпросның художество бүлеге һәм театр администрациясе шикелле оешмаларның җиң сызганып, бергәләшеп эш күрүләре кирәк.

Барысындан да бигрәк киләсе сезонның хәзерлеге алдан ук күрелгән булырга тиеш.

Мөхәммәд Парсин.
*Безнең юл, 1925, № 4.*

## СЕЗОН ҮТКӘЧ

14 нче апрельдә Татар дәүләт академия театры үзенең 1929–30 нчы елның кышкы сезонын япты. Үткән ел «Безнең юл» журналының 5 нче номерында «Яңа сезонга таба» дигән сүз башы астында бу елгы сезонны хәзерләүгә карата берничә мәкалә язылып, аңлашулар булып алган иде. Ул вакытта язылган кайбер киңәшләр, тәкъдимнәр сезон оештырганда һәм практик эш алып барылганда, һичшиксез, үзләренең йогынтыларын ясадылар, театр эшенә булышлык иттеләр. Хәзер, сезон беткәч, «Безнең юл»га сезон турында йомгак ясау, киләсе сезонны хәзерләү үз-үзеннән сорала. Менә шуның кереш сүзе урынына без бу елгы кайбер уңышлыкларны, җитешсезлекләрне язып, «Безнең юл» укучылары белән бүлешмәкче булабыз.

Октябрь революциясе нәтиҗәсендә театр дөньясы, гомумән, зур уңышларга иреште. 1848 нче елларда Франция революциясе чорында Рихард Вагнер «Театр, мәктәп һәм университетлар кебек үк, дәүләт учреждениесенә әйләнергә тиеш» дигән иде. Буржуа театрны бер вакытта да бу хәлгә куя алмады, куя алмады гына түгел, театрны ул капиталистларның хосусый предприятияләренә әйләндереп, театрны бозу, аны фахиш рәвештә юлдан чыгару эшен дә дәвам итте. Иптәш Луначарский хәзерге буржуа театрларның хәле турында шулай ди: «Буржуа җөмһүриятендә театр эше бик начар хәлдә тора. Театр «лавка»га әйләнә. Ул, билгеле, үзенең төбендә үк үзгәрә, фахиш рәвештә бозыла («Театр һәм революция», 11 нче бит). «Предприниматель театры һәм капитализм шартында булган культура куелышы тамашачыны фахиш рәвештә бозды. Шулай ук, үз нәүбәтендә, тамашачы театрны бозды» (шунда ук, 12 нче бит).

Пролетариат дәүләте Советлар союзында театрны буржуаның һәлакәт юлыннан коткарып, бөтенләй икенче якка борды. Бездә театр, гомумән, пролетариат культурасы фронтында үзенә зур урын алып, ул пролетариатның сыйнфый мәнфәгате өчен көрәшү юлына

күчте. Пролетариат театры буржуадан калган черек моментларны көннән-көн үзеннән алып читкә ыргыта бара. Татарстан шартларына килгән вакытта Татар дәүләт академия театры төзелеп, пролетариат хөкүмәте карамагына алынып, аны партия җитәкчелеге һәм эшче-крестьян контроле астында барлык яктан тәэмин итеп яшәтү факты милли җөмһүриятләрдә дә театр эшенең зур алга китүен күрсәтә. Бездә дә театр революцион культура фронтында сәяси һәм иҗтимагый тормышыбызда зур роль уйный торган өлкәләрнең берсе булып әверелде. Моны безгә театрның алдына куйган бурычлары ачык күрсәтә. Үткән ел сезон бурычларын билгеләгәндә, без түбәндәге сүзләрне укыйбыз: «Театр үзенең бүгенге бурычын билгеләгәндә, социализм төзелешенең үзәгеннән мөндәриҗә алырга, шушы чорның көрәшен гәүдәләндерергә тиеш. Театр үзенең бөтен мөндәриҗәсе белән социализм төзү көрәше – илне индустрияләштерү, авыл хуҗалыгын социализм нигезендә яңадан төзү, илне саклау моментларына хезмәт итәргә, үзенең һәр адымын сыйнфый көрәш ноктасыннан карап, шул юлда актив эшләргә тиеш», ди. (Кызыл Татарстан, 31 июль, 1929 нчы ел). Дөрес, бу бурычны үтәү Татар дәүләт академия театры өчен җиңел булмады. Чөнки театр дөньясы хәзерге тормышны гәүдәләндерүдә, гомумән, артта калган. Безнең шартларга килгәндә, бу тагын да авыррак иде. Без беләбез, Татар дәүләт академия театрының 1927–28 нче елгы сезонында ачыктан-ачык контрреволюцион солтангалиевчелек ярылып ята. 1928–29 нчы елгы сезонда мөндәриҗә ягыннан борылыш булса да, күбрәк тәрҗемә әсәрләр исәбенә булды. Үткән ел оригинал яңа әсәрләрдә тотнаклы дип санарлык «Ут» һәм «Зәкуан мулла шәҗәрәсе» әсәрләрен генә алырга мөмкин. Татар эшчеләре, крестьяннары тормышыннан алынып язылган бер пьеса да булмады. Менә бу яктан зур борылыш ясарга кирәк иде. Бу борылыш алдан, еректан килгән зур хәзерлек белән ясалмады, бәлки сезон алдыннан гына эшкә керешергә туры килде. Шуның өчен монда ашыгычлык һәм җитешсезлекләр булуы бик мөмкин иде. Шуңа карамастан Академия театры үзенең репертуарында ныклы борылыш ясый алды. Түбәндәге пьесалар аны ачык күрсәтә: «Доцент Янбулатов» Файко әсәреннән Н. Солтанов тарафыннан үзгәртелгән. Әсәр уку йортларында культура фронтында булган чит элементларга каршы көрәш ача. «Утлы божра» – Г. Уральский әсәре – гражданнар сугышыннан бер эпизодны гәүдәләндерә. «Рельслар гөрләгәндә» – русчадан тәрҗемә. Эшләп чыгаруда булган каршылыкларны чит элементлар ача. «Мятеж» – тәрҗемә. Гражданнар сугышыннан бер эпизод. «Ил» – К. Тинчурин әсәре. Крестьяннарның помещикларга каршы көрәшен күрсәтә. «Төзүчеләр» – Шакиров әсәре, авылдагы сыйнфый көрәшне гәүдәләндерә. «Җавап» – Г. Кутуй әсәре. Матбага эшчеләре тормышыннан. «Козгыннар оясында» – Ш. Камал әсәре. Революциягә чаклы булган татар эшчеләре тормышыннан. «Ут» – Ш. Камал әсәре. Чит элементлар белән бәйләнү бәласен гәүдәләндерә. «Данлы чор» – Риза Ишморатов әсәре. Туку эшчеләре тормышыннан. «Зәкуан

мулла шәҗәрәсе» – Ф. Сәйфи әсәре. Черегән элементларны күрсәтә. «Шлем» Минский әсәре. Бүгенге Кызыл Армия тормышыннан алынып язылган. «Авангард» – Катаев әсәре, Шамильский тәрҗемәсе. Колхоз тормышыннан. «Ил үскәндә» – Гыйззәтев әсәре. Авылдагы сыйнфый көрәш һәм колхоз тормышыннан. Менә бу әсәрләр арасында психология ягыннан производство һәм эшчеләр тормышыннан – 5 әсәр. Гражданнар сугышы – 2, бүгенге Кызыл Армия – 1. Колхоз төзелеше һәм авылдагы сыйнфый көрәш – 3. Иске авыл тормышыннан – 2. Чит элементлар белән көрәш – 3 әсәр. Болардан үткән ел куелганнары – 5 әсәр. Яңалары – 11. Шуларның да 9 ы, үткән елгылар белән алганда, оригиналлар – 12, тәрҗемә – 4. Бу әсәрләр үзләренең темалары белән театрның югарыда билгеләнгән бурычны үтәүгә, сүздә генә түгел, эштә дә керешкәнен күрсәтәләр. Чөнки ул темаларның күбесе хәзерге бурычларыбызга каратып куелалар. Шуның өстенә төрле темалар аерым вакытларга карата биреләделәр. Дөрес, театрның бу юлда зур җитешсезлекләре бар. Эшчеләр тормышыннан алынып язылган пьесалар художество ягыннан аксаган кебек, хәзерге хуҗалыкны яңадан төзү чорын тулы гәүдәләндерә алмыйлар, күбрәк төзәлү чорын бирәләр. Колхоз төзелешендә булган пьесалар, беренче адым булганлыктан, монда да ачыклык күренеп тора. Шуның өстенә производство һәм авыл хуҗалыгында эш процессы тамашачыга кайбер вакытларда җитә алмый калгалады. Эшче-крестьян тормышыннан алынып язылган әсәрләрдә яңа быт бер дә күренми, яки бик аз. Киләчәктә драматурглар менә шул нәрсәләргә игътибар итәргә тиешлеләр.

Безнең уебызча, киләсе елда драма буенча 15 пьеса хәзерләргә кирәк. Тема ягыннан эшчеләр тормышыннан – 3 әсәр, крестьяннар тормышыннан – 3, Кызыл Армия һәм Гражданнар сугышы – 2, культура фронты – 2, укучылар – 1, комсомол – 1, күрше Шәрык җөмһүриятләреннән – 1, яңа тормыштан 2 пьеса кирәк. Боларның 3 се – бу елгы әсәрләрдән, 2 се – урысчадан, 1 се – күрше җөмһүриятләр репертуарыннан сайланып, 9 ы яңадан язылырга тиешле.

Һәрбер театрның үзенең техникасына һәм алган юлына, тамашачысына карап, башка театрдан аермасы була. Шуның өчен пьеса язучы драматурглар Татар дәүләт академия театры белән алдан хәбәрләшеп, алган темалары, төзү техникалары турында театр белән аңлашып эшләгәндә пьесаларны үзгәртүләр әзрәк булыр иде.

Революция театрның эчке мөндәриҗәсен үзгәрткән кебек, аның тышкы тормышына да үзгәреш ясый. Фриче әйткәнчә: «Художество стиле үзенең төбендә шул дәвердәге иҗтимагый һәм быт-көнкүреш эшләрнең стиленә нигезләнә». Эшчеләр, крестьяннар тормышы хәзерге көрәш, гомумән, революция, масса хәрәкәтенә корылган. Бу масса хәрәкәте эшләп чыгару процесслары һәм эшләп чыгару кораллары белән бәйләнә. Постановкаларда менә шуны тиешенчә гәүдәләндерү театрның алдына зур бурыч булып килеп басты. Үткән елларда театрның стиле, формасы турында күп сүзләр булып килде.

Татар дәүләт академия театрын юлсызлыкта гаепләделәр. Бу ел художество советында күп сөйләшкән, уйлашканнан соң, театр үзенең төп юлы итеп реаль конструктивизм юлын алды. Шуның белән бергә, эзләнүләргә, тәҗрибәләр ясарга да урын калдырды. Шуның өчен быелгы сезонда күбрәк нәрсәләр реаль конструктивизм стилендә барып, «Зәңгәр шәл», «Җавап», «Төзүчеләр» һәм «Шлем» кебек пьесаларда тәҗрибәләр ясалды. Бу тәҗрибәләр арасында Вәлиев тарафыннан куелган «Шлем» куелышын уңышлы тәҗрибәләрдән санарга туры килә.

Шуның белән бергә Татар дәүләт академия театрының сәхнәсе хәзерге революцион театр өчен бик зәгыйфь булып чыкты. Киләчәктә театр алдында бу сәхнәне төбеннән үзгәртеп, киңәйтеп, механизация кертеп, яңадан эшләү моменты тора. Шуны эшләмәгәндә, театр бу буржуа сәхнәсеннән калган мирас белән күп алга китә алмаячак. Шуның өчен Татар дәүләт академия театрының бинасын зурайту, сәхнәсен яңадан эшләү иң ашыгыч эшләрнең берсе булырга тиеш. Театрның бинасын бер мең кешелектән ике мең кешелек ясау, сәхнәне иң соңгы техникага кую безнең төзелгән проект буенча 200000 сум торчак.

Хәзерге югарыда язылган эшләрнең тамашачыга барып җитүен карыйк. Театр үз төсен беләсе килсә, тамашачысына карарга тиеш. Чөнки аның мөндәриҗәсе, формасы нинди катлауның соравына җавап бирсә, ул шул катлау тамашачыга ия була. Алты айда Татар дәүләт академия театры 70000гә якын тамашачы үткәргән. (Үткән ел 51 мең үткән). Быелгы тамашачының 95 проценты профсоюзларга оешкан эшчеләр, хезмәткәрләр һәм укучылардан тора. Бу – зур уңыш. Ләкин шул профсоюзга оешкан тамашачының күпчелеге әле хезмәткәрләрдән һәм укучылардан гыйбарәт. Билгеле, эшчеләр районнарының шәһәр уртасыннан еракта булуы да моңа йогынтысыз калмый. Шуңа күрә театр Вахитов заводында, елга аръягында, хәтта Кукмара заводында аерым спектакльләр оештырып килде. Ләкин мәсьәлә моның белән генә чишелеп бетми. Без бу ел күп фабрикларда эшчеләргә билетларның барып җитүен тикшердек. Кайбер завкомнарның эшчеләрне театр белән тәэмин итүгә һичбер игътибар итмәгәннәре беленде. Академия театры үз бинасы эчендә эшчеләр тамашасыннан күпчелек ясарга тиеш иде, чөнки хәзерге районнарда булган театрларның сәхнәләре бик начар булганлыктан, спектакльләр районнарда Академия театрыннан түбән чыгалар. Кайбер әсәрләрне берьюлы куеп булмый. Шуның өчен эшчеләрне Академия театрына тагын да якынайту эше иң зур эшләрнең берсе булып барырга тиеш. Профсоюз органнарына бу эштән читтә торып калырга ярамый. Хуҗалык һәм планны үтәү ягыннан быелгы сезонда яхшы уңышлар бар. Үткән ел драма 89 спектакль бирелсә, быел 107 спектакль бирде. Аның өстенә 16 тапкыр татар операсы барды. Үткән ел 89 драма спектакле өчен 20 премьера куелган булса, быел 107 спектакль өчен 16 премьера куелды. Бу – зур алга китү. Чөнки никадәр эз премьера булса, шул нисбәттә спектакльләрнең сыйфаты яхшылана. Премьераларны әзәйтү быел

тамашачыларның санын киметмәде. Киресенчә, айдан-айга спектакльләрнең саны арта барды. Март аенда 25 спектакльгә барып житте. Бу нәрсә, бер яктан, премьераларны тагын да әзәйтергә ирек бирсә, икенче яктан спектакльләрнең санын күбәйтергә, тиз вакыт эчендә көндәлек спектакльгә күчәргә кирәклекне белдерә.

Быел спектакльләрнең үзенә төшә торган хакы 30 процент кимеде. Шуның нәтиҗәсе буларак, Татар дәүләт академия театрының кышкы сезоны ябылса да, ул театрны быел ел әйләнәсенә күчерде. Хәзер җәйге сезон оештыра. Җәй көне театр эшче районы һәм авылларда эшләп, Татарстанның 10 еллыгына Казанга кайтачак. Театр эшендә быел сәяси һәм художество җитәкчелеге советы зур урын тотты. Барлык пьесалар анда ныклы тикшерүгә очрадылар. Җәмәгать караулары үткәрелде. Үзгәртүләр, төзәтүләр булды. Шулай итеп художество һәм сәяси җитәкчелек советы киләчәктә үзенә бик нык игътибарны тарта торган оешма булып әверелеп бара.

Хәзер театрның артист һәм сәнгать эшчеләренә килик. Быелгы сезонда драманың художество составында Арапова, Болгарская, Ильская, Кальметова, Мәрьям Сульва, Мөхәммәдиева, Таждарова, Закиров, Камал III, Касыймов, Сәлимҗанов, Таһиров, Уральский I, Уральский II, Хисамов, Шамильский, художество бүлегендә Мөхсинев, Сәйфи, Тинчурин, Солтанов, Вәлиев, Исмәгыйлев, Сәйдәшев, Сперанский, Муко, Үтәгән, Йосыпов, Сәйфуллин, Терновскаялар эшләделәр. Гомумән алганда театрның быелгы составында хезмәт дисциплинасы, бердәмлек, производство белән кызыксыну бөтен җәмәгатьчелек алдында күренеп торды. Болар арасында ударный бригада төзелеп эшләде. Академия театрының планлы эшләреннән башка җәмәгатьчелек нигезендә төрле эшчеләр оешмаларында, кызыл гаскәрләр арасында кичәләр уздырылды, спектакльләр куелды. Шулай ук илне индустрияләштерү, колхозга художество бригадалары төзү файдасына иҗтимагый эш нигезендә спектакльләр бирелде. Артистларның күп ял көннәре төрле иҗтимагый эштә үтте. Үткән елга караганда театр һәм аның эшчеләре тамашачы һәм эшче массасы белән ныграк нигезләнде. Тамашачылар җыелышларыннан башка предприятиеләрнең аерым цехларында театр турында докладлар куелып, театр эшчеләр массасына якыная төште. Бу эш театр эшчеләренең сәяси һәм моральный яктан күтәрелүләренә ярдәм итте. Шуның белән бергә бу юлда эшләнергә тиешле булган эшнең бик әз өлеше эшләнде әле. Эшчеләр массасы белән бәйләнештә театр һәм аның эшчеләре үзләренең эшен 100 процент күтәрергә тиешлеләр.

Татар дәүләт академия театрында, булышлык составы рәвешендә, Театр техникумының 4 нче группасы эшләде. Кимова, Мәсгутова, Шадрина, Сәлимова, Хәйбуллина, Янборисова, Янгуразова, Шәрәфетдинова, Гыймадов, Зәйнуллин, Камалов, Нәриманов, Сәгыйтов, Хәбибов, Хисамов, Юсупов, Сәтиевләр эшләде. Татар техникумының бу эшчеләре бирелеп эшләделәр. Киләчәктә үзләренең яхшы сәнгать эшчеләре булачакларын ачык күрсәттеләр.

Быелгы сезонда драмадан башка опера сезоны төзелеп эшләде. «Сания» һәм «Эшче» опералары куелды. «Эшче» үзенең музыкасы һәм мөндәриҗәсе белән пролетариат сәнгатенә яңа байлык булып керде. «Эшче» операсын Татар дәүләт академия театры Татарстанның унъеллык бәйрәменә бүләк итте. «Эшче» операсы турында күп язылганлыктан, без монда артык тукталып тормыйбыз, тик шуны әйтергә кирәк, әле «Эшче» операсы – татарларда гына түгел, үзенең мөндәриҗәсе ягыннан гомумопера дөньясында яңа әсәр. Шуның өчен, аның кимчелекләре булуы бик мөмкин. Киләчәктә без аның кимчелекләрен бетерү, гомумтатар музыкасын үстерү юлында эшләргә тиешбез. Без монда бигрәк тә өч моментка игътибар итүне тәкъдим итәбез.

1) Опера үзе киләчәктә кирәкме, кирәк булганда ничек булырга тиеш дигән бәхәс йөртәләр. Без моңа каршы, опера кирәк дип җавап биреп, хәзергә тормышны гәүдәләндерү өчен төзелгән операларда үзгәреш ясарга кирәк булган урыннарда җыр урынына сүзләр кертеп, операның канунын бераз яңартырга кирәк дибез. Чөнки кызу сөйләү моментында озын көйләр җырлап тору ябышып бетми.

2) Операның музыкасын иҗат иткәндә, әкренләп халыкның культура дәрәҗәсеннән бик үк сикереп китми, музыканы интернациональләштерә барырга кирәк. Ләкин моңар кадәр иҗат ителгән көйләр турында эшче массаның карашы, ул көйләрне хезмәт ияләренең ничек аңлавы өйрәнелми. Шуның өчен киләчәктә опера язганда аның аерым музыкаларын, опера төзелеп беткәнгә кадәр хезмәт ияләре алдында күрсәтергә, аларның фикерләрен җыярга кирәк.

3) Татарларда талантлы композиторлар булу белән бергә, музыка башкаручылар составы – оркестр юк. Хор бик ярлы, хореография әле фольклордан чыгып җитә алмаган. Менә бу бүлекне оештыру, музыкадан артта калдырмау безнең көндәлек бурычыбыз булырга тиеш.

Югарыда язылганнарга йомгак ясасак, быел Татар академия театры сәяси иҗтимагый һәм художество ягыннан алга китте дип әйтә алабыз. Бу уңышның төп сәбәпләреннән беренчесе – партиянең ныклы рәвештә җитәкчелек итүе. Икенчесе – театрның эшчеләр җәмәгатьчелеге белән бәйләнеше (эшчеләр белән шефка алышу, социализм ярышы, эшчеләр тарафыннан театрның эшен тикшерү, ударный бригада һ.б....). Өченче –матбугат, бигрәк тә «Кызыл Татарстан»ның үткән елгы сезонны оештыруда киң җәмәгатьчелекне катнаштыруы булды.

Киләчәктә шушы өч төрле эш яхшы барганда, күрсәтелгән җитешсезлекләр бетеп, театр тагын да зуррак уңышларга ирешәчәк.

***З. Мөхсинев.***

*«Безнең юл», 1930, № 3–4.*

*Текстны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәрләре Ләйлә Гарипова һәм Айгөл Әхмәтова әзерләде*

УДК 2-335

*Н.В. Яблоновская*

# ИСМӘГЫЙЛЬ ГАСПРИНСКИЙНЫҢ ПУБЛИЦИСТИК МИРАСЫН ПОПУЛЯРЛАШТЫРУДА ЯҢА АДЫМ:
## Исмәгыйль Гаспринскийның сайланма әсәрләренең III томына («Публицистика: 1887–1890 гг.» (Казань–Симферополь, 2019) рецензия

Рецензируется III том «Публицистика:1887–1890 гг.» (Казань – Симферополь, 2019) полного собрания сочинений Исмаила Гаспринского, выпускаемого совместно Институтом истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан, Крымским научным центром ГБУ РК «Бахчисарайский историко-культурный и археологический музей-заповедник», Мемориальным музеем Исмаила Гаспринского, ГБОУВО РК «Крымский инженерно-педагогический университет им. Февзи Якубова», ГБУК РК «Республиканская крымскотатарская библиотека им. И. Гаспринского». В том вошли публицистические произведения И. Гаспринского (заметки, комментарии, статьи, очерки, зарисовки и т.д.), опубликованные в номерах газеты «Переводчик – Терджиман» за 1887–1890 гг., а также несколько публицистических произведений И. Гаспринского указанного периода, впервые транслитерированных и переведённых на русский язык. Рецензируемое издание обладает несомненной филологической, философской и медиалогической значимостью, дает возможность рассмотреть новые грани Гаспринского-мыслителя и Гаспринского-публициста, неразрывно связанного со своей эпохой и всеми ее преходящими заботами и непреходящими ценностями. Кроме того, материалы тома, раскрывающие «от первого лица» общественно-политические, экономические и культурные реалии Крыма второй половины 1880-х гг., будут чрезвычайно интересны историкам, культурологам и краеведам.

**Ключевые слова:** Исмаил Гаспринский, «Переводчик – Терджиман», этническая пресса, крымскотатарская журналистика, публицистика.

This article reviews the first volume “Journalism: 1887–1890” of The Complete Works of Ismail Gasprinski published in Russian in Simferopol in 2019. This volume includes journalistic works of I. Gasprinsky (notes, comments, articles, essays, sketches, etc.) published in the issues of the newspaper “Perevodchik – Terdzhiman” for 1887–1890, as well as several journalistic works by I. Gasprinsky of the same period, first transliterated and translated into Russian. The peer-reviewed publication has undoubted philological, philosophical and media-logical significance, makes it possible to consider new facets of the Gasprinsky-thinker and Gasprinsky-publicist, inextricably linked with his era and all its transient concerns and enduring values. In addition, the materials of the volume, revealing “in the first person” the socio-political, economic and cultural realities of Crimea in the second half of the 1880s, will be extremely interesting to historians, cultural experts and local historians.

**Keywords:** Ismail Gasprinsky, “Perevodchik – Terdzhiman”, ethnic press, Crimean Tatar journalism, journalism.

Атаклы кырымтатар һәм гомумтөрки фикер иясе, мәгърифәтче, публицист Исмәгыйль Гаспринскийның (1851–1914) сайланма әсәрләре Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, КР ДБУ Кырым фәнни үзәгенең «Бакчасарай тарихи-мәдәни һәм археология музей-тыюлыгы», Исмәгыйль Гаспринскийның мемориаль музее, КРның «Февзи Якубов исемендәге Кырым инженер-педагогика университеты» Югары белем ДБГБУ, КРның «И. Гаспринский исем. республика кырымтатар китапханәсе» ДБМУның уртак тырышлыгы белән, күптәнге мәдәни һәм җәмгыяви ихтыяҗны күздә тотып, басмага әзерләнде һәм дөнья күрде .

Басманың 2016 һәм 2017 елларда нәшер ителгән беренче ике томына И. Гаспринскийның әдәби әсәрләре [Гаспринский, 2016] һәм 1879–1886 елларда төрле җыентыкларда һәм вакытлы матбугатта («Тонгуч», «Шәфәкъ», «Зийаи Кавказие», «Таврида», «Тәрҗеман») урын алган иртә публицистикасы, шулай ук Симферопольдә һәм Истанбулда аерым брошюралар булып басылган хезмәтләре [Гаспринский, 2017] кертелгән.

Сайланма әсәрләрнең 2019 ел ахырында дөнья күргән яңа өченче томы И. Гаспринскийның публицистик әсәрләреннән (мәкаләләр, комментарийлар, очерклар, зарисовкалар һ.б.) тора. Алар моңарчы «Тәрҗеман» газетасының 1887–1890 еллардагы саннарында басылып чыккан булган.

Басманың баш мөхәррире – тарих фәннәре докторы, ТР ФАнең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры, ТР ФА вице-президенты Р. С. Хәкимов; фәнни мөхәррире – тарих фәннәре докторы, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының фәнни эшләр буенча директор урынбасары, ТР ФА хакыйкый әгъзасы Р.Р. Салихов, җаваплы сәркатибе – тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Кырым фәнни үзәге мөдире Э.Х. Сейдаметов.

Өченче том, алдагы икесе кебек үк, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Кырым фәнни үзәге кече фәнни хезмәткәре С.А. Сеитмеметова тарафыннан төзелгән.

И. Гаспринскийның төрки телле текстлары рус теленә Исмәгыйль Гаспринскийның мемориаль музее мөдире, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Кырым фәнни үзәге кече фәнни хезмәткәре Э.Э. Абибуллаева, Автоном коммерциячел булмаган оешма «Иҗтимагый кырымтатар телерадиокомпаниясе»нең әдәби, музыкаль һәм балалар программалары редакциясе мөхәррире Г.У. Зайидова һәм Көньяк федераль университетының дисциплинара гуманитар тикшеренүләр үзәге кече фәнни хезмәткәре Н.Е. Тихонова тарафыннан тәрҗемә ителгән.

Том контентының өстенлеге – И. Гаспринскийның журналистлык иҗатын һичшиксез популярлаштырудан тыш, китапта «Тәрҗеман»да басылган вакытта ук рус телле версияләре дә булган әсәрләр генә түгел, бәлки беренче тапкыр транслитерацияләнгән, русчага тәрҗемә

ителгән һәм фәнни әйләнешкә кертелгән аз билгеле төрки телле публицистик әсәрләр дә урын алуда.

Төзүче И. Гаспринскийның 1887–1890 еллардагы журналистлык мирасын, журналистика жанрларының өч төренә (мәгълүмати, аналитик һәм әдәби-публицистик) туры китереп, өч өлешкә бүлә: «Мәгълүмати язмалар», «Аналитик мәкаләләр һәм комментарийлар» һәм «Әдәби-публицистик очерклар һәм зарисовкалар». Шул рәвешле, ул гомуми хронологик тәртипне боза (шул ук вакытта һәр категория эчендә әсәрләр хронологик принцип буенча урнаша).

Төзүченең теләге аңлашыла: ул И. Гаспринскийның киңкырлы мирасын жанр ягыннан структуралаштырырга һәм аның иң элек журналист булуына басым ясарга тырыша. Әсәрләрнең мондый компоновкасын безгә уңышлы дип атавы кыен, чөнки:

1) И. Гаспринскийның барлык әсәрләре дә журналистика жанрларының заманча системасына «сыешмый, ә аларның кайберләре жанрлар чигендә «күчеш» күренешләре хасил итәләр, шуңа күрә аларны классификацияләгәндә ялгышырга һәм уникаль, мөһим, иң әһәмиятле нәрсәне күз уңыннан ычкындырырга мөмкин;

2) Россиядә сайланма әсәрләр бастырып чыгаруда әсәрләрне хронологик тәртиптә урнаштыру принцибының гасырдан артык чорны колачлаган ныклы традициясе урнашкан, моңа басманың башка рецензентлары да игътибар иткән иде [Фархшатов, Исогай];

3) томның ике өлешенә бирелгән исемнәр – «Аналитик мәкаләләр һәм комментарийлар» һәм «Әдәби-публицистик очерклар һәм зарисовкалар» – лексик яктан артык чуар: аналитик булмаган мәкаләләр гомумән юк һәм әдәби булмаган-публицистик очерклар һәм зарисовкалар да булмый;

4) төзүче тарафыннан уңышлы ассызыкланган газета дискурсы (һәр текст алдында аның «Тәрҗеман» газетасына нисбәтле библиографик тасвирламасы бар) мондый композиция белән тигезләнә, чөнки басманың бер үк номерындагы материалларга укучыга берничә тапкыр әйләнеп кайтырга туры киләчәк, бу аерым номерларны тулаем кабул итәргә комачаулый.

«Искәрмәләр»дә төзүче тарафыннан материалларның жанры билгеләнә, беренче тапкыр бастырган «Тәрҗеман» газетасының елы һәм номеры күрсәтелә (кызганычка каршы, томда ике тапкыр бирелгән библиографик тасвирламаларда – беренче тапкырында, алдарак күрсәтеп үтелгәнчә, текстлар алдыннан теге яки бу материал урнаштырылган бит номеры юк), телгә алынган тарихи шәхесләр, басмалар һәм үткәннең реалияләре турында кыскача белешмәләр бирелә һ.б.

Аңлатмаларда И. Гаспринскийның публицистик әсәрләре белән ул яшәгән дәвер арасындагы бәйләнеш җентекләп яктыртыла һәм бу рәсемнәр белән дә ныгытыла: кырымтатар мәгърифәтчесенең шәхси фотографияләре; хезмәттәшлек иткән, я аларны үзенең 1887–1890 елларга караган язмаларында искә алган тарихи эшлеклеләрнең сурәт-

ләре; «Тәрҗеман» публицистикасында чагылыш тапкан әһәмиятле вакыйгаларның, Бакчасарайның тарихи сурәтләре һ.б.

Томның иллюстратив материалларында әлеге елларда «Тәрҗеман» газетасы үзе кичергән үзгәрешләр дә тәфсилле чагылыш таба: һәр ел өчен аның номерлары саны китерелә, форматның (мәсәлән, 1888 елда ул өч тапкыр үзгәрә), логотипның үзгәрүе һ.б. турында тулы мәгълүмат бирелә. «Исемнәр һәм басмалар күрсәткече» булу басма белән эшләүне шактый җиңеләйтә. Анда шәхси исемнәр белән берррәттән, И. Гаспринский әсәрләрендә телгә алынган әсәрләрнең һәм вакытлы басмаларның атамалары да кертелгән.

Гомумән алганда, томны төзүчеләр зур фәнни һәм иҗтимагый мөһим эш башкарганнар, югарыда билгеләп үтелгән җитешсезлекләр генә аның гомуми әһәмиятен киметә алмый. Рецензияләнә торган басма һичшиксез филологик, фәлсәфи һәм медиалогик әһәмияткә ия. Ул үз дәвере, аның барлык вакытлы мәшәкатьләре һәм мәңгелек кыйммәтләре белән тыгыз бәйләнгән фикер иясе һәм публицист Гаспринскийга яңа күзлектән карарга мөмкинлек бирә. Моннан тыш, 1880 елларның икенче яртысындагы Кырымның иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм мәдәни реалияләрен «беренче заттан» ачкан том материаллары тарихчыларга, культурологларга һәм туган якны өйрәнүчеләргә бик тә кызыклы булачак.

**Әдәбият**


*Гаспринский И.* Полное собрание сочинений. Т. I. Литературно-художественные произведения / гл. ред. Р.С. Хакимов; сост. Г.Ю. Сеитваниева, С.А. Сеитмеметова. Симферополь: ООО ФОРМА, 2016. Т. I. 384 с.

*Гаспринский И.* Полное собрание сочинений. Т. II. Ранняя публицистика: 1879–1886 гг. / Гл. ред. Р.С. Хакимов; Сост. С.А. Сеитмеметова. Казань – Симферополь: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2017. 384 с., 23 ил.

*Гаспринский И.* Полное собрание сочинений. Т. III. Публицистика: 1887–1890 гг. / гл. ред. Р.С. Хакимов; сост. С.А. Сеитмеметова. Казань – Симферополь: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2019. 560 с., 16 с. ил.

*Фархшатов М.Н., Исогай М.* Круг читателей литературного наследия Исмаила Гаспринского расширится: рецензия на 1-й том полного собрания сочинений крымскотатарского просветителя на русском языке. Рец. На кн.: полное собрание сочинений Исмаила Гаспринского. Симферополь: ООО Форма, 2016. Т. 1. 384 с. / М. Фархшатов, М. Исогай // Крымское историческое обозрение. 2017. № 2. С. 183–198.



***Яблоновская Наталья Всеволодовна,***

*филология фәннәре докторы, В.И. Вернадский исем. Кырым федераль университетының Таврия академиясе (структур өлеше) славян филологиясе һәм журналистика факультетының телара коммуникацияләр һәм журналистика кафедрасы профессоры*

## ГЕН ПРЕПАРАТЛАРЫН КУЛЛАНУ

Казан федераль университетындагы Фундаменталь медицина һәм биология институтының ачык типтагы «Ген һәм күзәнәк технологияләре» лабораториясе белгечләре, Англиядәге Ноттингем университеты һәм Мәскәү дәүләт ветеринария медицинасы һәм биотехнологияләр академиясе галимнәре белән бергәләп, атларны дәвалау өчен нәтиҗәле ген препараты уйлап таптылар. Атларның зарарланган сеңерләренә кадаганда, ул ике ай эчендә аларның аякларын тулысынча дәваларга, үзләрен – аякка бастырырга сәләтле.

Мәскәү астындагы «Яңа гасыр» клиникасы базасында уздырылган тәҗрибәләр вакытында препарат элегрәк имгәнгән һәм аксап калган атларда сынала. Өч атна дәвалау нәтиҗәсендә алар аксамыйча йөри башлый, тагын ике айдан соң – узышларга һәм сикереп чабуга әйләнеп кайта. Тагын 12 айдан соң тикшерүләр аяклардагы тән тукымасының яңаруын, атларның тулысынча сәламәтләнүен күрсәтә. Фәнни тикшеренү вакытында препаратның тискәре йогынтысы булмау да ачыкланды.

Белгечләрнең пациентлары – спорт ярышларында катнаша торган атлар. Аларның берсенә, 2001 елда туган Ринго Ван Хоф Тер Нилленга 2015 елның июлендә шушы препарат белән операция ясала. Бер айдан соң ул инде CCN 2* программасы буенча өч төрле чыгышны берләштергән ярышта катнаша. Хәзер шулай ук ике йолдызлы программа буенча өч төрле чыгышны берләштергән ярышларда уңышлы чаба.

Тагын бер дәвалanучы ат– Афродита – препарат кулланганнан соң ике ай узуга Европа чемпионатында чаба, яшь атлар арасында команда бүләгенә лаек була.

Әлеге ачыш инглиз телле Daily Mail, The Telegraph, Science Daily, Alphagalileo ресурсы, USWeekly кебек басмаларда телгә алына, экспертлар тарафыннан югары бәяләнә.

Казан университетында эксперименталь эшне КФУ профессоры, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы Альберт Ризванов җитәкли. Галимнәр әлеге тикшеренүдә кулланылган ген терапиясенең уңышы VEGF164 генының про-ангиоген үсеш факторы комбинациясенә мөрәҗәгать итүдә дип саныйлар. Ул кан тамырлары ныгуга, шулай ук фибробластларның (FGF2) үсеш факторына йогынты ясый, үз чиратында, алар күзәнәкләрнең яшәүчәнлеген, сакланып калуын һәм үсүен тәэмин итә. FGF2 аксымы яңа кан тамырларының (ангиогенез) үсешен һәм ныгуын стимуллаштыра, шулай ук яраларның яхшы төзәлүенә, ябылуына китерә. Көтелмәгән иммун реакция булмасын өчен, ике ген да атның үзенеке булып, ул җан иясендәге табигый аксымнарның биосинтезын хасил итә. Моннан тыш, ике рекомбинант ген да бердәм плазмид ДНК га берләшә, нәтиҗәдә биологик яктан куркынычсыз ген терапиясе барлыкка килә.

Мондый травмалар күптөрле хайваннарда һәм кешедә дә очраганга күрә, бу тикшеренү ветеринария өчен дә, шулай ук гомуми медицина өчен дә бик мөһим. Аның нәтиҗәләрен аяк-куллар белән бәйле башка төрле авыруларны дәвалау өчен дә кулланырга мөмкин.

Россия һәм Англия галимнәренең бу ачышы шушы юнәлештәге башка ысуллардан күпкә өстен. Эш шунда, бүген файдаланыла торган стандарт ветеринария терапиясе 60% дәвалануны тәэмин итә, регенератив ветеринариянең иң яхшы ысуллары моны 20% ка арттыра. Бер үк вакытта дәвалану 5–6 ай вакыт сорый. Яңа ысул исә дәвалану вакытын киметә һәм тулысынча аякка басу мөмкинлекләрен тагын да арттыра.

Казан галимнәре бу ысулны башкача зарарлану очракларында, хәтта нәселдән килгән авыруларны дәвалау өчен дә кулланырга була дип саныйлар. Мәсәлән, галимнәр, Казан зоопаркы һәм Казан ветеринария академиясе белән берлектә, эт һәм мәче семьялыгыннан булган җәнлекләрне дәвалаганда ген препаратлары куллана. Казанда аларны сирәк очрый торган кыргый җәнлекләрне дәвалауда сынау да планлаштырылган.

***Ризванов Альберт Анатольевич,***
*Татарстан Фәннәр Академиясенең мөхбир әгъзасы*

# БАШКАЛАБЫЗ ГАЛИМНӘРЕ АКШ ГАЛИМНӘРЕ БЕЛӘН БЕРЛЕКТӘ ЧӘЧЛӘРНЕ ДӘВАЛАУЧЫ БУЯУ ҖИТЕШТЕРГӘННӘР

*«Бионанотехнологияләр» лабораториясендә дарулар җитештерергә һәм тере күзәнәк өслегендә төрле үзгәрешләр башкарырга сәләтле биоматдәләр ясау буенча тикшеренүләр уздырыла. Өслеге үзгәрешләр кичергән тере күзәнәкләр микроскопик һәм стереоскопик техника ярдәмендә сурәткә төшергәндә кулланыла. Лабораториядә шулай ук микроскопик контейнерлар, күп катлы юка элпәләр, биосенсорлар һәм күпкүзәнәкле ясалма системалар да ясала. Биоматдәләрнең эшчәнлегенә үзгәрешләр кертү максатыннан, төрледән-төрле наноматдәләр (нанокисәкчекләр, наносүсләр һ.б.) кулланыла, әлеге наноматдәләрнең агулылыгын тикшерү барышында төрле өлгеләрдән файдаланалар.*

Хәзерге вакытта чәчләрне тәрбия кылу өчен каралган чараларның күбесе өслектә актив булган матдәләр һәм полимерлар нигезендә ясалган. Казан федераль университеты галимнәре исә, Лузиананың (АКШ) Техника университеты хезмәткәрләре белән берлектә, нанокөпшәләр нигезендә җитештерелгән яңа чәч буяу технологиясен булдырганнар. Әлеге буягыч матдә чәчләрне буяу белән беррәттән, баш тиресенең төрле авыруларына каршы да көрәшергә мөмкинлек бирә. Бу технология ветеринария өлкәсендә, хайваннарны дәвалаганда да файдалы булачак. Галимнәр әйтүенчә, тикшеренүләрнең нәтиҗәләре медицина һәм косметика чараларын экологик яктан чиста һәм зыянсыз булган матдәләр ярдәмендә камилләштерүдә аеруча мөһим.

Яңа технология һәлосайт нанокөпшәләренең үзлектән җыела алу эшчәнлегенә нигезләнгән. «Бионанотехнологияләр» лабораториясе тикшеренүләр барышында инде күптәннән һәлосайт исемле материалны кулланып килә. Әлеге материал тышкы диаметры 50–60 нм, ә эчке диаметры 10–15 нм, озынлыгы исә 0,5–1,5 мкм булган күп катлы нанокөпшәдән гыйбарәт. Үз эченә төрле дару матдәләрен сыйдыра алу сәләтенә ия булганга күрә, һәлосайт нанокөпшәләре наномедицина һәм дарулар җитештерү өлкәсендә зур әһәмияткә ия. Галимнәр һәлосайт нанокөпшәләре өчен төрле тутыргычлар тәкъдим итәләр, алар арасында буяу һәм төрле дару матдәләре дә (мәсәлән, бетләргә каршы кулланылучы) бар.

Билгеле булганча, чәч буяуганда селтеләр кулланыла һәм оксидлашу процессы бара, алардан соң чәчләр бик нәзек һәм коры булып кала. Чәч буягычлар төрледән-төрле матдәләрне үз эченә ала, ә аларның тотрыклылары төс прекурсорларыннан тора. Соңгылары, үз чиратында, чәч өслегендә сутуар пероксиды белән оксидлаша – әлеге оксидлашу-кайтарылу реакцияләре чәчләр өчен бик зыянлы.

Һәлосайтлы балчык измәсе, буяу һәм дару матдәләре белән берлектә, чәч бөртеген каплый һәм аның тәэсире бик озак вакытлар дәвамында (чәчләрне 30 тапкыр юганчы) сакланырга сәләтле. Тикшеренүчеләр әйтүенчә, чәчкә төс кертү өчен әлеге матдәне 3–5 минут тоту да җитә, ә буягыч матдәнең түбән концентрациясе һәм технологиянең куркынычсызлыгы аллергия ихтималын киметә.

Шунысы кызык, чәчләрне буяучы юка катлам тотып караганда сизелми дә, аны бары микроскоп астында гына күрергә мөмкин. Яңа технология буенча махсус эреткечләр һәм чәч өчен зыянлы булган селтеләр дә кулланылмый.

Тикшеренү барышында һәлосайт нанокөпшәләренең педикулезга каршы нәтиҗәле булуы да ачыкланган. Галимнәр нанокөпшәләрне әлеге авыруны дәвалаучы берничә матдә белән тутыруга ирешкәннәр. Шулай итеп, яңа технологияне шулай ук ветеринария өлкәсендә дә кулланырга мөмкин булачак. Җәй айларында мөгезле эре терлекнең паразитлар йоктыру ихтималы бермә-бер арта, гадәттәге дәвалау ысулларын яңа технологиягә алмаштыру бу проблеманы чишәргә дә ярдәм итә ала.

Балчык нанокөпшәләренең чәч өслегендә үзлектән җыела алу сәләтенә багышланган мәкалә *Nanoscale* басмасында урын алган. Хәзерге вакытта галимнәр төркеме, патентланган технологияне коммерцияләү максатыннан, косметика ширкәтләре вәкилләре белән сөйләшүләр алып бара.

***Фәхруллин Равил Фәрит улы,***
*биология фәннәре докторы*

**2019 елның 10 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты оешуга 25 ел тулуга багышланган тантаналы чара узды.

Чарада катнашучыларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары М.Г. Әхмәтов, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты М.Х. Саләхов сәламләде, алар Институтның юбилее уңаеннан котлау сүзләрен җиткерде. Институт директоры И.А. Гыйләҗев Татарстан Республикасында энциклопедистика фәне үсеше тарихы турында чыгыш ясады.

Тантаналы чарада Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты хезмәткәрләрнә дәүләт һәм тармак бүләкләре тапшырылды.

**2019 елның 25 октябрендә** «Россия – ислам дөньясы» стратегик караш төркеме Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән берлектә Язучылар һәм интеллектуалларның «Айтматов укулары – мәдәниятләр диалогы өчен» III Халыкара форумын үткәрде.

Форум «Россия – ислам дөньясы» стратегик караш төркемен оештыру эшен башлап җибәргән һәм үзенең әсәрләрендә цивилизацияләр хезмәттәшлеге идеясен пропагандалаган күренекле совет язучысы Чыңгыз Айтматов истәлегенә багышланды. «Глобаль үзгәрешләр чорында кеше һәм мәдәният» темасы агымдагы елда Айтматов укуларының темасы итеп билгеләнгән иде.

Россия төбәкләреннән һәм чит илләрдән килгән галимнәр, фәнни хезмәткәрләр, югары уку йортлары мөгаллимнәре, мәдәният эшлеклеләре һәм язучылар катнашында пленар утырыш, «Глобаль дөньяда милли әдәбиятларның роле» темасына түгәрәк өстәл оештырылды, Чыңгыз Айтматов турында «Аматус» кинокомпаниясе тарафыннан төшерелгән документаль фильм (режиссеры Григорий Нахапетов) күрсәтелде.

**2019 елның 30 октябреннән 3 ноябренә кадәр** «Казан ярминкәсе» күргәзмә үзәгендә XI «АРТ-Галерея. Казан» күргәзмәсе эшләде. Күргәзмәдә Россиянең төрле төбәкләрендә яшәп иҗат итүче ике йөзгә якын рәссам, скульптор һәм декоратив-гамәли сәнгать остасының төрле юнәлешләрдә иҗат иткән меңнән артык әсәре тәкъдим ителде.

Экспозициянең һәр көне билгеле бер сәнгать төренә багышланган иде: Театр көне (30 октябрь), Әдәбият һәм шигърият көне (31 октябрь), Кино көне (1 ноябрь), АРТ – дизайн көне (2 ноябрь). Күргәзмә кысаларында шулай ук сәнгать мәктәпләре укучылары, студентлар һәм яшь рәссамнар арасында декоратив-гамәли сәнгать буенча «Алтын кош. Золотая птица – 2019» республика бәйгесе оештырылды.

**2019 елның 21–24 ноябрендә** Казан федераль университетының Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү» VII Халыкара фәнни-гамәли форумы үткәрелде. Форум тү-

бәндәге фәнни чараларны үз эченә алган иде:

«Күпмилләтле дәүләт шартларында туган телләрне саклау һәм үстерү: проблемалар һәм перспективалар» X Халыкара фәнни-гамәли конференциясе;

«Евразия гуманитар фәннәре контекстында татар теле белеме» II Халыкара фәнни-гамәли конференциясе;

«Мәдәниятнең рухи факторы буларак хәзерге шәһәрнең сәнгати-тарихи тирәлеген саклау» IV Халыкара фәнни-гамәли конференциясе;

«Мәдәниятара бәйләнешләр контекстында сәнгать һәм аны укыту» VIII Халыкара фәнни-гамәли конференциясе;

«Хаков укулары» Яшь галимнәр өчен халыкара фәнни-гамәли конференциясе.

Форумда чит илләрдән һәм Россия төбәкләреннән 300 гә якын галим, мәгариф хезмәткәре, аспирант һәм магистрант катнашты.

**2019 елның 22–23 ноябрендә** Казан федераль университетының Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтында уздырылган «Евразия гуманитар фәннәре контекстында татар теле белеме» II Халыкара фәнни-гамәли конференциясе тел гыйлеме өлкәсендәге күренекле галимнәр – тәрҗемәче, каллиграф Мөхәммәтгали Мәхмүдов, лексикограф Ризаэтдин Газизов, тел тарихы, диалектология, татар теле культурасы өлкәсендә танылган белгеч Латыйф Җәләй, социолингвистика, лексикология өлкәләрен өйрәнүгә зур өлеш керткән Әнвәр Ахунҗанов, диалектология, этнолингвистика, лингвометодика юнәлешендә танылган галим Фәрит Йосыповларның юбилейларына багышланган иде.

Конференциядә катнашучылар татар теле белеменең актуаль мәсьәләләре, лингвистикадагы яңа юнәлешләр һәм аларның татар теле белемендәге урыны, тел тарихы, телләрне чагыштырма-тарихи аспектта өйрәнү, полилингваль белем бирү һәм мәдәниятара бәйләнешләр темаларына фәнни докладлар белән чыгыш ясады.

**2019 елның 25–27 ноябрендә** Казанда «Иделем акчарлагы – 2019» яшь татар язучыларының XIX республика бәйгесенең йомгаклау туры үткәрелде. Анда 70 кә якын яшь язучы чакырылган иде. Җиңүчеләрне котлау тантанасы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы бинасында узды.

Бәйге Татарстан Республикасы «Идел» яшьләр үзәге тарафыннан талантлы яшь язучыларны барлау, берләштерү, иҗатларын активлаштыру максатыннан үткәрелде. Анда Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка төбәкләрендә, чит илләрдә яшәүче 14 яшьтән алып 30 яшькә кадәр булган каләм ияләре катнашты. Төп номинацияләр буларак, поэзия, проза, драматургия, балалар әдәбияты һәм «Хезмәт төбе – хәзинә» (Татарстанда 2019 ел Эшче һөнәрләр елы дип игълан ителү уңаеннан эшче һөнәрләр чагылыш тапкан әсәрләр) билгеләнгән иде.

**2019 елның 6–11 декабрендә** Казанда «Һөнәр» XI Бөтенроссия яшь режиссура фестивале узды.

Яшь режиссерлар тарафыннан тамашачыларга 22 спектакль тәкъдим ителде. Алар Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында, К. Тинчурин исемемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында, Г. Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театрында, Казан Яшь тамашачы театрында, «Әкият» Татар дәүләт курчак театрында, «Угол» иҗат лабораториясендә, «Тәрәзә» хәзерге заман сәнгать галереясында һәм «WERK» артпространствосында күрсәтелде.

Фестивальдә танылган театр режиссеры, дәүләт һәм театр премияләре лауреаты, Россиянең халык артисты Кама Гинкас катнашты, ул «Һөнәр» фестивале кысаларында узган өч көнлек уку-укыту программасы нигезендә мастер-класслар үткәрде.

**2019 елның 11 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Ике һәм күптеллелек шартларында дәүләт һәм региональ телләрне куллануның хокукый нигезләре (федераль дәүләтләрдә тел сәясәтен тормышка ашыруның дөньякүләм тәҗрибәсе)» дигән темага Халыкара фәнни-гамәли конференция үтте. Әлеге чара Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылды.

Конференция эшендә Назарбаев Университеты профессоры, филология фәннәре кандидаты Г.А. Омарбәкова (Казакъстан Республикасы), А. Герцен исемендәге Россия дәүләт педагогика университетының Билингваль һәм полимәдәни белем бирү үзәге директоры, Мәскәү педагогика дәүләт университетының рус телен чит тел буларак укыту кафедрасы мөдире, педагогика фәннәре докторы, профессор Е.А. Хамраева (Мәскәү), Россия мәгариф академиясенең «Педагогика» журналы баш мөхәррире, педагогика фәннәре докторы, профессор Р.С. Бозиев (Мәскәү), Чувашия Республикасы Мәгариф һәм яшьләр сәясәте министрлыгының Чувашия Республикасы Мәгариф институты проректоры, филология фәннәре докторы С.В. Петрова (Чебоксар), Удмуртия Республикасы Мәгарифне үстерү институтының Тьюторлык тәҗрибәсен үстерү үзәге директоры, этномәдәни белем бирү үзәге методисты, филология фәннәре кандидаты А.А. Клементьев (Ижау), Төмән дәүләт университеты Тубыл педагогия институтының филология белеме кафедрасы доценты, филология фәннәре докторы Г.Ч. Фәйзуллина (Төмән), Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Казан федераль университеты галимнәре, белем бирү оешмалары мөгаллимнәре һ. б. катнашты.

**2019 елның 12–13 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «Ризаэтдин Фәхретдиннның мирасы һәм иҗтимагый эшчәнлеге» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды. Ул күренекле галим, педагог, тарихчы, җәмәгать һәм дин эшлеклесе Ризаэтдин Фәхретдиннең тууына 160 ел тулу уңаеннан үткәрелде. Фәнни форум Татарстан

Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты тарафыннан оештырылды.

Чараның тантаналы өлешендә «Казан Кремле» Музей-тыюлыгының «Манеж» күргәзмәләр залында Р. Фәхретдиннең 2018–2019 елларда нәшер ителгән хезмәтләре тәкъдир ителде һәм «Ризаэтдин Фәхретдинов дәресләре» күргәзмәсе оештырылды.

Форум программасы кысаларында барлыгы дүрт тематик секция эшләде.

**2019 елның 17–20 декабрендә** Казанда «Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» форумы узды. «Корстон» сәүдә-күңел ачу комплексында оештырылган пленар утырышта Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты.

19 декабрьдә Татарстан Фәннәр академиясендә Форумга килүчеләр өчен уку-укыту чарасы үткәрелде, Татарстан Фәннәр академиясенең татар телен үстерүгә юнәлтелгән проектлары тәкъдир ителде. Анда чит төбәкләр һәм илләрдә яшәүче эшмәкәрләр белән үзара элемтә, уртак проектлар булдыру мөмкинлекләре каралды.

«Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» форумы кысаларында Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасының киңәйтелгән утырышы оештырылды.

Әлеге чараларда Россиянең 63 төбәгеннән һәм 29 чит илдән 650 дән артык вәкил катнашты.

**2019 елның 19 декабрендә** «Казан ЭКСПО» Халыкара күргәзмә үзәгенең И. Шакиров исемендәге концерт залында ТАССР-ның 100 еллыгын бәйрәм итү чараларын башлап җибәрүгә багышланган тантаналы чара үтте.

Тантанада Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе М.Ш. Шәймиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин, республиканың министрлык һәм ведомство җитәкчеләре, дәүләт органнары вәкилләре, фән, мәдәният һәм спорт эшлеклеләре катнашты.

Әлеге чара кысаларында Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев һәм Бөек Ватан сугышы ветераны, Советлар Союзы Герое Борис Кузнецов Татарстан Республикасының яңа дәүләт бүләге – «ТАССР төзелүнең 100 еллыгы» медале белән бүләкләнде.

**2019 елның сентябрь-декабрь айларында** Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Театр эшлеклеләре берлеге, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры тарафыннан «Яңа татар пьесасы – 2019» бәйгесе үткәрелде. Бәйгегә 50 дән артык эш тәкъдим ителде.

22 декабрьдә, татар театрының туган көнендә, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында әлеге бәйгенең җиңүчеләре игълан ителде. Беренче урынга Артур Шәйдуллинның «Сагынырсызмы?» пьесасы лаек булды. II премия «Чия тавы» пьесасы өчен – Илгиз Зәйниевкә, III премия «Янгын» пьесасы өчен Зөлфәт Хәкимгә тапшырылды.

Айгөл Әхмәтгалиеваның «Яратып туялмадым» әсәренә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының махсус премиясенә лаек булды. Зөлфәт Хәким, Илфак Ибраһимов пьесалары кызыксындыру премиясен яулады.

**2019 елның 23 декабрендә** Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан «Төрки дөнья театры: үсеш юлларын билгеләү» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе оештырылды. Әлеге чара Россиядә театр елына багышлап үткәрелде.

Конференция программасы төрки дөнья театрының көнүзәк проблемаларын ачыклау, милли театрлар тарихын барлау, драматургия һәм театраль педагогика үзенчәлекләрен өйрәнү, музыка һәм сәхнәнең нәфис бизәлеше темаларын үз эченә алды.

Конференциядә Россиянең һәм төрки илләрнең театр юнәлешендәге күренекле фән эшлеклеләре (И.Р. Исрафилов, Азәрбайҗан; С.Д. Кабдиева, Казакъстан; Бенги Бугай, Төркия; А.А. Степанова, К.Н. Матвиенко, Мәскәү; Т.С. Джурова, Санкт-Петербург; А.С. Сәгыйтова, Уфа; С.А. Окольникова, Абакан һ.б.), Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе институтлары, Казан федераль университеты, Казан дәүләт мәдәният институты, фәнни оешмалар, театр сәнгате белән бәйле уку йортлары, Татарстан Республикасы дәүләт оешмалары, Татарстан Республикасы Милли музее, Татарстан Язучылар берлеге һәм матбугат вәкилләре, архив хезмәткәрләре, аспирантлар, студентлар катнашты.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2019. № 4

Бизәлеш авторы – Э. Бәшәрова
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 28.12.2019. Басылды: .01.2020.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,5. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ, К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20

Журнал бушлай таратыла